www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда языу индексы – П2355.

№ 18 (1383) 13 май 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

12

Ибне Фадланның Ризаэтдин Фәхретдин тарафыннан тәрҗемә ителеп, Бакый Урманче архивында сакланган сәяхәтнамәсе, һичшиксез, өйрәнелергә тиеш.



16

Әдәби әсәрдәге вакыйгаларның тарихи хакыйкатькә туры килүе һич тә мәҗбүри түгел, ди үзенең тарих сабакларында Рабит Батулла.

24

К.Тинчурин театры сәхнәләштергән “Беренче театр” спектакле классиканы яңарту түгел, журналистларга тәрттеру генә булып чыкты.



Май чәчкәсе, шау сарыга манып, Язны җәйгә бара озатып...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстанда Бөек Ватан сугышында турыдан-туры катнашкан 359 кеше гомер итә.

- Бөтендөнья татар конгрессы 19-21 май көннәрендә «Милли тормыш һәм дин» XII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумын үткәрә.

- Мөслимнең Тукай скверында бу районның Түреш авылында туган шагыйрь Ләбиб Леронга элмә такта куелды.

- 13-18 майда Казанның «Мир» кинотеатрында узачак Төрки кино көннәре кысаларында Төркия, Казахстан, Әзәрбайҗан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Саха (Якутия) Республикасында, Хакасиядә һәм Татарстанда төшерелгән фильмнар күрсәтеләчәк.

- Халыкара музейлар көнендә (18 май) Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музеена, Заманча сәнгать галереясына һәм «Хәзинә» милли сәнгать галереясына бушлай кереп булачак.

- Россия Фәннәр академиясенең Уфа федераль тикшеренү үзәге галим-этнолог Илдар Габдрәфыйковны кабат эшкә алды.

- Уфаның Мостай Кәрим исемендәге Милли яшьләр театрында очучы-штурмовик, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәевнең 100 еллыгына багышланган «Герой йолдызы» спектакленең премьерасы булды.

- Украина территориясендәге махсус операция вакытында һәлак булган Россия Герое Дамир Гыйлемхановны хөрмәтенә Казандагы йорт диварына мурал (зур сурәт) ясадылар.

- Болгар цивилизациясе музеенең күргәзмә мәйданчыгында «Идел буе Болгары балалар күзлегеннән» күргәзмәсе ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Гөлүсә БАТТАЛОВА, шагыйрә:

“Бездә әдәбиятны пропагандалау начар эшли, ул замана ритмыннан арттарак калган. Хәзерге заман чит ил авторларын, русча язган авторларны карасак, алар дистәләгән телгә тәрҗемә ителә, әсәрләре буенча фильмнар төшерелә, китаплары күргәзмәләрдә катнаша. Автор үзе бит китап пропагандасы белән әллә ни шөгыльләнми дә, реклама, әсәрне җиткерү белән китап агентлыклары, әдәби агентлар шөгыльләнә.

Ә инде нәкъ шул ук югарылыктагы татарча язылган әсәр күп дигәндә китап булып басылып чыга. Ул әле укучысына барып җитмәскә дә мөмкин. Шуннан татар әдәбиятында укырлык әсәр калмады дип сүз чыга».

СЫНАМЫШЛАР

14 майда аяз булса, урак өстендә дә аяз көннәр фаразлана ● 15 майга каршы төндә сандугач сайраса, көн кояшлы булачак; бу көнне бодай һәм арыш чәчәләр ● 18 майда кәбестә үсентеләрен бакчага чыгарып утыртырга була ● 19 майда кыяр һәм борчак чәчәләр; бу көнне чык мул төшсә, кыяр уңа.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 35 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 45 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 10 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **24 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **20 майда 16 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

15 май – гобойчы, педагог, Татарстанның атказанган артисты Мөбәрәк Вазыйх улы Батталовның тууына 110 ел (1912–2006);

– актёр, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Нәҗип Сәмигулла улы Гайнуллинның тууына 110 ел (1912–1969);

– Халыкара гаилә көне.

18 май – төрки телләр белгече, этнограф, профессор Николай Фёдорович Катановның тууына 160 ел (1862–1922).

19 май – Оренбургта «Галимнәр илә залимнәр» әсәре белән «И.Б.Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге беренче мөселман драма артистлары труппасы» (булачак «Сәйяр») үз эшен башлый (1907).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 19 май.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(9-16 май)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **30 апрельдән 17 майга кадәр** талак, ашказаны асты бизе һәм ашказаны актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 12 нче көне

КӨН КАДАГЫНА

Морат Рәмзине зурлау

● Камил хәзрәт Сәмигуллин сәламли.

Халыкны аның шәхесләре милләт итә. Шөкер, бу яктан татар талантлы шәхесләргә бай. Шундыйларның берсе – күренекле дин белгече, тарихчы, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Морат Рәмзи (1855-1934). 5-6 май көннәрендә аның туган ягы – Сарман төбәгендә ошбу уникаль шәхеснең тормыш юлын һәм эшчәнлеген яктыртуга багышланган иҗтимагый вә фәнни чаралар узды. Идел буе Болгарында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлап әзерләнгән бай эчтәлекле манзара М.Рәмзи туган Иске Әлмәт авылында башланды. Кайткан кунаклар аның исемен йөрткән урта мәктәптә дәресләрдә булды һәм М.Рәмзи музеен карады, мәктәп янында 15 алмагач үсентесе утыртып, олуг шәхес хөрмәтенә булдырылачак бакчага нигез салды, М.Рәмзи исемендәге мәчеттә намаз кылып, корбан ашыннан авыз итте. Кызыклы чаралар авылның кайчандыр М.Рәмзи тәмле суын эчеп үскән «Олы Яр» чишмәсе янында да дәвам итте, андагы халык чишмә суыннан әзерләнгән чәй эчеп хушланды. Соңрак кунаклар Сарман «Шәфкать үзәге»ндә булды, анда халык һөнәрчеләренең «Сөлге туе» күргәзмәсен карады. Кичен «Мәдәният йорты»нда Сарман сандугачы Зөһрә Шәрифуллина, башка җырчылар һәм район фольклор төркеме концерты булды, шулай ук Мәскәү татарлары милли конгрессы башлыгы Рөстәм Ямалиев тырышлыгында татар теле һәм шәхесләребез хакында 10 мең данә тираж белән нәшер ителгән «Үз җиремдә – үз телем» дигән китап та тәкъдир ителде.

Инде М.Рәмзинең тормыш юлы һәм эшчәнлегенә дә кыскача гына тукталып үтик. Чөнки аның шәхесе һәм хезмәтләре, төрле сәбәпләр аркасында, билгесезлектә кала килде. Үзе төзегән шәҗәрә буенча, чыгышы белән ул Байлар ыруы нәселеннән, Бикчура ханга тоташа. Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, 1869 елда Казанга килә һәм Ш.Мәрҗани мәдрәсәсендә укый башлый. Ел ярым укыгач, Россиядә суфыйчылык үзәкләренең берсе булган Троицк каласына күчеп килә һәм укуын шунда дәвам итә, анда Нәкшбәндия тәрикатенә керә. 1876 елда М.Рәмзи Мәккәгә беренче тапкыр хаҗ кыла. Гарәбстанда ул 36 ел яши һәм шәех дәрәҗәсенә күтәрелә. Бу чорда М.Рәмзи фарсыдан гарәпчәгә суфый трактатларын, башка хезмәтләрне тәрҗемә итә, үзенең «Тәлфик әл-әхбәр...» («Казан, болгар һәм татар хәкимнәре һәм алар белән бәйле вакыйгалар турында хәбәрләр вә риваятьләр җыентыгы») дигән хезмәтен яза. Җәмгысе ул – 15 тән артык фәнни хезмәт һәм күп кенә мәкаләләр авторы. Гомеренең соңгы 15 елын Кытайда үткәрә. Анда ул Коръәнне татар һәм кытай телләренә тәрҗемә итә. 1934 елның 2 апрелендә Чугучак каласында вафат була.

Ә Сарманда 6 майда «Танылган дин белгече, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Морат Рәмзи: тарих һәм хәзерге заман» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Ул Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты, Россия ислам институты (Казан), Сарман районы хакимияте, Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм ассоциациясе, Татарстанның «Төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте», «Живое древо» фонды (ТР) һ.б. тарафыннан оештырылган. Эшче телләр анда – татар, рус һәм инглиз телләре иде. Форумны Сарман районы башлыгы Фәрит Хөснуллин һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ачты. Чарага Кытайдан М.Рәмзи оныгының улы Габделәхәт Рәмзи дә гаиләсе белән кайтты (чыгыш та ясады). Конференция Сарман төбәгеннән чыккан олуг шәхесләргә багышлап махсус әзерләнгән «Шушы җирдән, шушы туфрактан без!» дигән видеофильмны караудан башланды. Анда М.Рәмзи эшчәнлеге буенча докторлык диссертациясе яклаган галим Сәид Аукут (Төркия) һәм уйгур галимнәре күренекле якташыбыз хакында зурлап сөйләде.

Конференциядә танылган галимнәребез Хатыйп Миңнегулов, Искәндәр Гыйләҗев, Альберт Борһанов һ.б. чыгыш ясады. ZOOM аша аларга Нью-Йорктан – тюрколог-галим Юлай Шамилоглы (Казахстан), Мәскәүдән – галим, морзалар лидеры Илдар Үтәмешев, Уфадан – М.Рәмзи эшчәнлеге буенча кандидатлык диссертациясе яклаган, аның турында Мәскәүдә китап та бастырып чыгарган галим Салават Әхмәдуллин һ.б. өстәлде. Абруйлы шәхес, Сарманның күренекле төбәк тарихчысы Дамир Гарифуллин, Уфадан Татар морзалары мәҗлесе әгъзасы Кәрим Яушев, дин әһелләреннән Йосыф хәзрәт Дәүләтшин, Габдрахман хәзрәт Галәүтдинов, Сәет хәзрәт Хаков һ.б. чыгышлары да игътибарга лаек. Конференциядә 31 доклад тыңланды. Форумны «Милли Шура» әгъзасы, Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм ассоциациясенең Башкарма директоры, тарих фәннәре кандидаты Фәрит Уразаев алып барды. Аның әйтүенчә, конференция татар тарихына карата моңа кадәр булган эчке вә тышкы карашларны чагыштырып, алтын урталыкны табу мөмкинлеге бирә. Татарның гомуми һәм төбәк тарихлары синтезы исә катлаулы үткәннәргә тарихи эзлеклелек, объективлык һәм ачыклык та өсти. Ә М.Рәмзинең суфыйчылык карашлары инде, татарның үткәне һәм бүгенгесенә генә түгел, киләчәгенә дә фәлсәфи мәгънә кертә. Конференциядә катнашучылар мәртәбәле форумны оештыруга зур өлеш керткән Сарман муниципаль районы хакимиятенә, шулай ук башка оештыручыларга рәхмәт белдерде. Эш нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәр буенча резолюция кабул ителде.

● Габделәхәт Рәмзи гаиләсе белән: хатыны Әминә Рәмзи, кызлары Наилә һәм Наҗия, модератор Фәрит Уразаев, Сарман муниципаль район башлыгы Фәрит Хөснуллин.

Фоат УРАЗАЙ.

ТЕЛ ГАЗАБЫ – ГҮР ГАЗАБЫ

Юл газабы – гүр газабы, ди халык. Тел тыя белмәү газабы да җинелләрдән түгел икән. Россия тышкы эшләр министры С.Лавровның Италия телекомпаниясенә биргән интервьюсында яһүдиләр хакында әйткән сүзләре Израильдә зур канәгатьсезлек китереп чыгарды.

Журналистның аннан, Украина лидеры В.Зеленский әйткән, президенты яһүди булган илдә «денацификация» үткәрү – мәгънәсезлек, дигән сүзләрен шәрехләвен үтенгән соравына җавабында С.Лавров: «Хаталануым да бар, әмма Адольф Гитлерда да яһүдиләр каны булган. Бу мотлак бернәрсәне дә белдерми. Зирәк яһүд халкы әйтүенчә, иң ярсулы антисемитлар, кагыйдә буларак, яһүдиләр үзләре. Бездә әйтелгәнчә, гаилә гарипләрсез генә булмый», –дип ачыласы иткән. Израиль тышкы эшләр министры Яир Лапид моны «коточкыч тарихи хата» дип атаган. Аның әйтүенчә, яһүдләр холокост вакытында үзләрен үзләре үтермәгән, яһүдиләрне антисемитизмда гаепләү – расачылыкның иң кабахәт төре. Израиль премьер-министры Нафтали Беннет та җавапсыз калмаган. Бу җәһәттән ул: «...Мондый ялганның төп максаты тарихта яһүдләргә каршы кылынган иң куркыныч җинаятьләрдә дә аларның үзләрен гаепләүдән гыйбарәт», – дип рәнҗегән, Россия ягыннан гафу үтенүләрен көтүе турында да искәрткән.

Инде кайбер башка вакыйгаларга да күчик. Европа комиссиясе рәисе Урсула фон дер Ляйн Европа Берлеген реформалау идеясен хуплавы, ә бүгенге норма буенча анда консенсуслы тавыш бирү оешмада еш кына кирәкле карарның кабул ителмичә калуына китерүе турында белдергән. Мондый каларга ул 8 майда Венгрия Россиягә каршы кертелә торган санкцияләрнең 6 нчы пакетына каршы тавыш бирәчәк килгән. Ә АКШ президенты Джо Байден 9 майда, мәгълүм киная белән, «ленд-лиз» турындагы законны имзалаган. Димәк, бу инде Украинага хәрби ярдәм һәм сугыш коралларының ирекле куелуына юл ачыла дигән сүз. Алмания канцлеры Олаф Шольц та Россиянең Берлин өчен Украинага корал җибәрүдән башка юлны калдырмавы турында белдерде. Сүз инде авыр сугыш кораллары турында да бара. Молдова исә, Приднестровьедагы низагны тыныч юл белән хәл итү ниятендә, БМО аша Россия хәрбиләрен бу төбәктән чыгарырга чакыра.

Янә бер ишарәле борылыш. Узган җомгада БМО АКШта узган үзенең гадәти утырышында, Украинада хәрби операция башланганнан соң беренче мәртәбә, бу илдәге вәзгыять буенча белдерүгә бертавыштан кабул итте. Белдерү анда майда рәислек иткән АКШ тарафыннан кертелгән. Ул документта Украинада тынычлык вә иминлекне тәэмин итү җәһәтеннән АКШның тирән борчылу белдерүе, эгъза булып торган барлык дәүләтләрнең дә халыкара бәхәсләрне БМО Уставы кысаларында тыныч юл белән хәл кылырга йөкләмә алулары, Украинадагы кризисны хәл итү юлларын табуда БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш тырышлыгын хуплавы турында әйтелә. Әмма, резолюциядән аермалы буларак, АКШ рәислек иткән ил ясаган мондый белдерүләр мәҗбүри көчкә ия түгел икән.

Фоат УРАЗАЙ.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Нәтиҗәле иҗади эшчәнлекләре, театр, музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен К.Тинчурин театры артисты **Зөлфия Наил кызы Латыйпова (Вәлиева)**, Казан шәһәр филармониясе җырчысы **Рөстәм Мәҗит улы Асаев**, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле җырчысы **Гөлшат Фоат кызы Шәрәпова**, композитор, автор башкаручы **Зифа Вәли кызы Нагаева**га Татарстанның халык артисты исеме бирелде. Шулай ук әлеге мактаулы исемгә Качалов исемендәге Рус театры артистлары **Елена Юрьевна Ряшина** һәм **Марат Викторович Голубев** та лаек булды.

Театр, музыка сәнгате үсешенә керткән өлеше өчен Минзәлә драма театры артисты **Динара Абдулабәк кызы Әхмәтова**, Чаллыдагы «Орган залы» башкаручысы **Илсөяр Таһир кызы Сөләйманова,** Дәүләт академия симфоник оркестры артисты **Фәгыйль Мансур улы Гыйльманшин** һәм эстрада җырчысы **Радик Мөхәрләм улы Юльякшинга** (Элвин Грей) «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелде.

Мәдрәсә төзеклөндерүне көтә

Казанның Иске татар бистәсендә урнашкан «Касыймия» (Күл буе, Апанай мәдрәсәсе) мәдрәсәсе җимерелергә мөмкин. Бу хакта мәдрәсә мөдире Әхмәт Сабиров белдергән.

«Җил чыккан саен түбә калайлары урыныннан куба, яңгырда мәдрәсәгә су үтә. Диварлар буйлап агып төшкән су нигезгә зыян китерә. Без аларны даими рәвештә кадаклыйбыз, ләкин тузган такталар черегән калайны тотмый. Су үтү сәбәпле, бинага җимерелү яный. Без аны югалтудан куркабыз», – дигән ул.

Мәдрәсә бинасы Татарстанның мәдәни мирас объекты исемлегенә кергән. Түбәне бары дәүләт рөхсәте белән алыштырырга мөмкин. Әхмәт Сабиров дәүләт оешмалары Татарстан президентының бинаны төзекләндерү турындагы йөкләмәсен үтәмәде дип саный: «2018 елда Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов мәдрәсәне төзекләндерергә кирәк дигән йөкләмә бирде, әмма бүгенгә кадәр аның әмере үтәлеп бетмәгән. Татарстанның төп инвестицион-төзелеш идарәсе сметаны ясады, ләкин финанс чыганагы билгеләнмәде, шуңа күрә нинди акчага эшләргә кирәген беркем белми». Аның сүзләренчә, мәдрәсәнең түбәсе таушалган хәлдә булуы түрәләргә 2008 елдан бирле билгеле.

«Касыймия» мәдрәсәсе 1877 елда хәйрияче Ибраһим Юнысов акчасына архитектор Петр Романов проекты буенча төзелгән һәм Идел буе төбәгендә иң зур мөселман уку йортларыннан саналган. Төрле вакытларда анда Зәки Вәлиди, Гафур Коләхмәтов, Гаяз Исхакый һ.б. укыткан, Галиәсгар Камал, Муса Бигиев, Садри Максуди, Камил Мотыйгый белем алган.

2010 елда мәдрәсә бинасы Апанай мәчете карамагына бирелде. Бүген уку йортында йөздән артык кеше белем ала.

Балаларга милли проектлар

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» һәм «Сөйлә» проектлары 16 майда йомгаклау тамашасы белән тәмамланачак.

Бу проектлар Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Президенты каршындагы комиссия ярдәмендә Казан мэриясе тарафыннан гамәлгә ашырылды. Аларда Казанның 40 мәктәбеннән 700 ләп укучы катнашты. Дәресләр дүрт ай – февраль аеннан май аена кадәр дәвам итте. «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты дәресләрендә укучылар татар халык биюенә өйрәнде. Балалар белән профессиональ биючеләр һәм хореографлар эшләде. Дәресләр татар телендә барды. «Сөйлә» проектында катнашучылар сәнгать телен өйрәнделәр. Алар өчен тел техникасы, татар телендә сүз сәнгате буенча осталык дәресләре оештырылды. Дәресләрне театр артистлары һәм телевидение алып баручылары үткәрде.

Йомгаклау тамашасында укучылар бию сәнгатен һәм нәфис сүзне берләштерүче номерлар белән чыгыш ясый. Чарада проект остазлары да катнаша.

Май уртасыннан «Хәрәкәттә – бәрәкәт» Казан паркларында һәм скверларында дәвам итәчәк, теләге булган һәркем катнаша ала.

Тукайга мәхәббәт илә...

Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәге шәһәр мәгариф идарәсе белән берлектә «Тукайга мәхәббәт илә...» дип исемләнгән III Бөтенроссия шигырь сөйләүчеләр конкурсын игълан иткән иде. Бәйгене үткәрүдә Әлки районы якташлык җәмгыяте, Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Язучылар берлеге ярдәм күрсәтә.

Үзәк җитәкчесе Флюра Абдуллина хәбәр иткәнчә, конкурска Татарстанның Казан, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләре, Мамадыш, Бөгелмә, Әтнә, Сарман, Кама Тамагы, Лаеш, Әлки, Яңа Чишмә, Минзәлә, Чистай, Арча, Буа, Тукай һ.б районнарның мәктәп-гимназияләрендә, лицейларында укучылардан, балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрдән, мәдрәсәләрдә белем алучы шәкертләрдән, югары уку йортлары студентларыннан Г.Тукай шигырьләрен сөйләгән видеоязмалар алынган. Конкурста шулай ук Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы мәктәбеннән, Эстония (Таллин), Швеция, Берләшкән Гәрәп Әмирлекләре (Дубай) кебек мәмләкәтләрдән мәктәп укучылары да катнашкан. Гомумән, сәнгатьле сөйләм бәйгесенә 300 дән артык видеоязма килгән. Аларны шагыйрь, прозаик Марат Закиров, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты баш референты Илдар Мингәрәев, шагыйрә, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Наилә Яхина, журналист, «Гаилә һәм мәктәп» журналы бүлек мөхәррире Ирек Нигъмәти составындагы жюри бәяләгән. Аларның киңәшләре укучыларга гаять файдалы булгандыр.

Күптән түгел Татар мәдәнияте үзәгендә конкурска йомгак ясалды. Иң элек тантанада катнашучыларга Россия кооперация университеты ректоры, Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлары берләшмәсе рәисе Алсу Нәбиева тәбрикләүләрен җиткерде. Бу көнне төрле номинацияләрдә призлы урыннар алган 60 җиңүчегә дипломнар тапшырылды. Бүләкләү тантанасында Тукайның тормышы һәм иҗаты буенча викторина уздырылуы бәйрәмне тагын да җанландырып җибәрде.

Тантана «И Туган тел» җырын күмәк башкару һәм институт бинасы янында истәлек фотога төшү белән тәмамланды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Татарстаннан читтә яшәүчеләр игътибарына

*2022 елның икенче яртыеллыгына **«Мәдәни җомга»** газетасына Татарстаннан читтәге өлкә-республикаларда да – Башкортстан, Оренбург, Ульяновск, Төмәндә һәм башка төбәкләрдә язылып була. Газетабыз электрон каталогка кертелгән **(язылу индексы – П8254).** Игътибар! **«Мәдәни җомга»** газетасын почта бүлекчәләрендә электрон каталогтан эзләтегез.*

1 нче биттә – язгы бал чәчәге – тузганак.
Фото: pxhere.com

«Үлемсез полк» – янә урамда!

Җиңү бәйрәме көнне Казан үзәгеннән 170 мең кеше катнашында «Үлемсез полк» үтте. Коронавирус аркасында ике ел онлайн-форматта узганнан соң, быел шәһәр халкы Бөек Ватан сугышында катнашкан әби-бабаларының фоторәсемнәрен күтәреп, Казан үзәге урамнары буйлап атлады.

Колонна башында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Хөкүмәте әгъзалары, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, төрле иҗтимагый оешма вәкилләре барды. Республика җитәкчесе йөрештә әтисенең бертуганы Галимҗан Миңнеханов портреты белән катнашты. Татарстан Президенты янәшәсендә аның улы Искәндәр дә барды. Ул әнисе ягыннан бабасы – Бөек Ватан сугышы ветераны Бари Сафиуллин портретын күтәргән иде.

Ирек мәйданыннан башланган колонна Кремль янындагы Меңьеллык мәйданына кадәр барды. «Үлемсез полк» акциясендә катнашучылар 2,7 чакрым юл узды.

Чаллы шәһәрендә әлеге йөрешкә 76 мең кеше чыкты.

Каһарманга бюст

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгы көнендә, Казан кадет интернат-мәктәбе территориясендә Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов бюстын ачу тантанасы булды. Әлеге мәктәп Б.Кузнецов исемен йөртә.

Тантаналы чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Казан мэры Илсур Метшин, мәдәният министры Ирада Әюпова, Татарстан Ветераннар иҗтимагый оешмасының республика советы рәисе Хәбир Иштирәков, ветеранның тол хатыны Әлфия Филатова һ.б. катнашты.

Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында Б.Кузнецов белән шәхсән таныш булуын билгеләп үтте. «Бу нык энергияле, тиңсез кеше иде», – дип хәтергә алды ул. Әлфия

Филатова иренең кадет мәктәбенә аның исеме бирелү белән һәрвакыт горурлануын искә төшерде. Кадет интернат-мәктәбе укучылары Советлар Союзы Героена багышланган шигырьләр укыдылар, кадетлардан җыелган тынлы оркестр чыгышы да яңгырады.

Тупчы каберенә истәлек

Рейхстаг түбәсенә беренчеләрдән булып Җиңү байрагын кадаган татар солдаты Гази Заһитовның кабере янына мемориал туп урнаштырдылар. Гази Заһитов туган ягында – Башкортстанның Мишкә районы Яңагош авылында җирләнгән.

Мемориал тупны кую тәкъдиме белән Дәүләт Думасы депутаты Динар Гыйльметдинов чыккан. «Мин Гази Заһитовның якташы. «Атайсал. Кече Ватан» республика проекты кысаларында «Башнефтегеофизика» АҖ генераль директоры Рөстәм Адиевка мемориал постамент ясау идеясе белән мөрәҗәгать иттем», – диде ул.

Уръяды авыл Советы башлыгы Раик Заһитов әйтүенчә, тупның авырлыгы 400 кг, озынлыгы – 3 метр. «Мондый туплар Бөек Ватан сугышы елларында Кызыл Армиядә танкка каршы кулланылган була. Герой кабере янындагы мемориал туп Гази Заһитовның тормыш тарихын белергә теләгән туристларны җәлеп итәр дип уйлыйм. Алар авыл үзәгендә урнашкан музейга да барырга вакыт табарлар дип ышанам», – диде ул.

Тантанада Россия Федераль Куркынычсызлык хезмәтенең Башкортстан буенча идарәсе башлыгы Юрий Серышев, Башкортстан буенча эчке эшләр министры Роман Деев, Уфа гарнизонының хәрби прокуроры Виктор Радыгин, Мишкә районы хакимияте вәкилләре һәм башка кунаклар катнашкан.

Былтыр августта Мишкә районында Гази Заһитовка һәйкәл ачылган иде. Шулай ук ноябрь аенда кабере төзекләндерелде.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

«Казан утлары» журналы һәм «Мәдәни җомга» редакцияләре, әтисе

Мингазим Семигулла улы ГАЛИУЛЛИНның

вафат булуы сәбәпле, мөхәррир Гөлия Сәлахованың авыр кайгысын уртаклаша.

Рамазан ае әҗерләре

Рамазан ае нәтиҗәләре буенча, Татарстанда Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре тырышлыгы белән 780 мең кеше катнашында ифтар мәҗлесләре уздырылган.

Быел да «Рамазан - изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны ай буе дәвам итте. Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды битараф булмаган кешеләрдән акча җыеп, авыру балаларга ярдәм оештыра, аз керемле гаиләләрне азык-төлек белән тәэмин итә, ифтарлар уздыра, мохтаҗлар файдасына фитыр сәдакасы һәм фидия җыюны оештыра, сугыш качакларына ярдәм күрсәтә алды.

Марафон Татарстанның төрле район һәм шәһәрләрендә яшәүче 20 балага тернәкләндерү һәм дәвалану курсларын узарга мөмкинлек бирде. Мөселманнарга уңайлы булсын өчен «Зәкят» фонды фитыр һәм фидия сәдакаларын электрон рәвештә үзәкләштереп җыюны оештырды. Нәтиҗәдә фондның исәп-хисап счетына 2,4 млн сумнан артык акча килгән. Әлеге керем күп балалы гаиләләргә, ялгыз аналарга, ялгыз өлкәннәргә һ.б. мохтаҗларга тапшырылды. Моннан тыш, аз керемле гаиләләргә ай буена азык-төлек ярдәме дә күрсәтелде: ай буена «Зәкят» хәйрия фонды 550 дән артык мохтаҗ гаиләне 3,5 тоннадан артык азык-төлек белән тәэмин итте. Мохтаҗлар өчен махсус 34 хәйрия ифтары оештырылды. Хәйрия марафоны кысаларында барлыгы 4780 кешегә матди ярдәм күрсәтелде.

Ураза гаете уңаеннан башкалабызның М.Горький исемендәге үзәк мәдәният һәм ял паркында шәһәр күләмендә «Рамазан-Фест» бәйрәм чарасы үтте. Аны Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибәте оештырды. Бәйрәмдә дин әһелләре, җырчылар, акробатлар, цирк осталары чыгыш ясады, балалар өчен күпләгән остаханәләр оештырылды.

Гает көнне зиратка барып, мәрхүм булган кардәшләребезне искә алу да күркәм гадәт. Шул уңайдан елдагыча Казан шәһәренең Яңа бистә зиратында остазларны искә алу көне үткәрелде, анда күпләгән дин әһелләре, зыялылар җыелды. Дога кылу мәрасименә килүчеләрне 1998 елдан бирле әлеге чараны оештыручы Ильяс хәзрәт Җиһаншин каршы алды. Сүз уңаеннан, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре ел дәвамында каберләрне, чардуганнарны карап, чистартып, буяп торалар. Быел остазларны искә алу чарасы танылган мөгаллим, күпсанлы китаплар авторы Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк кабереннән башланды һәм күренекле дин эшлеклесе, Татарстанның беренче баш казые Габделхак Саматов кабере белән тәмамланды. Мәдрәсәгә кайткач, Коръән ашы, әрвахлар рухына багышлап, сүрә-аятьләр укылды. Остазларны искә алу чарасына кадәр мәдрәсә остазы Рәхимулла хәзрәт Коръән хәтем кылган иде.

Эльмира СИРАҖИ.

- Суринам Республикасы аборигеннары нибары 340 сүз ярдәмендә аралаша. Рус телендә 500 мең сүз (махсус терминнардан башка), инглиз телендә 1 миллион сүз бар.
- Французлар сузык авазларның төсмерләре саны белән таң калдыра. Мәсәлән, чын француз «о» сузыгын 13 төрле әйтә ала.
- Көньяк Африка Республикасында 11 дәүләт теле бар.
- Карачай-Чиркәс Республикасындагы абаза теле дөньяда иң катлаулы тел буларак Гиннесснең рекордлар китабына кертелгән.
- «О» хәрефе дөньяның 65 телендә бар.
- Дөньяда иң популяр телләр – инглиз һәм кытай телләре. Беренчесендә барлыгы 1,13 миллиард кеше, икенчесендә 1,11 миллиард кеше сөйләшә.

Башкортстанда халык саны кими

Рәсми мәгълүматлар раслаганча, Башкортстанда халык саны 2020 елда 24365 кешегә кимегән. Росстатның 1990-2020 еллар күрсәткечләрен анализласаң, бу биш ел элек белән чагыштырганда 26 тапкырга күбрәк.

1990 елларда Башкортстанда халык саны тотрыклы рәвештә, елына 2265 кешедән алып 34266 кешегә кадәр артып барган. Бу Үзәк Азия республикаларыннан кайтучылар белән бәйле, һәм өлешчә – советтан соңгы чорда туучылар саны зур булган. 2000 еллар башында кимү күзәтелә (2005 елда минус 15092 кеше). Аннары бер күтәрелеш чоры булып ала, һәм инде 2015 елдан башлап тотрыклы кимү башлана (2015 елда – 923 кешегә, 2020 елда – 24365 кешегә).

Бу тискәре динамиканың сәбәпләре нинди? Авырулар, кул салулар, миграция. Ни өчен шулай килеп чыга соң? Тулы анализ өчен башта Башстат хисабына күз салыйк, анда үлүчеләр саны күп булган районнар китерелгән. 2021 елның 11 аенда Башкортстанда 61541 кеше вафат булган. Үлем коэффициенты мең кешегә 16,8 тәшкил итте. Шул ук вакытта бу статистикада Башкортстан өчен үтә дә мөһим булган этник фактор исәпкә алынмый. Ә без анализлыйк.

Республикада иң күп үлүчеләр саны Борай районында теркәлгән – мең кешегә 25,9 кеше. Шулай ук Әлшәй (23,9), Бакалы (23,8), Чакмагыш (23,6) һәм Архангел (23,2) районнары да кызыл зонага керә. Монда сүз әлегә табигый сәбәпләр аркасында вафат булучылар турында бара.

Архангел районыннан тыш, бу муниципаль берәмлекләрнең барысы да республиканың күбесенчә татарлар яши торган көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш өлешенә керә. Ярый, Борай районы соңгы елларда иң коймкты баручы район санала, әмма Чакмагыш, Бакалы һәм Әлшәй районнары икътисади яктан төшеп калганнардан түгел. Бу районнарда авыл хуҗалыгы да алга киткән һәм алар нефть чыгару зонасына керә.

Монда сәбәпне – башкорт хакимиятләренең сәяси стратегиясеннән эзләргә кирәкмиме икән? Урал арты башкорт төбәгеннән аермалы буларак, алда санап үтелгән районнарның социаль-икътисади хәлен яхшырту өчен берминди махсус программа да үткәрелми. Гәрчә, монда социаль проблемалар шактый.

Әлбәттә, коронавирус пандемиясе дә үз ролен уйнады. Ләкин ковид бөтен төбәкләргә дә таралды, аның өчен административ чикләр юк. Димәк, сәбәп – медицина өлкәсендә, ә бу инде социаль мәсьәлә һәм бары тик дәүләт сәясәте белән генә бәйле.

Башкортстан хөкүмәте Рөстәм Хәмитов чорында башланган Урал арты үсеше программасын дәвам итеп кенә калмады, ә аңа бүленгән акчаны шактый арттырды һәм программаны алдагы елларга озайтты. Премьер-министр Андрей Назаров сүзләренчә, ул 2024 елга кадәр исәпләнгән һәм аны гамәлгә ашыру 111,7 млрд сум белән бәяләнә.

Чагыштыру өчен: Башкортстан бюджетында чыгымнар 267,6 млрд сум дип исәпләнгән. Ягъни республиканың болай да өстенлекле өлешенә берничә елда республика еллык бюджетының 40%ка якынын тоту планлаштыра. Моннан тыш, хөкүмәт Урал артының 2030 елга кадәр үсеш программасын да булдыру планлаштыра. Шул ук вакытта Урал артының социаль өлкәдә өстенлекле үсеше практикасы Мортаза Рәхимов вакытында ук киң куелган иде. Гәрчә, болар барысы да башка территорияләр үсешенә зыян китерә, чөнки физиканың билгеле бер кануны нигезендә, кайдадыр кимегән булса, кайдадыр арта. Мондый даими дискриминация территориясе булып һәрвакыт Башкортстанның көнбатыш өлеше кала.

Мондый тигезсез социаль-икътисади сәясәт идеологиясен хакимият контролендәге «экспертлар» да нигезләргә тырыша, алар арасында, мисал өчен, Башкортстан Мәдәният министрлыгының гуманитар тикшеренүләр үзәге хезмәткәре Азамат Буранчин да бар, ул моңа зур материал багышлаган. Соңгы 30 ел дәвамында ишетелгән дәлилләр һаман шул ук – берничди яңалык та юк. Тик менә бу 30 ел инде акчалар төпсез коега түгелә, ул арада реаль проблемалар күпмилләте республиканың башка өлешләрендә дә өлгергән. Шунысын да өстик, А.Буранчин милләтара мәсьәләләр өчен җаваплы вице-премьерның күптәнге дусты булып тора, ә ул, милләтара мәсьәләләр өчен җаваплы буларак, Р.Хәбиров хакимиятендә нәкъ менә башкорт сәясәтен алга сөрә. Республика хакимияте татар районнарында дәүләт пропагандасы һәм мәгариф системасы аша соңгы елларда җирле халыкны «башкортлаштыру» омтылышын да калдырмый.

«Башкаларга чокыр казыма – үзең шунда төшәрсең» дип юкка гына әйтмиләр шул. Бу юлы да шулай килеп чыкты. М.Рәхимов чорындагы кырыс авторитаризм режимы, этник протекционизм, бигрәк тә гуманитар (мәдәният һәм мәгариф) һәм административ өлкәләрдә ачык чагылды, иң креатив кешеләрнең республикадан читкә китүенә китерде. Ә бу, үз чиратында, республиканың тискәре имиджын тудырды – Башкортстан тышкы инвестицияләр һәм икътисади күрсәткечләр буенча аутсайдерлар арасында калды. Иртәме-соңмы бу бумеранг титуллы халыкка да китереп сугасы иде.

Икътисади фактор менә шундый «бумеранг» булып чыкты. Хроник икътисади җитешсезлекләр, ә иң мөһиме, депрессия һәм чарасызлык аркасында инде башкорт халкы республикадан читкә, беренче чиратта, Көнбатыш Себер төбәкләренә китә башлады. (Башкортстанда үткәрелгән фикер сорашу 29 процент оппонентның республикадан китәргә теләвен белдергән).

Көнбатыш Себер төбәкләрендә башкортларның саны арту, ниһаять, анда аерым милли-мәдәни автономияләр төзелүгә китерде. Бу моннан өч ел элек Федерация шурасы сенаторы Лилия Гомәрова җитәкчелегендә башкортларның федераль милли-мәдәни автономиясен төзергә дә мөмкинлек бирде. Экологик проблемалар аркасында миграциянең кинәт артуы Урал артының башкортлар яшәгән «рәсми» башкаласы – Сибай шәһәрендә күчемсез милек бәяләренең кыска вакытлы кимүенә дә китерде.

Башкортстан балаларның үзүзләренә кул салу саны буенча да Идел буе округында лидер булып тора. Моннан тыш, Башкортстан полиция хезмәткәрләре арасында үз-үзен үтерүләр саны белән дә танылды. Мәсәлән, күрше Татарстанда 2019 елда 258 кеше үз-үзенә кул салган, ә Башкортстанда – 729. Татарстанда кул салулар 100 мең кешегә 6,6 очрак тәшкил итсә, Башкортстанда – 20,1.

Туучылар санына килгәндә, республикада туучылар саны буенча лидер булып Бөрҗән районы кала, анда халыкның табигый үсеше - 34 кеше. Әмма анда да туучылар саны узган ел белән чагыштырганда кискен кимегән (2020 елда 341 булса, 2021 елда - 264). Башка башкорт районнарында да – шул ук күренеш. Әмма гаделлек өчен әйтергә кирәк, иң башкорт саналган Бөрҗән районында туучылар саны аз гына күбрәк булса да, нәкъ менә башкортлар яшәгән көньяк-көнчыгыш үзенә кул салучылар саны белән лидер булып тора. Әйтик, 2020 елда бу тискәре рейтингта беренче өч урынны Зианчура, Зилаер һәм Әбҗәлил районнары алган. Димәк, башкорт көньяк-көнчыгышына 30 ел буена даими рәвештә күп акча салынуга карамастан, моның файдасы юк. Биредә социаль хәл яхшырмый, икътисад үсми, бу территория дотацияле булып кала бирә.

Бөтен Башкортстан халкына килгәндә, 4 млн кеше дигән чик инде күптән кимегәндер. Әш монда демография йә миграция күрсәткечләрендә генә түгел. Уфа үзе дә миллионлы шәһәр статусын югалту чигендә тора (Волгоград һәм Пермь шәһәрләре кебек). Кайбер чыганаклар буенча, 2021 елда узган җанисәп барышында халык санын алучыларга «әгәр Уфада фатирларда ялгыз кешеләр яшәве ачыкланса, статистика өчен аларга «үлгән җаннар»ны өстәргә киңәш ителгән. Бу, янәсе, Башкортстан башкаласында миллион кешене «җыярга» кирәк дигән максат белән аңлатылган.

Йомгаклап әйткәндә, нинди нәтиҗәләр килеп чыга?

Беренчесе: Башкортстан 4 миллион халкы булган республика статусын югалтып бара.

Икенчесе: кайбер ярлырак төбәкләр белән чагыштырганда табигый сәбәпләр аркасында үлүчеләр саны азрак булса да, Башкортстанда үз-үзләренә кул салулар һәм миграция саны бик зур булып кала. Шулар нәтиҗәсендә Башкортстан алдагы берничә елда икътисади гына түгел, демографик күрсәткечләр буенча да Идел буе төбәкләре арасында лидерлыгын тулысынча югалтачак.

Өченчесе: бу тискәре тенденцияләр башкорт хакимиятенең милли планда тар карашлы сәясәте аркасында тагын да катлаулана. Шуңа да карамастан, демографик һәм икътисади-миграция факторлары Башкортстанның этник төзелешендә якын киләчәктә берминди реаль үзгәреш тә булмаячак дип әйтергә мөмкинлек бирә. Ягъни титуллы халык санының реаль артуы булмаячак. Димәк, 2015 елгы микро-җанисәп һәм 2010 елгы халык санын алу мәгълүматларыннан аерылып торган теләсә нинди мәгълүмат 2020 елгы җанисәпнең фальсификацияләнгән булуын аңлатачак.

Илнар ГАРИФУЛЛИН,
тарихчы, сәясәт белгече.

СЕМБЕР КАРЛЫГАЧЛАРЫ

Ульяновскиның Татар мәдәния💦 үзәгендә балалар иҗатын үстерүне күздә тоткан «Сембер карлыгачлары» өлкә фестиваль-конкурсы узды. Оештыручылар – өлкә татар милли-мәдәни автономиясе, Татар мәдәният үзәге.

Мәртәбәле конкурста өлкәнең авыл районнарыннан – Чардаклы, Ишеевка, Мәләкәс, Новоспасское, Николаевка, Барыш якларыннан һәм Ульяновск, Димитровград шәһәрләреннән килгән 82 бала ике номинациядә үзләренең иҗади сәләтләрен күрсәтте.

Фестивальне яшь җырчы Диләрә Шиһабетдинова гимнга әверелгән «Сембер карлыгачлары» җыры белән ачып җибәрде.

Татар мәдәният үзәге җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рамилә Сафина әйтүенчә, быел конкурста катнашырга теләүчеләрнең кимүе күзәтелгән. «Саф татар төбәге саналган Иске Кулаткыдан, җыр-моңга гашыйк милләттәшләребез яшәгән Яңа Малыклы, Сенгилей районнарыннан балаларның конкурста катнашмавы күңелне әрнетә. Шулай ук сәнгать җитәкчеләренең нигезнамәгә игътибар итмәүләре дә иҗат бәйгесенең сыйфатын төшерә. Малай һәм кызларның сәхнә костюмнарын да яңартасы бар. Татар халкы гомер-гомердән зәвык белән киенгән бит», – ди Р.Сафина.

«Кызганычка, яшь җырчыларның күпчелеге татар авазларын дөрес әйтми, сүзләрнең мәгънәсен аңлап бетерми. Шуңа күрә җырның асылы үзгәрә, тамашачы аны кабул итми. Сәнгать җитәкчеләренең балаларның телен камилләштерү өстендә армый-талмый эшлисе бар әле», – диде жюри әгъзасы, өлкә мәгариф үсеше институтының баш белгече, Татарстанның атказанган укытучысы Әлфия Абутдинова.

Фестиваль-конкурсның гран-приена Новоспасское районыннан Алинә Фәтхуллина лаек булды. Ул татар халык җырын акапелла башкарды. Галия Айбетова (Ульяновск), Аделия Тимербулатова (Чардаклы районы), «Булгар» халык ансамбле (Ульяновск) 1 нче урынны алдылар.

«Сәхнә түренә күтәрелгән һәр бала үзенчә талантлы. Сәнгать җитәкчеләренә вакытларын кызганмыйча алар белән җитди рәвештә шөгыльләнергә генә кирәк. Өлкә конкурсында катнашучы бала моңлы тавышка ия булу белән бергә, нота буенча сулыш алырга, сүзне дөрес әйтергә, зәвыклы итеп киенергә тиеш. Авыл культура хезмәткәрләре өчен мәдәният үзәгендә семинарлар ешрак узырылса, файдасы булыр иде. Ульяновск өлкәсе киләчәктә дә татар сәхнәсенә талантлы җырчылар бирергә бурычлы», – диде жюри рәисе Нурия Туркова.

Рузия ХӘЛИМОВА.

Галимҗан Ибраһимов – ОЛУГ ШӘХЕС

Татарстан Фәннәр академиясендә ике көн дәвамында татар әдәбияты классигы һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулу уңаеннан аның тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган «Галимҗан Ибраһимов һәм XX-XXI гасырлар татар белеме» дигән темага халыкара фәнни-гамәли семинар узды. Анда Төркия, Казахстан, Кыргызстан, Әзәрбайҗан мәмләкәтләреннән, Россиянең Казан, Уфа, Ижевск, Якутск, Мәскәү һ.б. шәһәрләреннән галимнәр, шул исәптән «Казан утлары» журналының 100 еллыгына багышланган чаралар кысаларында Татарстанга килгән кунаклар катнашты.

Семинар Академия фойесына куелган күргәзмә – соңгы елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан нәшер ителгән китаплар белән танышудан башланды. Семинар кысаларында Г.Ибраһимов әсәрләренең 15 томлык яңа басмасы да тәкъдим ителде. Әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов кунакларны томлыкларның эчтәлеге, үзенчәлекләре белән таныштырды. 15 томлыкта язучының мирасы һәм эшчәнлеге киң колачланган. 1974-1987 һәм 2000 елларда язучының әсәрләрендәге идеологик сәбәпләргә бәйле төшереп калдырылган урыннар кабаттан торгызылган. Моннан тыш академик басмада аңлатмалар да бирелеп барыла. Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина да Г.Ибраһимовның 15 томлыкта, язучы гына түгел, җәмәгать эшлеклесе, телче һәм тарихчы буларак та ачылуын, тупланма аның фәнни һәм иҗади мирасы, эшчәнлеге турында безнең күзаллауларны үзгәртүен искәртте.

Д.Заһидуллина шулай ук әдип һәм язучы иҗатының бүгенге көндә дә әдәбият белгечләренең игътибар үзәгендә тотылуы очраклы булмавын белдерде. Г.Ибраһимовның тормышы, иҗаты, эшчәнлеге, аның социаль һәм милли азатлык өчен көрәшен XX гасыр башындагы татарлар тормышындагы яңарыш барышыннан аерып булмый. Г.Ибраһимовның әсәрләрендә рухи ирек һәм кеше холкының көче үзәккә куела. Аның хезмәтләре татар халкының мәдәнияте тарихында әһәмиятле урын алып тора. Галимнәребез Г.Ибраһимовны тел һәм әдәбият белеме, татар теленең нигезләрен, яңа татар әдәбиятын формалаштыручыларның берсе, татар теленең реформаторы буларак та хаклы бәяли. Татар теленең орфографиясе, морфологиясе, синтаксисы, аларны укыту методикасы, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча аның тарафыннан язылган хезмәтләр нигездә XX гасыр башындагы фәнни юнәлеш-юлларны билгели. Ул шулай ук Татарстан матбугатын оештыручыларның берсе: «Эшче», «Кызыл Армия», «Кызыл яшьләр» газеталарының, «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») һәм «Мәгариф» журналларының беренче адымнары аның исеме белән бәйле. Фәннәр академиясе өчен исә Г.Ибраһимов исеме аерым әһәмияткә ия, ул 1920 елларда ТАССРның академик үзәкне җитәкләгән, халыкның рухи дөньясын төрле яклап өйрәнүгә юнәлеш тотып, галимнәрне һәм белгечләрне бергә туплап берләштерә алган.

Әдәбият галиме Хатип ага Миңнегулов Г.Ибраһимовның язучылык ягыннан зур талантка ия булуын таный. «Аның «Яшь йөрәкләр»е, «Диңгездә»се һ.б. повесть-хикәяләре проза жанрында язылган шигърь әсәрләр. Анда тел стилендә бер кимчелек табып булмый», – дип белдерде.

Г.Ибраһимов – шулай ук татарларны дөнья һәм аеруча тугандаш төрки халыклар белән бәйләп торучы төп күперләребезнең берсе. Казахстанның Гумилев исемендәге Евразия университеты ректоры Ерлан Сыдыков Г.Ибраһимовның язмышы Казахстан белән тыгыз бәйләнгән булуы турында сөйләде. Ул казах телендә иркен аралашкан, гомеренең бер өлешен казах далаларында үткәргән, балаларга белем биргән, казах язучылары белән аралашкан. Әдипнең «Казакъ кызы» романында казахларның XIX гасыр азагы – XX гасыр башындагы көнкүреш тормышы сурәтләнгән. Әдипнең өченче хатыны Хәдичә, иренең вафатыннан соң, тормышын Казахстан белән бәйләгән – Актүбә һәм Алма-Ата шәһәрләрендә яшәгән.

Г.Ибраһимовны Казахстанда шулай ук казах әдәбиятына нигез салган Магҗан Жумабаевның остазы буларак та беләләр икән. «М.Жумабаев казах халкы өчен инглизләргә Шекспир кебек кадерле. Татар әдибе күп кенә казах язучылары белән дустанә мөнәсәбәттә булган», – диде галим Е.Сыдыков.

Семинарда татар зыялыларының, дин әһелләренең башка төрки халыкларга йогынтысы зур булуы да искә алынды. «Манас» кыргыз-төрек университетының кафедра мөдире Османкун Ибрамов татар әдәбиятының Г.Тукай, Г.Ибраһимов һ.б. татар әдәбиятының күренекле вәкилләренең тәэсире нәтиҗәсендә кыргыз мәдәниятендә дә татар элементы барлыкка килүен искәртте. «Сугышка кадәрге һәм аннан соңгы мәдәнияттә һәм сәясәттә татарлар темасы зур һәм бик кызыклы. Монда сүз татар муллалары турында да, ул елларның вакытлы матбугаты турында да бара. Безнең беренче язучыларыбыз «Шура» журналында үз әсәрләрен бастырган», – диде ул.

Тарих фәннәре докторы Илдус Заһидуллин Г.Ибраһимовның мәкаләләре арасында көн кадагына суга, иҗтимагый фикерне үзгәртә, яңа юнәлешкә алып китә, тарихта кала торганнары да булуын әйтте. Әйтик, әдип 1910-1913 елларда татар матбугатында «Без төрекме, татармы?» дигән бәхәстә актив катнаша. Ул бу мәсьәлә буенча мәкаләләр язганчы, милләтләр тарихын, шул исәптән русныкын да, тирәнтен өйрәнә, үз мәкаләләрендә татар итеп формалашу юлларын да күрсәтә, милләтебезнең асыл якларын һәм кимчелекле якларына да игътибар юнәлтә, «Ул хезмәтләрендә академик милли тарихны язу бурычын да куя. Шиһабетдин Мәрҗанине үз чорының даһие, дип атый», – диде тарихчы.

Г.Ибраһимов, күренекле сул татар зыялыларының берсе буларак, язмыш кушуы буенча большевиклар сафына эләгә һәм 1920 елдан ТАССР кысаларында милли-дәүләт төзелешенә җәлеп ителә. Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков Г.Ибраһимовның, сәясәтче буларак, татар зыялыларының фикер бердәмлеген җимерүдә гаепләде. Әйтик, Садри Максуди, Йосыф Акчура кебек тирән белемле шәхесләр XX гасыр башында Башкортстанның татарлар күпләп яшәгән төньяк-көнбатыш өлешен Татарстан составына кертүне таләп иткән. Шул вакытта Г.Ибраһимов, аларга каршы чыгып, үзәк хакимият алдында зыялыларның позициясен шик астына куйган. Ул Башкортстан белән Татарстан җирләрен берләштерү яклы булган. «Бүгенге көндә дә шушындый ялгыш җибәрелү сәбәпле, татар-башкорт мәсьәләсе калкып чыга. Сәяси хата эшләнмәгән булса, милләтара мәсьәлә шул вакытта ук хәл ителгән булыр иде», – диде Д.Исхаков.

Галим Г.Ибраһимовның сәяси хатасын университетта укымавына, ягъни нигезле белеме булмауга китереп бәйләде. «Бу хәл дөнья политологлары янәшәсендә аеруча ачык күренә. Аның оппонентлары, киресенчә, университетта белем алган, милләтара мәсьәләләрне яхшы аңлаган», – ди галим. Шуңа да карамастан, Г.Ибраһимов оппонентларын «ахмаклар» дип атаган. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла исә, әдипнең эшчәнлегенә бүгенге күзлектән бәя бирмәскә кирәклеген әйтеп, Г.Ибраһимовның Башкортстан белән Татарстан җирләрен бергә кушу идеясен алга куюын берләшкән республиканың көчлерәк булырына инануыннан килүен искәртте. Тик үзәк хакимият биләмәләрне ул теләгәнчә бүлмәгән. Язучы һәм сәясәтченең белемен дә шик астына куярга кирәкми. Р.Зәйдулла Г.Ибраһимовның бик эрудицияле, укымышлы булуын ассызыклады һәм «Ислам мәдәнияте» дигән әсәренә игътибар юнәлтергә киңәш итте. Анда язучының Көнчыгыш, ислам мәдәнияте тарихларын бик яхшы белүе ачык күренә. «Ул Садри Максуди кебек Көнбатыш университетларын тәмамламаган, әмма аның үзлегеннән алган белеме тирән булган», – диде Р.Зәйдулла. Язучылар берлеге рәисе шулай ук ул елларда Г.Ибраһимов алдында Гаяз Исхакый кебек чит илгә чыгып китү, йә коммунизм идеяләрен алга сөрү кебек ике юл торуын искә алды. «Ул коммунистик юлны сайлаган. Аның каравы, Г.Ибраһимов татар әдәбияты, татар әдәби теле үсешенә зур өлеш керткән. Тел мәсьәләсендә исә язучы Зәки Вәлиди идеясен яклап чыккан, ягъни ике республика өчен дә татар теле әдәби тел булырга тиешлеген әйткән, – диде Р.Зәйдулла. – Әмма, З.Вәлиди үз истәлекләрендә язганча, алар анда бернәрсә дә эшли алмаган». Х.Миңнегулов та Г.Ибраһимовның четерекле, авыр вакытларда үзенең кыю фикерләрен әйтә алуына ихтирамын белдерде. «Аның кимчелекләре дә бардыр, әмма ул – зур фигура. Без аның мирасын барлаганда, ул заманның мохитен исәпкә алырга һәм бүгенге көнебез өчен авазлаш, файдалы булган якларын күбрәк күрергә тиешлебез», – диде ул. Галим шулай ук төп игътибарны Г.Ибраһимовның әдәби мирасын, хезмәтләрен башкаларга да җиткерү, әсәрләрен дөнья халыклары телләренә тәрҗемә итү мәслихәт икәнлеген дә искәртте.





Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Фирдәвес ХУҖИН

Бигрәк якын бер-берсеннән Каш белән күз арасы...

* * *

Бигрәк якын бер-берсеннән
Каш белән күз арасы:
Кешенең генә билгесез
Яшәү-үлем арасы.

Әллә тугач та өзелә
Сабыйның тормыш юлы.
Йөздә алырга бик мөмкин
Картлар соңгы сулышын.

Аллаһтан башка берәү дә
Бетерми моны белеп.
Хәерлесе дә шундадыр,
Утырмас өчен җебеп.

Хәерлесе: фанилыкта
Коръән буенча яшәү.
Сабырлык чиген чыкмыйча,
Киргәге чыкса – яшьнәү!

Яшьнәү, зыян китермичә,
Кимсетмичә беркемне.
Ата-ана, туганнарны,
Онытмыйча күршеңне.

Санамыйча гамәлләрне,
Савап эшләдем диеп.
Уң кул биргәндә, сулы тик
Аркадан каксын сөеп.

Мондый күренешләр сирәк
(Юкса ул гел дә кирәк).
Кем кемнедер рәнҗеткәннән
Чыдамый күпме йөрәк!

Мизгелдә гомер тотыла,
Ачыла җан капкасы.
Күзләрдә сүнеп тоташа
Яшәү-үлем арасы.
(Каш белән күз арасы).

Боларны уйлаучы сирәк,
Күпләргә барсы кирәк!
Байлык кирәк, күбрәк кирәк –
Чыдасын гына йөрәк!

"Өч көнлек дөнья" шаукымы
Көчлене генә таный.
Көчлеләр акчаны гына
Бөектән биек саный.

Каш белән күз арасыдай
Яшәүгә үлем якын.
(Әй, адәмнәр, уйланыйкчы)
"Дөнья малы – дуңгыз каны"
Ятадыр җиргә саркып.

Тыз да быз аның өстеннән
Чабыша күпләр шашып.
Мәңгелекне уйламыйча
Бүгеннең тәмен татып.
Яшәү үлемгә бик якын,
Үлем яшәүгә якын.

Көне җиткәч җир йөзенә
Һәркемне ала тартып.

НИ ҖИТМИ?

Сабый тугач, елап аваз сала,
Нәрсә даулый, аңа ни җитми?
Әнисеннән эзләгәнен тапкач,
Тынычлана – ирене сөтле.

Үскән саен көйсезлеге арта,
Игътибар күп,тик аңа җитми.
Иркәләүләр гел өстәлә тора,
Сөйләшүләр генә юк җитди.

Бакча – мәктәп: тәрбия һәм уку,
Болар – шиксез кирәк, файдалы.
Әти-әниләрнең шул чылбырда
Тәрбиясе кирәк дәвамлы.

Өлкәннәрнең вакытлары җитми,
Бар гамьнәре дөнья кууда.
Бала үсеп җиткән, тик тәртипсез,
Каян килгән чатнау буында?

Гаепләне эзләп шау-шу куба –
Җәмгыятьнең иң төп бәласе.
Бер-берләрен аңлау җитмәгәнгә,
Тупаслана йөрәк пәрәсе...

Балигъ затта эгоистлык көчле:
Таләп итә, аңа ни җитми?
Акча җитми, кәеф-сафа корып
Яшәмәкче һичбер көч түкми.

"Гаиләдә имгәк булгалый" дип,
Акыллыбаш әйткән кайчандыр.
Камиллеккә һәрчак омтылмасаң,
Тормыш болай гына җайланмый...

* * *

... Аллаһ тарафыннан кавемнәр дә
Тигез яратылган дөньяда.
Кайбер кавем бары үзен генә
Омтыладыр өстен куярга.

Басып ала, талый күршеләрен,
Үзе яши торган чик җитми.
Азчылыкны тәшкил иткәннәргә
Башка чара юктыр, тез чүкми.

Ирек киткән, газиз Ватан киткән,
Ана сөте генә китмәгән.
Ансы китсә, тагын ни кала соң?
Күз яшьләре һаман кипмәгән.

Телне тартып алмасыннар иде,
Ул – туганчы җанга тоташкан,
Шул телсез дә инде калдырсалар,
Катып калыр барсы торараш.

Мондый хәлне булдырмаска кирәк,
Гафләтлектән уян, и гавам!
Гасырлардан килгән үзгәлекне
Киләчәктә һаман ит дәвам.

Ә барыбер сорау ачык кала:
Адәмнәргә җирдә ни җитми?
Матурлыкны байлык алыштырган,
Ник данлыйбыз икән шул "чүп"не?!

Гомерләр тиз, мизгел кебек үтә,
Котылгысыз соңгы чик җитә.
Туфрактан адәм ничек калыкса,
Вакыт җиткәч туфракка китә.

Алабуга районы,
Илмәт авылы.

Рөстәм ЗАРИПОВ

Күп нәрсәне аңлап булмый Татар теленнән гайре...

ЯҢА "АЛМАГАЧЛАРЫ"

Мең тугыз йөз унҗидедә
Калыкты этрәк-әләм,
Таҗлы вирус тантанасы
Шуннан мантыйкый дәвам...
"Вак син, ә!"не аңлатамы,
"Вакцина" дигәннәре?
Ваклык сынавын узабыз,
Кадалсын энәләре!....
Күп нәрсәне аңлап булмый
Татар теленнән гайре,
Әллә ниткән аталышлар
Тик аңа гына бәйле...
Әйтик, "кутерьма" сүзенең
Чишмә башы – "күт-әрмә";
Тюрьма дигән төшенчәнең
Асыл мәгънәсе – төрмә.
"Каторга", димәк – катырга,
"Колхоз"да баш иҗек – кол,
Сибирь дигәннәре – Себер,
Байкал дигәне – бай күл.
Ковчег – капчыктан баш ала,
"Түш"тән ясалган "тушка",
Клеопатра – Көлия батыр,
Көлиядән – Золушка?
Гөлбикәгә Көлбикә, дип
Дәшкәнме үги ана?..
Җәбер-золымның төрлесен
Татый ятимә бала...
"Отец" – әтисе дигән сүз,
Ә "баламут" – мут бала.
"Балабол" – бала булудыр?
Безнең эз, сүз һәркайда...
Көләч, бул, дип кушылгандыр
Көлия атлы исем дә,
Клеопатра – Көлия батыр,
Патша булган Мисырда!
"Кремль" дигәннәренең
Татарчасы – "керемле".
"Теремок" дигәннәре дә
Аңлата кук "төрем"не...
Исемендә үк кисәтү
"Алма" атлы җимешнең,
"Яблоко"ның төп чыгышы
"Ябулык" дип ишеттем.
Оҗмахта булмый шул калып,
"Алма" дигәнне алып,
Ялгыштыргынмы милләтне,
Әллә Иблис атланып?
Безнең кавемгә каныгу
Җирдә еш кабатланган.
...Алмалы туган телебез,
Белмим, ничек сакланган?..
Милләт язмышы чагыла
Куштырнаклы сүзләрдә,
"Эээх, алмагачлары!" – дип
Җырлау язган безләргә...
Ватандаш урыс халкы да
Аны үзенчә суза,
"Эх, яблочко", – дип әйттерә,
Тыпырдап, кыза-кыза...
...Унҗиденче елдан бирле
Таҗ кия этрәк-әләм,
Таҗлы вирус шул бозымнан
Ялкынлы кайнар сәлам...

@

Ошбу билге – татарча эт,
Урысчадан калька.
Ни өчен, чөнки аларда
Бу тамга – "собачка"...
Украин "әкәм-төкәм" ди
Швед – "фил борыны",
Кытайлар – "тычкан" дип таный,
Фин – "мәче коерыгы".
Латыш, литвалар да "et" ди
"А" хәрефе өстәп...
Безгә дә туры килә ул,
Теккән кебек үлчәп...
...Башка атама булсын, дип
Көрәшмибез нишләп?
Безнең өчен иң кулае
Булыр кебек "ишәк"...
Кемдер әйтер, барс бик шәп,
Йә булмаса – бүре...
Җавап: "Алар бездә бик аз,
Ә чучкалар – мүре"...

БУ НИ БУ?

...Татар халкына кем, кайчан
биленәчә текте сакал?
Кем төшерде аны төпкә,
моңын буып, ниткән шакал?
"Кара алтын"ын кем имә,
җир күкрәгән чәйни-чәйни?
Милләтне талаучы өчен яз ни,
көз ни, кыш ни, җәй ни...
Татар гәҗит-журналларын
төп йорттан кем, нигә куды?
Почта чыгымнары белән
аренда хакымы буды?
"Без толерант, шуңа шулай", – дип,
түбәтәй чөйик микән?
"Сау бул, татар матбугаты,
хуш, туган тел", – диик микән?..

СТАЛИННЫҢ

● Антонов Василевский белән.

(Дәвамы. Башы 16-17 нче саннарда).

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Чынлыкта, Василевский күңелендә Генштаб башлыгы вазифасыннан китү теләге күптәннән төенләнгән була. Хәрби чыганакларда расланганча, 1945 ел башланганда ул Балтыйк буендагы гаскәрләрнең хәрби хәрәкәтләренә юнәлеш бирә, ә менә 13 гыйнварда башланып киткән Көнчыгыш Пруссия операциясен үткәрү мәшәкатьләре, аны планлаштыруга шәхсән үзе житәкчелек иткән Сталин иңнәренә төшә. Әмма февраль башында Югары Башкомандующий вакытлыча Мәскәүне калдырып торырга мәҗбүр, чөнки аны Кырымда АКШ һәм Бөекбритания житәкчеләре белән очрашу көтә. Ә инде, бер үк вакытта, илнең оборона халык комиссары урынбасары да булып торган маршал Василевский, Сталинның һәм Генштаб буенча урынбасары Антоновның Ялта конференциясендә катнашу өчен Кырымга китүләре сәбәпле, турыдан-туры үз вазифаларын башкару өчен Мәскәүгә әйләнеп кайта һәм Көнчыгыш Пруссия һөҗүм операциясенә житәкчелек итәргә керешә. Ялта конференциясе исә Кырымда үтә. СССР житәкчесе Иосиф Сталинның 4-11 февраль көннәрендә АКШ президенты Франклин Рузвельт һәм Бөекбритания премьер-министры Уинстон Черчилль белән сөйләшүләр алып барган тарихи урын – Ялтадан өч чакрым чамасы ераклыктагы Ливадия бистәсе.

18 февральдә кичен, Ялтадан кайтып төшкән Сталин Василевскийга, фронт командующийларына булышу өчен Көнчыгыш Пруссиягә китәргә тәкъдим итә. Василевский форсаттан файдаланып калырга карар кыла һәм Югары Башкомандующийдан үзен Генштаб башлыгы вазифасыннан азат итүен сорый. Сәбәбе гаять дәрәҗәдә җитди: 34 ай дәвамында Генштаб башлыгы булып торган чагында Василевский 22 ай буена фронтлардан кайтып кермәгән икән. Дөрес, әгәр дә шул көнне 3 нче Белоруссия фронты командующие армия генералы Иван Черняховскийның вафаты турында хәбәр килеп ирешмәсә, бәлки бу гына мөһим карар кабул итәргә житәрлек дәлил булып та тормас иде. Димәк, Сталинның андый карарга килүен, нәкъ менә Василевский үтенече белән Черняховский вафатының бер көнгә туры килүе белән аңлату дөресрәк. Сталин исә тиз ризалаша һәм Василевскийны 3 нче Белоруссия фронты командующие итеп билгеләргә куша. Нәтиҗәдә Александр Михайлович Кенигсбергны басып алуга житәкчелек итә һәм 19 апрельдә икенче мәртәбә « Жиңү» ордены белән бүләкләнә. Шунысы да бар: әле 1944 елның җәендә үк, Белоруссия операциясе уңышлы тәмамланган көннәрдә, Сталин Василевскийга Алманияне жиңгәннән соң, аны Ерак Көнчыгыштагы совет гаскәрләренең Башкомандующие итеп куярга жыенуын ирештерә. Маршалга Япониягә каршы кампанияне әзерләүгә 27 апрельдә кушыла һәм төгәл ике айдан аның житәкчелегендә Маньчжурия стратегик һөҗүм операциясе планы әзерләнеп бетә. 1945 елның 5 июлендә генерал-полковник формасындагы, документларында Васильев фамилиясе күрсәтелгән Василевский Чита каласына килеп төшә һәм 30 июльдә Дәүләт оборона комитеты (ГКО) директивасы белән Ерак Көнчыгыштагы совет гаскәрләренең Башкомандующие итеп билгеләнә.

Февраль аеннан исә Генштаб башлыгы вазифасына керешкән армия генералы А.Антонов житәкчелегендә Берлин операциясе планы эшләнә һәм ул 1 апрельдә Ставка тарафыннан хуплау таба. Кайбер чыганакларга нигезләнеп, Алексей Иннокентьевичның 1944 елның җәй айларыннан ук Берлин турында уйлана башлавын искәртеп үтү шулай ук артык тоелмас. Әлбәттә, Алмания ягы җиңелү килешүенә кул кую белән генә Советлар Союзы өчен яу тәмамланмый, гитлерчыларны тар-мар иткән гаскәрләрне Ерак Көнчыгышта яңа сугыш хәрәкәтләре көтә. Ниһаять, Антонов белән Василевский житәкчелегендә Япониягә каршы оештырылачак кампаниягә әзерлек эшләре июнь башларында төгәлләнеп бетә. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1945 елның 17 июленнән алып 2 августына кадәр сузылган Потсдам конференциясендә армия генералы Антонов АКШ белән Бөекбритания вәкилләренә Япониягә каршы ясалачак операциянең әзер булуы турында белдерә. 6 августта америкалылар Япониянең Хиросима каласына атом бомбасы ташлый, ә икенче көнне Сталин, 9 август иртәсеннән японнарга каршы хәрби хәрәкәтләр башлау турындагы боерыкка кул куя. Нәкъ шул көнне янкилар Япониянең тагын бер каласы Нагасакины атом-төш коралы кулланып, жир белән тигезли. Совет гаскәрләре исә өч атна эчендә японнарның Квантун армиясен туздыра, нәтиҗәдә Маньчжурия, Корея һәм Сахалин белән Курил утраулары дошманнан азат ителә.

Сугышлар тәмамлану белән Антонов демобилизация үткәрү белән шөгыльләнә, 1946 елның мартыннан – кабат Генеральштаб башлыгының беренче урынбасары вазифасында.1948 елның ноябрендә Сталин Советлар Союзы маршаллары Булганин белән Василевскийның тәкъдимнәрен кабул итмичә, Генштаб башлыгы вазифасына Штеменконы куярга карар кылганнан соң, Антонов Кавказ арты хәрби округына «күчә». Совет Армиясе полковнигы, техник фәннәр докторы, язучы Зәки Зәйнуллин раслаганча, үз милләтеннән баш тартырга ризалашмаган Алексей Иннокентьевичның Генштаб башлыгы вазифасына куймауларына хәтере калганмы? Әллә инде Штеменко үзенең беренче урынбасары кәнәфиендә башка генералны күрергә теләгәнме? Кызганыч, бу сорауларга әлегәчә төгәл җавап юк һәм ул чактагы вәзгыять билгесез көе кала. Гәрчә армия генералы Антонов, һәрвакыттагыча, яңа вазифасында да сынатмый: әүвәл Кавказ арты хәрби округы командующие Советлар Союзы Маршалы Фёдор Иванович Толбухинның беренче урынбасары вазифасында хезмәтен дәвам иттерә. 1950 елның гыйнварыннан исә командалык вазифасында: 1954 елның яз урталарына чаклы, ягъни 4 елдан артыграк ул – Кавказ арты хәрби округы командующие. Апрель аенда Антонов Тбилисидан Мәскәүгә әйләнеп кайта һәм Генштаб башлыгы Советлар Союзы Маршалы Василий Данилович Соколовскийның беренче урынбасары итеп билгеләнә, бер үк вакытта Оборона министрлыгының коллегияләр әгъзасы да булып тора. Аның тормышындагы соңгы үзгәрешләрнең нәкъ менә Сталин үлеменнән һәм Берияне атканнан соң ясалуына игътибарны юнәлтү аеруча мөһим.

Әмма А.Антонов бу вазифада бер елдан чак кына артыграк булып өлгерә: 1955 елның 14 маенда Варшава килешүе төзелә һәм ул шул килешүгә кул куйган илләрнең Берләшкән хәрби көчләре штабы башлыгы вазифасына билгеләнә, бер үк вакытта Сәяси-киңәшләшү комитетының Генераль секретаре итеп тә сайлана. Идарә аппараты эшчәнлеген көйләү эшләре һәм дус илләр армияләре гаскәрләренең бердәм хәрәкәт итүләренә өйрәтүләрне оештыру – бары да Мәскәү каласында урнашкан Штабның беренче башлыгы Алексей Иннокентьевич җилкәсенә төшә. Аның союздаш илләр армияләре тарафыннан оештырылган күнегүләрдә шәхсән катнашуын искәртү дә урынлы. Әлеге мөһим вазифаны милләттәшебез гомеренең соңгы көннәренә чаклы, 7 ел дәвамында бик тә нәтиҗәле, төгәл һәм бөтен көчен салып башкара. 1962 елның 18 июнендә Мәскәү каласында вафат була. Шунысы бар: Бөек Ватан сугышында «Жиңү» орденыннан (№12 – 4.06.1945) тыш, өч Ленин, дүрт Кызыл Байрак, ике I дәрәҗә Суворов, I дәрәҗә Кутузов, I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм чит илләрнең 14 орден-медаленә лаек булган милләттәшебезнең кылган олы эшләре тиешенчә бәяләнмәве бик күпләргә, шул исәптән, илнең хәрби житәкчеләренә тынгы бирми.

2003 елда, мәсәлән, Бөек Ватан сугышында катнашкан бер төркем СССР һәм РФ хәрби житәкчеләре ил президенты В.В.Путин исеменә хат белән чыга. Армия генералы А.И.Антоновка Россия Герое исеме бирүне үтенеп кул куючылар – Советлар Союзы Маршаллары Сергей Леонидович Соколов, Дмитрий Тимофеевич Язов, Виктор Георгиевич Куликов, Василий Иванович Соколов һәм армия генераллары Анатолий Иванович Грибков, Валентин Иванович Варенников, Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев. Исемлеккә иң ахырдан, һәрвакыт үз милләте өчен жан атып яшәгән Хәрби фәннәр академиясе президенты, хәрби фәннәр докторы һәм тарих фәннәре докторы академик Мәхмүт Әхмәт улы имзасы төшүе, инициативаның нәкъ менә аннан чыккан булуын искәртә. Инде мөһим тарихи документка әйләнгән шул хаттан кайбер өземтәләр биреп үтик: «2003 елда Курск сугышына 60 ел тула. Бу орышлар нәтиҗәсендә совет гаскәрләре тарафыннан стратегик өстенлек яуланды... Әлеге һәм башка стратегик операцияләрне үткәрүдә армия генералы Алексей Иннокентьевич Антоновның таланты бәһаләп бетергесез зур роль уйнады...

Варшава килешүенә кергән илләрнең хәрби көчләре Штабы башлыгы вазифасын башкарган чагында Антонов идарә аппаратын оештырды, уку-укыту процессын җайга салды һәм заманча шартларда гаскәрләрнең бердәм хәрәкәтләрен тәэмин итә алуларына иреште...»

Хатка кул куючы хәрби житәкчеләр раслаганча, «7 ел дәвамында Советлар Союзы һәм аның союзникларының дәүләт куркынычсызлыгы рулендә торган Антонов, чын мәгънәсендә үз вазифасында «яна».

Хатның соңгы өлешендәге: «Армия генералы Антонов – «Жиңү» ордены белән бүләкләнгән бердәнбер генерал, әмма аның фамилиясе хәрби житәкчеләрнең Ватан каршындагы үзгә казанышлары өчен булдырылган озын исемлеккә кертелмәгән...

А.И.Антонов, лаек булуына карамастан, ни маршал, ни Советлар Союзы Герое була алмады. Үз-үзен аямаучан бу шәхес бөтен халкыбыз тарафыннан яуланган Бөек Жиңүгә бәһаләп бетергесез саллы өлеш кертте, әмма аның эш-гамәлләре тиешенчә бәяләнмәде. Ул искиткеч талантлы хәрби житәкче, булдыклы офицер һәм үз Ватанының чын патриоты иде», – дигән фәһемле юллар аерым игътибарга лаек.

Ни гаҗәп, яуда сыналган Бөек Ватан сугышы ветераннарының үтенечләре җавапсыз кала. 2005 елда шундый ук эчтәлектәге үтенеч Белоруссия президенты Александр Лукашенко белән Санкт-Петербургның вице-губернаторына юллана. Аларның икесенең дә хатка илтифатсыз калмауларын ассызыклау мөһим. Губернатор урынбасары Антоновка Россия Герое исеме бирү мөмкинлеген илнең Оборона министрлыгында карау тәкъдиме белән чыгуын үтенеп, хатын Ленинград хәрби округы командующиена җибәрә. Сүз уңаеннан, хаталануларны кисәтү максатыннан чыгып, кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертү урынсыз булмастыр. Беренчедән, үтенеч хатларының һәр ике очракта Хөкүмәт бүләкләре бирү мәсьәләләре буенча Россия ассоциациясе президенты ярдәмчесе Алексей Анатольевич Павликов тарафыннан күндерелүе мәгълүм. Икенчедән, Санкт-Петрбургның вице-губернаторы үтенеч белән Ленинград хәрби округының кайсы командующиена мөрәҗәгать итүе билгесез. Чөнки 2005 елның 9 мартында армия генералы Валентин Сергеевич Бобрышевны армия генералы Иван Евгеньевич Пузанов алыштыра. Бөек Жиңүнең

● Генераллар Антонов һәм Штеменко штабта эш вакытында.

ХӘРБИ КИҢӘШЧЕСЕ

50 еллыгы алдыннан бирелгән үтенечкә җавап (№173/3/65776) исә Оборона министрлыгы Баш кадрлар идарәсенә караучы 3 нче идарәнең 3 нче бүлеге башлыгы С.Лебедев тарафыннан 16 сентябрьдә имзаланган. А.А.Павликов исеменә килгән хаттан өзек:

«Хәзерге вакытта, Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклар өчен, Россиянең дәүләт бүләкләре тапшырылмый... РФ президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре бирү буенча комитет, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны бүләкләү турындагы үтенечләрне караганда, фәкать искәрмә рәвешендә, сугыш вакытында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителеп тә, гамәлгә керми калган бүләкләү документларын гына карый. РФ Оборона министрлыгының Үзәк архивында А.И.Антоновны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим иткән мәгълүматлар юк. Хәзерге вакытта андый үтенеч белән чыгу урынсыз, чөнки үз яугирләрен бүләкләү хокукына фәкать хәрби частьларның командирлары гына ия.

Шушылардан чыгып һәм гамәлдәге кануннарга нигезләнеп кенә А.И.Антоновка Россия Герое исеме бирү мөмкин түгел».

А.Антоновның Гродно каласында туган булуын исәпкә алып, аңа Белоруссия Герое исеме бирү турында күндерелгән үтенечкә Минск каласыннан җибәрелгән җавап хаты имзаланган көн – 2005 елның 27 апреле. Президент аппараты җитәкчесе урынбасары О.В.Пролесовский кул куйган хаттан (№15/8-637) өземтә: «Белоруссия республикасы Законында 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклар өчен бүләкләү каралмаган. Шунлыктан, Сезнең үтенечегезне канәгатьләндерә алмыйбыз.

Шул ук вакытта, Гродно каласындагы бер урамга армия генералы Алексей Иннокентьевич Антонов исеме бирелгән булуын һәм 2004 елның 3 июлендә Белоруссияне алман фашистлары баскыннарыннан азат итүгә 60 ел тулу уңаеннан, аның якты истәлеге хөрмәтенә мемориаль тактага куелуын хәбәр итәбез».

Ихтыярсыздан, бездә гел генә ике төрле мөнәсәбәт хөкем сөрүен таныргa туры килә. Оборона министрлыгы җавабыннан күренгәнчә, Россия кануннары буенча, Алтын Йолдызга тәкъдим ителеп тутырылган документ булмау аркасында Антоновка Россия Герое исеме бирү «мөмкин түгел» икән. Ә менә Башкортстанның яңа башлыгы Радий Хәбировның абруен күтәрү өчен тагын бер татар баласы генерал-майор Миңнегали Шәйморатовка ул исемне бирү мөмкинлеген таптылар Оборона министрлыгында, андый документ юк дип тормадылар. В.В.Путин Указга кул куйган көн – 2020 елның 30 марты (№230).

Янә бер мисал. 2008 елның 8 мартында ил президенты Владимир Путинның 327 нче санлы Указы дөнья күрде. Анда Мамадыш районының Албай авылында туган Георгий Семенович Смирновка Россия Герое исеме бирелүе турындагы юллар ташка басылган. Рус милләтеннән булган кече лейтенант Смирнов 81 нче ерака оча торган авиация полкында звено башлыгы булып хезмәт итә. 1941 елның 31 октябрендә төнлә, хәрби бурыч үтәп кайтып килүче ТБ-3 самолетының төп багы тишелә, бер двигателе һәм радиостанциясе сафтан чыга. Шул сәбәпле, составында звено командиры Г.С.Смирнов, укчы-бомбага тотучы лейтенант В.П.Кириллович, һава укчысы кече сержант А.А.Захарченко һәм укчы-радист кече сержант М.М.Зотовтан торган экипаж үз аэродромын бик озак эзли, әмма таба алмый. Иртәнге дүрттә ягулык бетә һәм командир ирексездән Орджоникидзе краеның (1943 елдан – Ставрополь крае) Александров районы Северное авылы янында самолетын җиргә төшерергә карар кыла. Куе томан, берни күренми, нәтиҗәдә самолет ерынтының тау битенә килеп бәрелә. Край үзәге Ворошиловск каласындагы (1943 елдан – Ставрополь каласы) 1626 нчы санлы эвакуация госпиталендә табибләр авыр яраланган Георгий Смирновның гомерен саклап калу өчен тәүлектән артык көрәшә, әмма үлем җиңә: 2 ноябрьдә якташыбыз бакый дөньяга күчә. Госпиталь җитәкчелеге тарафыннан тутырылган статкартада һәм башка хәрби документларда шул көн күрсәтелүенә карамастан, хәзерге чыганакларда Смирновның 1941 елның 9 ноябрендә үлүе турында язалар. Бу, тәгаен, 5 ноябрьдә аңа лейтенант чины бирүне аңлап бетермәү сәбәпле туган хаталанудыр. Югыйсә моңа һич тә аптырыйсы юк: чин бирү турындагы документ Геройның вафатына кадәр тутырылган һәм ул, һичшиксез, лейтенант булып калырга хаклы.

Сугыш башланганнан алып, лейтенант Смирнов самолеты 22 хәрби очыш ясый, дошман өстенә төрле калибрдагы 17 тонна бомба ташлый, гитлерчыларның өч истребителен, дүрт танкын яндыра. Википедиядә расланганча, «1941 һәм 1942 елларда лейтенант Смирнов ике тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, тик документлары «югалу» сәбәпле мактаулы исем бирелми». Бу турыда мәгълүм булуга, туганнары гаделлеккe торгызу эшенә керешә. Эзләнүләр ярты гасыр тирәсе дәвам итә һәм, ниһаять, малае Геннадий Владимир Путин исеменә хат язганнан соң, Георгий Смирновка Россия Герое исеме бирелә. Бу очракта да геройга тәкъдим итеп тутырылган документның булмавы мәсьәләнең уңай чишелешенә комачау тудырмый. Якташыбызның җир куенына иңдерелгән урыны – Ставрополь каласының Комсомол тавында ясалган «Мәңгелек дан» һәйкәле янындагы туганнар каберлеге.

Ни аяныч, Бөек Ватан сугышы белән бәйле һәм татар халкына кагылышы булган сәер хәлләрнең очына чыгарлык түгел. Милләтебезнең каһарман улы, данлыклы диверсант-разведчик Даян Мурзин үзе оештырган партизаннар бригадасы белән Словакиядә, Богемиядә һәм Моравиядә тиңсез батырлыклар кылып, дөньяның күп илләрендә танылу таба. Майор чинындагы комбриг Мурзин дошман тылында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булырлык диверсияләр оештыра, «Олы җир»гә кыйммәтле мәгълүматлар җиткереп тора, шул территорияләрдә азатлык көрәше җәелдерүгә саллы өлеш кертә, 16 нчы танк дивизиясе командиры генерал-лейтенант Дитрих фон Мюллерны әсир төшерә. Әле хәтта хәрби антына хыянәт иткән Кызыл Армия генерал-лейтенанты Андрей Власов та нәкъ менә аның партизаннары ятьмәсенә эләгә. Әмма 1944-1945 елларда Ватан алдында күрсәткән батырлыклары өчен «кара генерал» Даян Баян улын орден түгел, хәтта медаль белән дә бүләкләмиләр. Күрәсең, мондый гаделсезлекләр күбрәк чех һәм словак ягын гына борчыгандыр. Шулай дип расларга тулы нигез бар. 2004 елның сентябрендә Ян Жижка исемендәге 1 нче Чехословак партизаннар бригадасы оешуга һәм аның Словакиядән хәзерге Чехия территориясенә үтеп керүенә 60 ел тулу уңаеннан Прагада үткән тантаналы чаралар белән бәйле хәлләр – шуңа саллы дәлил. Анда, 2000 елдан Чехия Республикасы Армиясенең отставкадагы полковнигы Даян Мурзинны, иң кадерле кунак буларак кабул итәләр, хөрмәтнең иң зурысын күрсәтәләр. Әлбәттә, көрәштәш дуслары моның белән генә чикләнми: бригаданың ветераннар советы рәисе Честмир Смолка һәм дошман тылында көрәш алып барган Чехия белән Моравиянең элекке партизаннары Даян Мурзинга Россия Герое исеме бирүләрен үтенеп президент В.Путинга мөрәҗәгать итә. Даян Мурзинның 2005 елда Уфада нәшер ителгән «Дошман тылындагы фронт» китабындагы берничә дистә чехословак партизаны кул куйган хаттан өземтә:

«Хөрмәтле Владимир Владимирович! Безнең барыбызга да Даян Мурзин командалыгында Словак милли восстаниесе үзегеннән <…>Прагага чаклы ифрат авыр партизан көрәше юлы үтәргә туры килде. Без, турыдан-туры партизаннар сугышында катнашучылар, аны иң булдыклы оештыручыларның берсе һәм гаять дәрәҗәдә кыю, тәвәккәл, гайрәтле командир буларак беләбез. Ул кыска гына вакыт эчендә партизаннар отряды оештыра алды. Соңрак, өзлексез дәвам иткән сугышлар барышында, отряд эре партизаннар бригадасына әверелде, һәм Мурзин аның белән сугыш тәмамланганчы командалык итте... <…>

Майор Мурзинның фәкать исемен генә ишетү дә фашистлар арасында курку тудырганына күпләребез шаһит. <...> Безнең бригада партизаннары тарафыннан меңнәрчә фашист солдаты һәм офицеры юк ителде, хәрбиләр һәм техника төялгән 68 эшелон яр астына җибәрелде...

Чехословакия җирендә алып барылган тигезсез сугышларда Д.Мурзин ике тапкыр яраланды һәм контузия алды. <...> Безнең халык Мурзинны үзенең милли герое дип игълан итте, урамнар, мәйданнар аның исемен йөртә, ул – Чехословакиядәге күп кенә кала һәм авылларның мактаулы гражданы. <…> Д.Б.Мурзин ЧССР хөкүмәтенең 10 югары бүләгенә лаек булды... <…>

Бүген үзебезнең зур бәйрәмебез – Словак милли восстаниесенең 60 еллыгы алдыннан Сезгә мөрәҗәгать итәбез һәм Даян Баян улы Мурзинга Россия Герое исемен бирүегезне үтенеп сорыйбыз» (5 – 6 битләр).

Шаккатмалы хәл, ветераннар үтенеченә колак салучылар табылмый – хат җавапсыз кала. Бу серле вакыйганың армия генералы Алексей Антоновка карата күрсәтелгән мөнәсәбәткә гаять дәрәҗәдә аваздаш, охшаш булуы ярылып ята. Хәер, алдагы мисаллардан күренгәнчә, мондый сәер, үзгә мөнәсәбәтнең традициягә әйләнгәнлеге бик яхшы шәйләнә. Шуңа да, РФ Оборона министрлыгы тарафыннан бертөрле мәсьәләләргә ике төрле караш белдерелү сере аңлашылмавы, һичшиксез, күпләрне күңелсез уйларга этәрә.

Рәис ЗАРИПОВ.

КАЙТ, БӘГЪРЕМ!

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

Станциянең ерак почмагында аларның составы икенче көн тора инде. Ник тоткарлауларын беркем әйтә алмый. Солдатлар гына түгел, офицерлар да билгесезлектән җәфа чигә: әле җәйнең эссе кояшына нәүмиз булып, маңгайларын сөрткәлиләр, җилкә кашый-кашый арлы-бирле йөренәләр, әле бергә җыелалар да, тыннары беткәнче суырып, тәмәке көйрәтәләр...

Ял итү өчен вагоннан унбиш адым гына ара билгеләнгән. Һәр вагон янында мылтыклы сакчы йөри. Әле анда, әле монда төрле командалар яңгырый, менә бервакыт, сүгенү сүзләре белән мәхәббәт җырлары бергә укмашып, нindидер сәер тавышлар симфониясе барлыкка китерә...

Бер читтә чирәмле калкулык буенда ике егет утыра. Татарлар. Йөзләре, тән хәрәкәтләре, карашлары ук шуңа ишарәли: алар Татарстаннан. Казан читендәге бер кырда тукталып калганнар икән, монда сихер-тылсымның да шаукымы булгандыр, дип уйларга туры килә. Аларны туган якларыннан алып китәсе килмәгән кебек, поездлары җиргә береккәндәй тора бирә...

Егетләрнең Мансур исемлесе аеруча моңсу-ямансу күренә. Аның йөзе качкан, тәмәкесен дә ярсынып суыра, еш кына станция ягына карап ала. Нидер күзәтә, кемнедер көтә, ахры...

Аның янәшәсендә тыныч кына, нindидер битараф йөз белән моңаеп утырган солдат дустын тынычландырмакчы була:

– Ярар инде, артык йөрәгеңә алма. Якын ара түгел, егерме алты чакрымны бер тында гына килеп җиту... ай-йай...

– Ну, Наил!.. Килә ул, килә... «Киләм» диде бит. Димәк, таш яуса да килә!.. Шундый кеше. Минем әби дә килгән. Килеп өлгергән!..

Берни аңламаган Наил сорамый булдыра алмады:

– Нинди әби? Иләсләнеп көтүең белән җиңеләя башладың инде әллә?

Мансур теләмичә генә сөйләп китте:

– Аерым тарих бар безнең нәселдә... Шушы тирәләр булырга тиеш, –Мансур як-яктагы урман-кырларга карашын йөртеп алды. – Минем бабайның эшелоны да шушындыйрак станциядә туктап торган.

– Шуннан нәрсә булган? Килгән... Озаткан... Киткән...

– Юу-ук... Килеп кенә китмәгән, шул ярты сәгатьлек очрашуда яңа гомергә, зур тормышка оеткы салып киткән...

– Нәрсә димәкче буласың, һич аңламыйм...

– Их, язучы булсам, мин ул очрашу хакында риваять язар идем... Әйе, йөрәк белән кичерергә, җан белән тоярга кирәк бу тарихны. Бабайларны алып киткән сугышны аңлау өчен, окопларга атышлар турында түгел, нәкъ менә тылдагы шундый очрашулар хакында хикәяләр, бәяннәр кирәк! Их, язучы булсаммы?!

* * *

Сәлимгәрәй поездга утырыр алдыннан тагын авылга хат язып салды. Хәрби хезмәткә әзерләү лагереннан кузгалып киткәч, бер атнадан Казанда булабыз, диделәр. Станциясен дә әйтteләр, көнен дә, сәгатен дә... Әйтмәсләр дә иде. Әйтергә тиеш тә түгелләр иде... Сәлимгәрәй кат-кат сорый торгач, эшелон башлыгы урынбасары, сер итеп кенә, колагына ук килеп әйтте: «Шул көнне, шул сәгатьтә Казан янындагы шундый-шундый станциядә булабыз», – диде.

Кат-кат сорасаң да әйтмәсләр иде эшелонның фронтка бару графигын. Сугыш кызып кына килгән чак. Фронтта алдыра алмагач, дошман совет тылындагы диверсияләрен бермә-бер арттырды. Бөтен юл маршрутлары, расписаниеләр, донесениеләр яшерен сер булып санала...

Башка берәү булса әйтмәс иде, эшелон башлыгы урынбасары татар булып чыкты. Казан татары булмаса да, «Казан» сүзен ишеткәч, шундук үзгәрде. Беренче очрашуда кашын җыерып каршы алган иде, әмма шул тылсымлы сүзне ишетү белән, Сәлимгәрәйгә туганына караган кебек карый башлады. Сүзләре килеште аларның, сугышка кадәр икесе дә укытучы булып эшләгән икән. Мансур исемле менә шул татар кешесе кайсыдыр бер очрашуда Сәлимгәрәйнең колагына кайчан Казан тирәсендә булачакларын килеп әйтте. «Хат язсаң, татарча яз, турыдан-туры әйтмә, читләтебрәк белгертергә тырыш», – дип искәртергә дә онытмады. Һәр хатның махсус кешеләр тарафыннан укылуын, тикшерелүен үзе дә белә Сәлимгәрәй. Тагын шуны да белә: хат ахырында «Победа будет за нами!» яисә «Да здравствует Сталин! За Сталина!» дип өстәп язып куйсаң, укып та тормыйлар...

Авылга хат язганда ул шулай дип куйды: «За Сталина, за Родину жизнь отдам!» дигән сүзләрнең астына кат-кат сызгалады... «Туган җирем өчен, якыннарым, әткәм-әнкәм өчен, сөйгән ярым өчен» дисә, әйбәтрәк булган булыр иде дә... «Сталин» исеме керсә, хат барасы җиренә тизрәк барып җитә шул...

Хат авылда калган, вәгъдәләшкән кызы Гөлчирәгә атап язылган иде. Ашыгып язылган берничә җөмлә ул: «Гөлчирә сөеклем! Безне фронтка озаталар. Эшелоныбыз, абзәтәйнең туган көненә өч көн кала, уңыш чорында олаулар белән ашлык китерә торган станциядә ярты көн тукталып торачак. Килә алсаң, килергә тырыш... Шунда барысын да сөйләшербез... Көтәм! За Сталина, за Родину жизнь отдам!!!»

Сәлимгәрәй товар ташый торган вагонның икенче кат сәндерәсендә йөзтүбән капланып яткан хәлдә, үзе кебек үк фронтка баручы нindидер солдат кулы белән ике такта арасында махсус уелган тишектән тышкы якка төбәлгән килеш, бөтен дөньясын онытып, бары тик алда булачак очрашу хакында гына уйланды: «Хат барып җитәрме? Өлгерерме?» Юл буендагы станцияләрдә, шул төбәктән фронтка китүче солдатларны җыеп, сәгатьләр, көннәр буе тукталып торганда да үз уйларыннан аерылмады: «Күрешә алырлармы?» Сөйгәне белән очраштырачак станциягә якынлашкан саен аның йөрәге ешрак типте, хисләре кайнарланды...

* * *

Соңгы кичтә, көн саен авыл яшьләре җыела торган яланда биеп-җырлап алганнан соң, парлап төрлесе төрле якка таралышты. Иртәгә фронтка алынасы өч егет үз ярлары белән парлашып, бер төркем булып киттеләр. Сөйләшмәделәр. Кызлар гына мышык-мышык борын тарта. Сөйгәннәрен нindи афәт авызына җибәрәчәкләрен алар белеп бетермәсәләр дә, бик ачык тоялар иде. Егетләр аларны үзләренчә тынычландырган, юаткан була, әле кочып алалар, әле, үпкәләгән булып, берничә адым читтәрәк бара башлыйлар. Кайсыдыр егет әйтеп куя: «Безнең кайтуга ышанмыйсызмы әллә?» Кызлар шундук елаудан туктый, үз ярларының иңенә сарыла...

Нәкъ төн уртасында өч пар өч якка үз урамнарына каерылып кереп китте. Ләкин беркем дә өйләренә ашыкмады. Кичке уенга төшә торган юл башында очрашалар да тагын урамнарына кереп китәләр... Шулай әле бер якка, әле икенче якка бер-берсен озатышып йөри башладылар. Менә бервакыт калган ике пар кинәт юкка чыкты: кайтып киттеләрме, берәр кая кереп постыларммы? Үзләре генә калганын Гөлчирә дә сизеп алган. Әнә бит, барган җиреннән туктап, Сәлимгәрәйгә каршы килде дә, биленнән кочып, башын егетнең күкрәгенә салды.

– Арыдым, Сәлим... Әйдә берәр кая кереп утырабыз... – Гөлчирә, яратып, үз итеп, аңа «Сәлим» дип кенә дәшә...

Сәлимгәрәй үзе дә арган иде. Күбрәк борчулы хисләрдән арды. Гөлчирә белән соңгы очрашулары бит. Ничек борчылмыйсың инде! Җәй ахырына туй дип торалар иде. Менә мәлгунь Гитлер бөтен хыялларына аркылы төште... Озак йөрмәсләр анысы... Сугышка бөтен ил белән әзерләнәләр иде бит... Ул хакта күптән сүз йөри инде. Сталин әзерләнгәндер... Ул барысыннан да башлырак...

Гөлчирәләр йорты каршында туктап торалар икән. Шул җитә калды кызга. Ике кулыннан тотып, егетне үзләренә таба тартты:

– Әйдә безгә керәбез. Әтинең бакчада ял итә торган лапасы бар...

Сиздермәскә тырышып, сак кына басып, җилкапканы ачып керделәр дә ишегенә чаршау ябылган такта лапас сәкесенә кереп урнаштылар. Кечкенә тәрәзәсе бар икән. Шуннан тонык кына ай нурлары төшеп тора. Дөресрәге – суырылып агып тора... Болай да авыр уйлардан тимерләп торган күңелне тагын да ныграк ямансу итә...

Бу юлы сөйләшмәделәр. Бер-берсенә сыенып тик утырдылар. Тыйнак кына үбешеп алалар да тагын тыналар, үз уйлары белән ялгыз калалар... Шунда Гөлчирәгә әллә нәрсә булды: менә ул сикереп торды да чишенә башлады. Башта яулыгын чиште, изүләрен ычкындырды, аннары җил кебек җиңел, юка күлмәген аска шудырып төшерде...

– Гөлчирә, нишливең бу?

– Сәлим, ал мине!.. Без барыбер бергә булачакбыз. Миндә орлыгың калсын. Ул сиңа сугышта исән калырга ярдәм итәр, тизрәк җиңеп кайтырга булышыр... Ә миңа – көтәргә... Мин... синеке...

Бу хәлдән тәмам ярсынган, тышка сикереп чыгардай булып типкән йөрәге Сәлимгәрәйне утырган җиреннән тартып торгызды.

– Гөлчирә, ярамас бит, никахсыз ярамас... Аннары...

– Нәрсә «аннары»?

– Кайта алмасам?.. Кайтмасам нәрсә булыр, Гөлчирә?

– Кайтасың, кайтасың, Сәлимгәрәй!.. – Бу юлы Гөлчирә аның исемен тутырып әйтте. – Алла боерып, көзгә үк кайтып җитәсең, мин моңа ышанам. Чөнки мин сине өзелеп-өзелеп яратам! Ә яраткан кешеләрнең күңеле дөрес тоя ул... Ә мин тоям, тоям: син кайтачаксың!

Тәрәзәдән төшкән ай яктысында көмешкә манчылып, җем-җем килеп торган зифа сын, тулышып, наз көтеп зарыккан күкрәкләр калтырана башлаган иде инде... Сәлимгәрәй сак кына килеп, сөйгәнен кочаклап алды, бермәлгә тын калды... Ул кызның йөрәк тибешен аермачык тоя, хәтта аның күз яшьләренең күлмәк изүенә тамуын да ишеткән кебек иде...

Сәлимгәрәй үзе дә калтырана башлады, шашынып кызның битеннән, күзләреннән, чәчләреннән үбәргә кереште... Менә аның иреннәре әле беркемнең дә тәне кагылмаган зифа кулбашларга, сылу күкрәкләргә үрелде... Һәм туктап калды... Тагын бер мәртәбә кызны кысып кочты да, иелеп, аның күлмәген күтәрде, кияргә булышты...

Кыз барысын да аңлады. Бер сүз эндәшмәде, Сәлимгәрәйгә сыенып, бөтен җаны-тәне белән берегеп тора бирде... Бераздан гына сөйгәненең колагына пышылдады:

– Тизрәк кайт, яме... Мин сине көтәрмен... Саф килеш көтәрмен... Кайт кына, ничек тә кайт кына, бәгърем...

(Дәвамы киләсе санда).

Берничә көн элек тарих фәннәре докторы, профессор Рәмзи Кәлимулла улы Вәлиевкә 85 яшь тулды. Ул узган гомер юлының зур өлеше Казан университеты белән бәйле. Тормышының иң катлаулы чоры, мөгаен, СССР җимерелгән, яңа Россия пәйда булган 1990 елларга туры киләдер. Яңа, көнбатышка йөз тоткан иҗтимагый-сәяси кыйммәтләрнең актив үтеп керүе күпләрнең планнарын гына түгел, язмышларын да пыран-заран китерде. Шәрык акыл иясе төгәл искәргән: “Күчешләр чорында яшәүдән сакласын” (Конфуций). Казан дәүләт университетының тарих факультеты деканы Р.Вәлиев тә, күпчелек галим-голәма кебек, шөбһәле билгесезлек халәтен кичерә: фән тагын яшәрме дә, үзебез калырбызмы?

Рәхмәтләргә лаек профессор

1981 елдан бирле декан урынбасары булып хезмәт куйган Рәмзи Кәлимович 1995 елда декан вазифасына игълан ителгән вакантлы урын өчен конкурста катнаша һәм көндәшләрен җиңүгә ирешә. Әмма эшне башлау җиңелдән булмый, бу вазифаны 16 ел буена башкарып тәҗрибә туплаган, факультет коллективында зур абруй казанган дусты һәм хезмәттәше Индус Таһировны алыштыру ничек ансат булсын? Өстәвенә, югары уку йортлары системасын финанслау кими, болай да мул булмаган хезмәт хакын бирү тоткарлана. Әмма тарих факультеты коллективы алдында өмет уты кабына – яшәячәкбез! Коллектив белән яңа вазифада очрашу вакытында аңа, табигый ки, төп сорау бирелә: “Яңа иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтә сез Татарстан тарих фәненең перспективаларын нинди сурәттә күрәсез?” Р.Вәлиев ул мәлдә үтә саклык белән, әмма җитлеккән галим һәм практик булуы анык беленерлек итеп җавап бирә. Еллар уза, икеләнүләр ныклы ышаныч белән алышына, әмма аның фәнни кыюлыгы һәрвакыт факультет коллективының фәнни потенциалын бәяләүгә нигезләнә. Бер чыгышында тарих факультетының беренче деканы, профессор һәм академик И.Таһиров түбәндәге сүзләрне әйтә: “Рәмзи Кәлимовичка тарих факультеты белән Казан университеты өчен иң кыен вакытта җитәкчелек итәргә туры килде. Моның өчен нык-лы характерга ия булу гына җитми, куелган максат хакына һич соңармый, нәкъ вакытында туплана белү зарур иде. Факультет җитәкчедән уңды. Вәлиев – белеме буенча тарихчы, холкы белән дипломат, төп эш хакына вак-төяккә икенче чиратка куя белү сәләтенә ия зат. Ул коллективны саклап калу, аны яшь кадрлар белән баету белән бергә, яңа юнәлешләр дә булдырды”.

Тарих факультетын җитәкләргә алынганда ук, Р.Вәлиев провинциализмнан арыну, тупланган фәнни потенциалны саклау һәм ныгыту, төбәк дәрәҗәсендә генә калмыйча, бөтенроссия масштабындагы фәнни-тикшеренү һәм белем бирү үзәге булып җитешү зарурлыгын күздә тота. Шуңа күрә декан вазифасындагы беренче адымнарыннан ук Татарстанның гына түгел, шулай ук Идел-Урал төбәгенең тарихын һәм бүгенгесен өйрәнүгә дә комплекслы, күпьяклы якын килү бурычын куя. Әлеге максат белән яңа фәнни юнәлешләр булдырыла, шул ук вакытта тарихи эзләнүләрдәге лидерлык позициясе дә саклана. Р.Вәлиев сынауларда сынмаган һәм яңа фәнни юнәлешләр белән киңәя барган факультет өчен биниһая тырышлык куя. Р.Вәлиевнең деканлыгы чорында тарих факультеты илдәге башка югары уку йортлары, кайбер чит ил университетлары белән багланышлар кора, матди-техник базасы һәм укыту-методик базасы ныгый. Яңа кафедра – Татарстан тарихы кафедрасы ачыла, музеология буенча белгечләр әзерләү башлана. Тарих факультетындагы фәнни хезмәткәрләр составының көйле һәм нәтиҗәле эшчәнлеге тәэмин ителә.

Р.Вәлиев үз гамәлләрен мәҗбүрият белән түгел, йөрәге кушканга кыла, коллегаларының фәнни һәм карьерага кагылышлы амбицияләрен аңлап, аларны хәл итәргә омтылып яши, шуның белән факультетта эшлекле, дустанә һәм иҗади вәзгыять тууга этәргеч бирә. Остазыбыз үзе дә, Конфуций искәргәнчә, “Кешенең иртән эшкә барасы килеп, кичен өенә кайтасы килеп торса, бәхет өчен шул җитә”, дип яши.

Табигать Р.Вәлиевне тормыш фәлсәфәсен гамәлдә куллана белү, стратегик фикерләү һәм стандарт булмаган карарлар кабул итү сәләте белән бүләкләгән. Безне, аның шәкертләрен, тагын остазыбызның фәнни дискуссияләр белән оста “дирижёрлык итүе” һәм үзенең дә аларга актив катнашуы сокландыра иде. Фәнгә кагылышлы мәсьәләләрдә җитди профессор тормышта бетмәс-төкәнмәс юмор иясе: әле генә сөйләмен руслар арасында тәгәрәп үсканнәргә генә хас гыйбарәләр кушып “үрсә”, ул да булмый, фикерен татарның тормыш фәлсәфәсен чагылдырган бизәкләр белән баетып җибәрә. Кайбер фәнни җитәкчеләрдән аермалы буларак, ул үз аспирантлары алдына беркайчан да шикле шартлар куймый, мавыгып эзләнүчеләргә булышлыгын кызганмый. Безнең белән эшләү, әлбәттә, аңа җиңел түгел, бу эш мәшәкать-кыенлыклар өсти, әмма без аңардан һәрвакыт аңлау һәм яклау таба идек.

Остазыбызга мөнәсәбәтебездә иң мөһиме – җитәкче һәм кеше буларак аңа булган хөрмәт һәм ышану. Р.Вәлиев әзерләгән 20 фән докторы һәм кандидаты – тарих фәннәре докторы, Ульяновск педагогика университеты профессоры, полковник И.Чуканов әйткәннәрне нәкъ үзенеке итеп кабатлый ала: “Фәнни даирәләрдә сезнең яңалыкка тоемыгыз һәм шул ук кимәлдә коллегаларыгыз, аспирантлар һәм студентлар белән арадашлык итү сәләтегез киң билгеле. Сезнең тормыш юлыгыз – тарих фәненә фидакярләрчә хезмәт итү, ә инде казанышларыгызның Татарстан һәм Россия дәрәҗәсендә танылуы – күпьеллык киеренке хезмәтегез өчен бирелгән төп бүләк”.

Шәхсән үзем Р.Вәлиевне инде 40 елдан бирле беләм. Студентларның бәяләү шкаласы буенча ул – “нормальный” укытучылар рәтендә. Безнең яшьлектә андый бәягә заман белән бер аяктан атлаучы һәм үз белеме багажын яшь буынга тапшыру теләге белән янганнар лаек була иде. Р.Вәлиев аспирантлар өчен һәрьяклап үрнәк: ул безне фәнни эш алып бару тәртибенә, кешеләр белән аралашырга, тормышта үзең сайлаганны яратырга өйрәтте, чын галим һәм укытучы булу серләренә төшендерде. Тормышыбызда менә шундый гади, ачык, яхшы күңелле, зирәк акыллы кеше очрарга тиеш булу, аның барыр юлыбызны билгеләүдә катнашуы – язмыш бүләге булгандыр.

Галимнәрдән дә, иҗади һөнәр ияләреннән дә Р.Вәлиевнең туктаусыз үзгәреп торган иҗтимагый-сәяси чынбарлык шартларында заман таләп иткән фәнни юнәлешләр сайлавы турындагы фикерләр ишетергә туры килгәне бар. Үткер һәм сыгылмалы акыл белән кылынган гамәлнең нәтиҗәсе генә шулай төрле яшьтәге һәм төрле социаль статустагы кешеләр тарафыннан уртак хуплау белән бәяләнә аладыр. Объектив күзлектән караганда, бу – галимнең фәнни юлын да күрсәтә. Һәр кеше дә үз эзләнүләренең тематикасын шул дәрәҗәдә кискен үзгәртергә кыймас: 1917 елгы революцион хәрәкәт, аннары 1920-1930 еллардагы сәяси репрессияләр һәм зыялылар язмышы, “Болак арты республикасы”, милли төзелеш һәм, ниһаять, кече ватан тарихы. Әлеге юнәлешләрнең һәркайсында аның саллы фәнни өлеше бар. Татарстанның беренче суверенитеты турындагы идея дә аныкы! Шунысын танымый булмый, аның суверенитетлар турындагы идеясен һәркем һәм дәррәү кабул итми. Әмма Татарстан тарихы Р.Вәлиев өчен һәрвакыт төп юнәлеш булып калды. Ул ясаган ачышлар иң яңа Татарстан тарихын яңа тарихи материаллар белән баету мөмкинлеге бирде.

Р.Вәлиев – 300 дән артык фәнни һәм фәнни-популяр хезмәт, 10 фундаменталь монография авторы. Соңгы ике дистә ел эчендә генә ул Татарстанның иҗтимагый-сәяси, милли-дәүләт үсеше мәсьәләләренә караган 100 дән артык фәнни хезмәт бастырып чыгарды. Аның эшләре галимнәр һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан хаклы рәвештә югары бәяләнде. Филология фәннәре докторы Т.Галиуллинның әңгәмәдәшләренә Р.Вәлиевнең үз геройларын ышандырырлык итеп тасвирлау осталыгын билгеләп үтүе күңелгә уелып калды. Сүз “Фаҗига” китабы герое Галимҗан Шәрәф турында бара, авторның “Черек күл” паркын, шундагы эскәмияләрнең берсендәге Галимҗанны, аның яшәеш турындагы авыр уйларын җанландырып сурәтләве мисал ителгән иде. Р.Вәлиев матбугат белән гомере буе актив хезмәттәшлек итә, тарихи белемнәрне популярлаштыруга күп көч куя. Аның мәкаләләре “Звезда Поволжья”, “Мәдәни җомга” газеталарында, “Гасырлар авазы – Эхо веков”, “Казан утлары”, “Мәгариф”, “Мирас”, “Безнең мирас”, “Туган җир. Родной край” журналларында дөнья күрде.

Олпат галим үз фәнни эзләнүләрен алга таба да киңәйтә. Пандемия чоры “торгынлыгында”, 2020-2021 елларда нәшер ителгән “Горная сторона... Наше время” һәм “Борьба за национальную государственность: начало XX века” китаплары шуны раслап тора. Шуларның беренчесен, Р.Вәлиевнең тормыш һәм иҗат юлына, нәсел тарихы, гаилә-туганлык мөнәсәбәтләренә багышланганын аерым бер кызыксыну белән кулыма алдым. Китапның сюжет сызыгы авторның туган җире – Тау ягы, университет дуслары һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең төп юнәлешләренә кагылышлы фактлар белән үрелеп бара. Китапның ахырында Р.Вәлиевнең шигырьләре урнаштырылган, арадан берсе дөньядан вакытсыз киткән хатыны Люциягә багышлана. Китапларның икенчесе – гомерләре Россия тарихының текә борылышларына туры килеп, иҗтимагый-сәяси вакыйгалар “тегермәненә” эләккән шәхесләр турында. 2022 елда галим тагын бер хезмәт әзерләп, нәшриятка тапшырды. Китап туган авылына багышлана һәм “Исәнме син, Карашәм” дип атала.

Р.Вәлиев үзен бәхетле кеше дип саныйдыр. Ул корган йорт – барлык мәгънәләрдә җылы йорт. Хатыны Люция Казан медицина институтының дәвалау факультетын тәмамлаган табибә, биология фәннәре кандидаты, биотехнология өлкәсендәге ике патент авторы иде. Катлаулылыклар аркасында аңа уңышлы башланган фәнни юлын дәвам итү насыйп булмый. Аның өчен гаилә һәм иренең карьерасы беренче урында куела. Авырып, тормыштан вакытсыз киткән Люция ханым, иренең фәндәге юлы югарыга таба үрләсен өчен, барысын да эшли. Р.Вәлиев Россия һәм Татарстанның абруйлы галимнәреннән берсе булып танылган икән, монда аның табигатьтән бирелгән таланты, үзенең тырышлыгы һәм асыл сыйфатларына өстәп, хатыны тудырган шартлар бәрабәренә дә ирешелгән дип аңларга кирәк. Бүгенге көндә ул кызлары Эмилиянең уңышларына сөенеп яши.

Р.ШӘЙДУЛЛИН,
тарих фәннәре докторы.

Мәдәни җомга
13 май
№18, 2022

● Ибн Фадлан Алмыш хан каршында Багдад хәлифе әл-Мөкътәдирнең хатын укый. Н.Хаҗиәхмәтов эше. 1997 ел.

ИБНЕ ФАЗЛАН

Татар мәдәнияте тарихына XX гасыр башы Яңарыш дәвере алып килде. Күренекле мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдин мөхәррирлегендә басылган «Шура» журналында әдәби әсәрләрнең һәрдаим дөнья күрүе, тарихи хәтерне уятуда мөһим роль уйнаган язмаларның нәшер ителүе эзсез калмаган. 1908–1918 ел аралыгында журнал битләрендә ислам әхлагы, фәннең төрле тармакларындагы ачышлар һәм әдәби әсәрләр белән таныштыру гасыр башы укучысын төрле яктан баеткан. Р.Фәхретдин «Шура»ның һәрбер санында «Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр» циклында дөнья тарихында, шул исәптән шәрык мәдәнияте һәм әдәбиятында билгеле урын тоткан шәхесләргә багышланган мәгълүматлар җиткереп барган.

Бу язманың сәбәпчесе булган гарәп сәяхәтчесе Әхмәд ибне Фазланның (Фадлан) тәрҗемәи хәле дә тәүге тапкыр «Шура»да нәшер ителә. Мәкалә 1909 елның 19 нчы санында дөнья күргән. Автор Ибне Фазланның Болгарга килүе турында язса да, ун ел дәвамында нәшер ителгән «Шура»да Ибне Фазланның Болгарга сәяхәтен тасвирлаган язма басылмаган. Шунысы ачык: Р. Фәхретдин Әхмәд ибне Фазланның сәяхәте һәм аның хакында нәрсә дә белмичә фәнни мәкалә язарга алыныр иде микән?! Һичшиксез, юк... Мөхәррир һәм галим кулында Ибне Фазлан турында язма өчен материл булган, әлбәттә. Ул мәкаләдән дә аңлашыла. Ләкин сәяхәтнамәнең үз вакытында басылмавы сорау калдыра.

Дөрес, Р.Фәхретдин тәрҗемәсендәге «Ибне Фазланның Болгарга килүе» сәяхәтнамәсен галим Әнвәр Хәйри XX гасырның 90 нчы елларында, аерым алганда «Мирас» журналының 1994 елгы 5-6 саннарында һәм «Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгарга килгәндә язган сәяхәтнамәсе»н (Казан: «Сүз», 2013) китабында Ибне Фазлан сәяхәтенә караган материалларны туплап, фәнни аңлатмалары белән күләмле хезмәт нәшер итә. Галим, нигездә, күренекле рус ориенталист галиме, тарихчы Андрей Ковалевский тәрҗемәсен алып, аңа тәнкыйди текст рәвешендә эшли, шунда ук Р.Фәхретдин татарчалаштырган текстны да урнаштырып, китапның эчтәлеген баетуга ирешкән. Әмма сәяхәтнамәне милли мәдәниятендә хәзерге татар теле кагыйдәләренә якынайтып тәрҗемә итүче Р.Фәхретдин булса, XX гасырның 60-70 нче еллар башында ук матбугатка тәүге тапкыр әзерләүче татар халкының күпкырлы талант иясе Габделбакый Урманче булуын онытырга ярамый. Төгәлрәге, ул язманы 1968 елда Уфа шәһәреннән күчереп алып кайта.

Б.Урманченың Татарстан Сынлы сәнгатьнең музей архивына вакытлы саклауга куелган шәхси архивын өйрәнгәндә Р.Фәхретдинов тарафыннан тәрҗемә ителгән Ибне Фазланның Болгар дәүләтенә сәяхәте хакында кулъязмасына тап булдым. Чыганаклар арасында сәяхәтнамәнең кайда саклану һәм аның нинди хәлдә булуы турында кыска-кыска искәрмәләре бар. Хәзер шәхси архивтагы язмаларга күз салыйк. Ул кулъязманың язмышын түбәндәгечә аңлата: «Ибне Фазланның Болгарга килүе. Уфа каласында элек Диния нәзарәтендә булган, СССР гыйлемнәр Академиясенең Башкортстан филиалының кулъязмалар коллекциясендә сакланмакда булган тарихи гыйльми фазыл Ризаэтдин Фәхретдин кулъязмаларының II томында булынмакда. Күчердем: Урманче Габделбакый Идрис угылы 1968 ел, сентябрьнең 3-5 ләрендә. Имза: Габделбакый». Рәссам, кулъязманы автор ничек эшләгән булса, шул хәлдә калдырып, хәтта язу стилен дә Р.Фәхретдин язуындагыча калдыруны максат итеп эшләгән. Төп максаты: киләчәк буыннар кулъязма белән эшләгәндә текстка хилафлык китерү бар дип саный. Укучыга ирештерәчәк чыганак Диния нәзарәте архивының СССР (хәзерге Россия) Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы, Тел, әдәбият һәм тарих институты архивына кайсы вакытта тапшырылуы турында да мәгълүмат алабыз. Шәхси архивта сакланган чыганакта: «Бу язма күчерелде Ризаэтдин Фәхретдин бине Фәхретдиннең үз кулы берлән 18 сәхифә (ягъни 34) үзәрендә язылган. Хазирында Башкортстан башкаласы Өфе, СССР Гыйлемнәр Академиясенең Башкортстан филиалы кулъязмалар кабинасында саклана торган әсәрдән. Бу кулъязма 1967 елга кадәр Диния нәзарәтенең архивында булган. Кулъязма аерым катыргы тыш белән төпләнгән, сау-таза хәлендә сакланган. Яңа кулларда нинди хәлдә булыр, Аллаһ белә. Шунлыкдан язып алырга һәм мөмкин кадәр Р.Ф.ның язу рәсемен сакларга тырышдым. Өфе каласы. 1968, 6 сентябрь. Габделбакый Урманче», – дигән сүзләр белән очрашабыз.

Мәгълүм ки, укучы Ибне Фазланның Болгарга сәяхәте белән А.Ковалевский тәрҗемәсендә генә таныш иде. Шәхсән үземә дә, студент елларында татар теленнән курс эше язганда, Ковалевский тәрҗемәсенә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Шунысы кызганыч, ул заманда бу хезмәт белән югары уку йортларында гуманитар юнәлештә белем алган аерым катлам татар укучысы гына таныш булгандыр. Ул елларда киң катлам татарга Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе сер булып кала килде. Шул гаделсезлеккә нокта куярга теләптер, Б.Урманче болгар дәвереннән үк татар һәм күрше халыкларның тарихын, аларның этнографик һәм гореф-гадәтләре, йолаларын теркәп калдырган бердәнбер язма чыганакны татар укучысына җиткерүне максат иткәндер, мөгаен. Ләкин... Милләтләрнең тарихына, мәдәниятенә каршы алып барылган совет идеологиясенең сәясәте Б.Урманче уйлаган изге ниятенә азрак киртә куя: «Ибне Фазланның Болгарга сәяхәтнамәсе» укучыга барып ирешми кала. Монда галимнәрнең куркуларын да, татарга хас булганча, кирәгеннән артык белүләрендә, бер-берләренә аяк чалырга теләүләрен дә һ.б. да күрергә мөмкин. Түбәндәге чыганак бу сорауларга җавап бирә сыман: «Ризаэтдин бине Фәхретдиннең мәшһүр гарәб сәяхәтчесе Ибн Фадланның Болгарга килүе хакында язган рисаләсе.

Искәрмә: мондый һәм моңа охшаш кайбер мәгълүматларны укучыга җиткерү, нигездә гыйльми оешмаларның һәм югары уку йортларында гыйльми басмалары ярдәмендә эшләнергә тиеш. Журнал белән ниндидер җыентык һәм популяр формада шулай ук эшләп булды һәм киләчәктә булыр.

Теләк: 1. Р.Фәхретдинов турында кереш озын, урынсыз читләшүләр күп. 2. Р.Фәхретдинов турында журнал инде үз материалын урнаштырды (Миркасыйм). Моны да искә алмый булмас. 3. Р.Фәхретдинов шәхесенә, аның иҗтимагый ролен фән учреждениеләре исеменнән ачыклау кирәк. 4. Сәяхәтнамәне файдаланырга мөмкин. Әмма:

А) нәкъ шуның җирлегендә язылган Н.Фәттахның романы басылып беткәннән соң бераз вакыт үткәч (1970–1971 еллар).

Б) чыганакларның гыйльми учреждениеләрдә теркәлгән булуларын әйтеп, төп нөсхәләргә ишарәләп. 15.07». Чыганактан күренгәнчә, Б.Урманче материалны «Казан утлары» журналына 1969 ел ахыры яисә 1970 ел башында биргән, күрәсең. Кызганыч, мөхәррир имзасы куелган язмадан күренгәнчә, журналда басылмауның төп сәбәпләрен ачык сиземләргә мөмкин. Хәтта ки, Ә.Еникинең «Бу хезмәт укучылар өчен бик кызыклы булыр дип ышанам. Шуңа күрә мин басылып чыгару ягында. 26.05.70 ел» дигән тәкъдиме булса да. Шул рәвешле, Р.Фәхретдиннең кулъязмасы буенча Б.Урманче әзерләгән Ибне Фазланның Болгарга сәяхәте белән меңәрләгән татар укучысы таныша алмый кала.

Бакуда яшәгән милләттәшебез, XX гасырның 60-70 нче елларында Җәгъфәр-Садыйк Мамедов тарафыннан да Әхмәд ибне Фазланның сәяхәте татар теленә тәрҗемә ителгән. Кызганыч, ул да кулъязма хәлендә генә калган. Заманында Җ.Мамедов әзерләгән машинка басмасын кемдер Татарстан Милли музеена тапшырган. Соңрак, 2003 елда музейның өлкән фәнни хезмәткәре Рәмзия Абзалина аны «Әл-Мөкътәдирнең сакләбләр падишасына илче итеп җибәрелгән Мөхәммәт ибн Сөләйман химаясендәге Әхмәд Ибне Фадлан китабы» исеме белән бастырып чыгара. Чынлыкта тәрҗемә 1974 елда әзерләнгән, кереш мәкаләсендә «Җәгъфәр-Садыйк Мамедов, март 1974» дип куелган. (Җ.Мамедов тарафыннан башкарылган тәрҗемәне эшкәртүдә, татарның зыялы нәселеннән булган, Уральск шәһәренең 3 нче мәчет (халык телендә Кызыл мәчет) имам-хатыйбы Габдеракыйп Тулбаевның туганы Һади Тулбаев ярдәме белән нәшер ителгән. Китапны төзүче Р.Абзалина шундыйрак фикерен җиткерде). Хезмәткә кереш мәкалә язган әдәбият галиме Марсель Әхмәтҗанов чыганак хакында: «Ибн Фадлан сәяхәтнамәсен 60 еллар ахырында Бакуда яшәүче милләттәшебез Җәгъфәр-Садыйк Мамедов татар теленә гарәпчәдән тәрҗемә итә һәм аның бер өзеге күренекле татар драматургы һәм галиме Нәкый ага Исәнбәт тәкъдиме белән «Казан утлары» журналында дөнья күрә», – дип Җ.Мамедов тәрҗемәсенең язмышын күз алдына китереп бастыра. Шулай итеп Җ.Мамедов тәрҗемәсе дә билгесезлектә кала. Совет хакимияте һәм коммунистлар фиркасе идеологиясе басымы астында яшәгән татар мәдәниятендә бу сәяхәтнамәгә мөрәҗәгать итүчеләр булса да, аның матбугатка татар телендә нәшер итү теләген белдергәннәр башка күренми шикелле. Алар бардыр, ләкин безгә әлегә мәгълүм түгел.

XX гасырның 80 нче еллары уртасында дәүләттә үзгәреш җилләре исә башлау белән, татар халкы үзенең тарихына, бай мәдәнияте һәм әдәбиятын җентекләбрәк, тирәнрәк өйрәнергә, яңача караш белән карый башларга юллар ачыла. 1944 елгы КПСС Үзәк Комитеты Политбюро карары нигезендә татарның борынгы тарихын тикшерү тимер йозак артына яшерелсә, инде 80 нче еллар ахырында тарихи чыганакларга мөрәҗәгать итү арта, аларны дөньяга чыгару юнәлешендә беренче адымнар ясала. Мәсәлән, әдип Солтан Шәмси XX гасырның 90 нчы елларында рус һәм татар телендә берничә

● Идел буе Болгарының ислам кабул итү тантанасы. Рушан Шәмсетдинов эше.

● Болгар иле илтәбәре Алмышка Ибн Фадлан илчелеге. Булат Гыйльванов эше. Фрагмент.

СӘЯХӘТНАМӘСЕ

●Ибн Фадланның Болгарга килүе. Бакый Урманче эше.

тапкыр әсәрнең әдәби тәрҗемәсен бастырып чыгара. 1999 елда исә, Татарстан китап нәшриятында ике телдә «Әхмәд ибне Фазланның Ител елгасына сәяхәте» исеме белән нәшер ителә. С.Шәмси китаплар нәшер итү белән чикләнми, ул XX гасырның 90 нчы елларыннан башлап Ибн Фазлан һәм аның сәяхәтнамәсен матбугатта шактый пропагандалаган шәхесләребезнең берсе дә.

Югарыда искә алынганча, инде 1974 елда Җәгъфәр-Садыйк Мамедов гарәпчәдән алып татарчалаштырса, С.Шәмси исә Ковалевский тексты буенча эшли кебек. Әхмәд ибне Фазланның Болгарга сәяхәтен тирәнтен өйрәнеп, төрле чыганаклар белән чагыштырган, фәнни яктан җентекле тикшерелгән күләмле хезмәтне – галим Әнвәр Хәйри 2013 елда бастырган «Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язылган сәяхәтнамәсе» исемле китабы аерым игътибарга лаек. Ә.Хәйри А.Ковалевский тәрҗемәсендәге текстны ул тәкъдим иткән факсимиле белән чагыштырып, Ковалевскийдагы хаталарны анализлап, төзәтеп, татар укучысына яраклаштырып тәкъдим иткән. Бу хезмәтнең башка татар басмаларыннан өстенлеге шунда ки: ул – татар укучысына җиткерелгән беренче фәнни басма.

Р.Фәхретдиннең Әхмәд ибне Фазланның Болгарга килүе хакындагы сәяхәтнамәсен кайсы вакытта тәрҗемә итүе мәгълүм түгел. Шулай да Б. Урманче журналда бастырырга ният иткән Ибне Фазлан сәяхәтенә кереш мәкаләсендә мәгърифәтче галимнең кулъязманы XX гасыр башында тәрҗемәгә алынса да, әле 20 нче елларда татарчалаштыруның төгәлләнмәвен искәртеп уза. Б.Урманченың фикерен, Р.Фәхретдиннең 1925 елда Ленинградта уздырылган СССР Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилеенда катнашуы һәм анда СССРның күренекле шәргыятче галимнәре белән танышуы һәм аралашуына бәйләп аңлатырга мөмкин. Мәгълүм булганча, озак еллар Ленинградта «Россия Фәннәр академиясе хәбәрләре» исемендә журнал бастырыла. 1924 елда гуманитар юнәлешкә караган өлешендә З.Вәлидинең В.Бартольд тәрҗемәсендә «Ибне-л-Факихның Мәшһәд нөсхәсе» исемле мәкаләсе дөнья күрә. Һичшиксез, бу журнал Р. Фәхретдин кулына тапшырылгандыр. Һәм нәтиҗәдә, мәгърифәтче галим, З. Вәлиди язмасындагы урын алган текстларын кулланып, Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе кулъязмасын шактый тулыландыруга ирешкән.

Ә.Хәйри төзегән китапта бу кулъязманың тәрҗемә хакында «Ибне Фадлан сәяхәтнамәсенең «1905 елда Ризаэтдин Фәхретдин тарафыннан татар теленә эшләнгән тәрҗемәсе» дигән мәгълүмат бирә. Әмма галим нинди чыганакка ишарәләве аңлашылмый. Шунысы ачык: 1909 елда «Шура» журналында басылган мәкаләгә нигезләнеп, кулъязманың XX гасырның 10 нчы елга кадәр башкарганын һәм 20 нче елларда З.Вәлиди тарафыннан табылган «Мәшһәд нөсхәсе»нә таянып дәвам иткәнен чамаларга була. Б.Урманче шул нөсхә буенча эшли. Ягъни, Р.Фәхретдин исә гарәп сәяхәтчесе, географ һәм тарихчы Якут Хәмәви китабына тасвирланган өлешләренә таянып һәм З.Вәлидинең «Мәшһәд нөсхәсе» мәкаләсендә булган өзекләрне кушып татарчалаштыра. Б.Урманче исә әлеге атап үткән чыганакларны нигез итеп, чагыштырып, башка материаллар белән дә баета.

Шунысы мәгълүм, Р.Фәхретдин тәрҗемәгә керешкән елларда сәяхәтнамәнең бердәнбер тулы нөсхәсе – Мәшһәд нөсхәсе әле табылмаган. Хезмәтнең тагын бер яңалыгы: сәяхәтнамәнең беренче тапкыр татарчалаштырылуы үзе үк тарихи әһәмияткә ия. Дөрес, Шиһаб Мәрҗани «Мөстафәдел әхбар»... китабында Ибне Фазланның Болгарга сәяхәте хакында өзек-өзек мәгълүматлар биреп уза. Әмма гарәп-фарсы сүзләре белән бизәлгән өзекләрне татарча текст дип атарга иртәрәктер. М.Рәмзи китабында да гарәп телендә язмасын күрергә мөмкин. Ләкин шунысын ассызыкларга кирәктер: Р. Фәхретдин Якут Хәмәви текстына тәнкыйди килә.

Б.Урманче дә шәхси архивында Ибне Фазлан сәяхәте хакында материаллары арасында сәяхәтнамәдәге күп кенә мәсьәләләргә ачыклык кертергә тиешле сорауларны билгели, урыны-урыны белән искәрмә һәм аңлатмалар биреп уза. Нигездә, ул «сакләб» төшенчәсенә бәйле. Искәртеп үткәнчә, Якут Хәмәви тексты тулы түгел. Р. Фәхретдин әлеге язманы тулысы белән тәрҗемә иткән, шул сәбәпле «Мәшһәд нөсхәсе»ннән аермалары да җитәрлек. Үз вакытында «Казан утлары» журналы өчен әзерләгән текстка кереш мәкалә язган Б.Урманче дә аларны күрсәтеп үтәргә тырышкан. Мәсәлән, Б.Урманченың кереш мәкаләсендә бу хакта түбәндәге юллар бар:«Риза Фәхретдин «сезгә тәкъдим ителә торган рисаләнең баб исемнәре, саннары һәм дә маддәләргә аерып куелган саннар безнең үз эшемез булыр», ди. Ягъни бөтен рисаләне төзүче үзе 16 бабка бүлгән, һәр маддәсе бер абзац тәшкил итә. Барысы 105 маддә-абзац. 16 нчы маддә юк, 15 тән соң 17 нче маддә башлана. Бу сәбәпсез түгел. Югарыда әйтеп үтелгән, Мәшһәд нөсхәсенә багышланган мәкаләбездә бу хакта сүз булыр. Аның җае шунда». Кызганыч, Б.Урманченың искә алган мәкаләсе шәхси архивында юк. Әмма 16 маддә-абзац Б.Урманче кулъязмасының икенче ягында теркәлеп калган. Флора ханым Әхмәтова-Урманче дә, астөшермәләрдә Р.Фәхретдин язган искәрмәгә өстәп, 16 маддәнең ни өчен текстка кертелмәвен аңлатып уза. Ул бу маддәнең төшеп калу сәбәбен текстта башкортларның бет ашаулары хакында язылуын күрсәтә һәм аның А.Ковалевский тәрҗемәсендә булуын искәртә.

(Дәвамы киләсе санда).

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН.

Мәдәни җомга
13 май
№18, 2022

КЫРЫМ

●Сәйдали Курсәетов.

●Исмаил Ирсмәмбәтов.

(Дәвамы. Башы 17 нче санда).

Кырым халкы тагын бер атнадан, күп дигәндә исә бер айдан ярымутрау азат ителер дип өметләнә. Тиздән әлеге имеш-мимеш урмандагы партизаннарга да барып ирешә һәм җитәкчелектә ыгы-зыгы тудыра. Әмма көтелмәгән хәл була. Вермахтның 17 нче армиясе частьлары югалтуларсыз диярлек ярымутрауга эвакуацияләнә. Алар килү белән Кырымда 270 мең немец һәм румын сугышчысы туплана. Бу вәзгыятьне тамырдан үзгәртә.

Сочида да, Кырымда да күпләп партизан отрядлары пәйда була башлый. Менә бер мисал. Андрей Сермуль: *«1943 елның сентябрендә Македонский янына бер кырымтатар егете килде һәм Куышта иреклеләр отрядының, немец командирларын үтереп, партизаннар янына китәргә теләвен хәбәр итте. Куышка килдек. Казармада, чыннан да, үтерелгән лейтенант ята. Эз буенча барып, алтмышлап кешене очраттык, барысы да Кырым татары. Иң беренче сораулары – чыннан да Мокроусов инде җитәкче түгелме? Җавап бирдек. Кызыл Армиянең Орел һәм Белгород янындагы җиңүләре турында сөйләдек, гаебен йолу өчен коралын немецка каршы боручыларны партизаннарның әзәрлекләмәячәген әйттек»,* – дип искә ала.

1943 елның ноябренә инде урманда 33 партизан отряды була. Бу елның соңгы өч аенда 5632 кеше партизанга әйләнә. Кырым авылларында шулкадәр күп ир-ат булуы таң калдыра. Алар барысы да армиядә булырга тиеш бит. Моңа Кырымдагы мобилизациянең тиешенчә үткәрелмәве сәбәп булгандыр. Менә бер хатирә: *«Сугыш башланды. Октябрь азагында мине Ялтадагы военкоматка чакырттылар, тик нигәдер өйгә кайтарып җибәрделәр. Тагын бер чакырганда, автомашина килмәде. Өченче тапкыр чакырганда, немецлар инде Симферопольне алган иде, һәм без үз ихтыярыбызга куелдык».*

Оккупацияләнгән Симферопольдә дә шул ук хәл күзәтелә.

1943 елның көзендә отрядлардан бригадалар, аннары өч берләшмә төзелә. Бу чорда 952 кырымтатар партизанлыкка китә. 1943 елда урманда инде барлыгы 6089 кеше исәпләнә, 1944 елда тагын 1186 кеше өстәлә. Булачак Көньяк берләшмәнең 10 нчы һәм 11 нче отрядлары тулысынча кичәге иреклеләрдән оештырыла. Менә 10 нчы отряд турында мәгълүмат: руслар – 54 кеше; греклар – 14; украиннар – 12; Кырым татарлары – 7; Казан татарлары – 5; әрмәннәр – 4; үзбәкләр – 4; поляклар – 3; грузиннар – 2; румыннар – 2; әзәрбайҗан – 1; белорус – 1; болгар – 1; яһүд – 1; карел – 1; лак – 1; словак – 1; хорват – 1 кеше.

1941 елның ноябреннән 1944 елның апреленә кадәр Кырымдагы партизаннар хәрәкәте аша якынча 12,5 мең кеше үтә. Шулардан 54 кеше әлеге эпопеядә беренче көннән соңгысына кадәр катнаша, һәм алар арасында 3 Кырым татары була.

Кадыев Сәетхәлил. 1913 елда туган. Сугышка кадәр дәүләт иминлек хезмәте сержанты. Карасубазар НКВДсы Дәүләт иминлек хезмәте лейтенанты. Отряд, бригада, берләшмәнең разведка җитәкчесе.

Молочников Мәмәт. 1912 елда туган. Карасубазар партизан отряды сугышчысы; Хәрби трибунал секретаре (10.10.42 – 05.01.43); 2 нче секторның 3нче отряды диверсия төркеме командиры; 4 нче бригаданың 2 нче отряды комиссары; Көньяк берләшмәнең 7 нче бригада 1 нче отряды комиссары.

Моратов Курсәет. 1908 елда туган. НКВД лейтенанты. 4 нче отрядның махсус бүлеге вәкиле.

Ихтимал, кемгәдер 54 кешедән 3 кеше генә бик аз тоелыр. Чынлыкта исә әлеге 54 кешедән нибары 9 ы гына сугышка кадәр Кырымда яшәгән!

Хыянәтче ... итеп билгеләнәсез
(1944 елның апреле – 1946 елның феврале)

Советлар Берлегенең барлык азат ителгән территорияләрендә кабул ителгәнчә, иң зур партизан отряды командиры – партиянең өлкә комитеты секретаре, отряд командирлары һәм комиссарлары исә өлкә шәһәр һәм районнарында җитәкчеләр итеп куела. Баштарак Кырымда да шулай булыр төсле тоела. Өч йөз Кырым партизаны нигездә шәһәр һәм районнардагы төрле җаваплы вазифаларга билгеләнә. Кырым партизаннар хәрәкәте штабы башлыгы В.Булатов (Казан татары) ВКП(б)ның Кырым өлкә комитетын җитәкли; П.Ямпольский (яһүд) – Кырым АССР ХКС рәисе урынбасары; И.Генов (болгар) – Кырым АССРның социаль тәэминат буенча халык комиссары; Х.Чусси (грек) – коммуналь хуҗалык комиссары урынбасары; Р.Мостафаев (кырымтатар) – Ялта шәһәр партия комитеты беренче секретаре итеп куела.

Вәзгыятьнең үзгәлеге шунда ки: 1944 елның язында җитәкчеләрне билгеләү үзенә бер фальстарт була һәм аның ярымутраудагы кадрлар сәясәтенә бер катнашы да булмый. Ярымутрау чыннан да тулысынча азат ителгәч исә, нәкъ менә обкомнан еракта – урманда булучылар һәм чынлап торып дошманга каршы көрәшкәннәр «портфель»сез кала.

Гаепсезләрне җәзаларга, лаексызларны бүләкләргә

Безгә Л.Бериянең И.Сталинга язган хаты мәгълүм: *«Партизаннар исерек, көне-төне кирәкмәгәнгә аталар, җитәкчелеккә буйсынмыйлар. Һәм хәтта халыкны талау белән дә шөгыльләнәләр»,*– диелгән анда.

ВКП(б)ның Кырым өлкә комитеты секретаре В.Булатов белән килешеп, партия-совет активы һәм милиционер итеп куелачак ышанычлы гади сугышчылардан тыш (300 кеше) барлык партизаннар Кызыл Армиягә җибәрү пунктларына тапшырыла.

1944 елның 13 апрелендә «Кырым АССР территориясен совета каршы элементлардан чистарту буенча чаралар турында» карар кабул ителә. Ярымутрау җиде секторга бүленә, тәртип саклау өчен 20 мең солдат бүленә. Фильтр чаралары вакытында 2 мең кеше кулга алына, шулардан 1104 есе армия хезмәтеннән качып йөрүче дип табыла. 21 апрельгә кадәр 40 мең кеше армиягә алына.

Ярымутрауны азат итүнең беренче сәгатьләреннән соң ук диярлек биредә җәза органнары үз эшен башлый: бер үк вакытта НКВДның территориаль бүлекчәсе, 51 нче армия, 2 нче гвардия армиясе, аерым Диңгез буе армиясе, Кара диңгез флоты – барысының да «СМЕРШ» бүлекләре. Аларның барысына да шпион һәм диверсантларны тоту буенча «план» үтәргә кирәк, җитмәсә, бүләкләү системасы да кызыктыра – 10 «хыянәтче» өчен медаль, 25 есе өчен орден бирәләр.

6 ай буе партизаннар сафында сугышкан элекке «ирекле»


За время пребывания в партизанских отрядах проявил мужество и храбрость в борьбе с немецкими оккупантами.
Участвовал в пяти открытых боях против немцев и румын. Участвовал в десяти боевых операциях и вместе с группой уничтожил 65 гитлеровцев, 3 автомашины, 1 мотоцикл.
Лично убил двух гитлеровцев. Во всех боях и операциях всегда был впереди

● Мәмәт Молочниковка бәяләмәдән.

З.Ибраһимов болай искә алган: *«1944 елның 15 апрелендә безнең отряд Ялтага керде. Күпмедер вакыт без шәһәрдә тәртип сакладык, аннары исә барыбызны да Кызыл Армиянең даими частьларына тапшырачакларын, аңа кадәр мунчага алып барып, хәрби форма бирәчәкләрен хәбәр иттеләр. Тик мине һәм иреклеләрнең Куыш ротасында сугышкан тагын 6 кешене мунчадан чыкканда НКВД хезмәткәрләре көтә иде. Бөтен «иреклеләрне» төрмәгә җибәрделәр. Аннары – хәрби трибунал утырышы һәм трибунал. Кемнедер 6 елга, кемнедер 10 елга, мине 15 елга хөкем иттеләр, бер егетне аттылар».*

Нәтиҗәләр

Партизан отрядларының нигезен партия-совет номенклатурасы тәшкил итәргә тиеш була, 1941 елның көзендә килачәктә Кырым партизаннар хәрәкәтенең үзгенә әйләнәчәк кешеләр арасында түбәндәге кырымтатарлар булуы билгеле:

Әбләзиз Османов – ВКП(б)ның Судак райкомы секретаре;

Әбибулла Әмәтов – ВКП(б)ның Сейтлер райкомы секретаре;

Әбләмит Ибраһимов һәм Әбибулла Вәлишаев – ВКП(б)-ның Алушта райкомы инструкторлары;

Бәкер Әбдишев – ВКП(б)ның Судак райкомы инструкторы;

Абдул-Шәһит Әмидов – ВКП(б)ның Бакчасарай райкомы инструкторы;

Абдул Әширов – Чкалов исемендәге колхоз рәисе;

Ибраһим Әмәтов – Ильич авыл советы рәисе;

Әсән Әбәсәнов – Алушта сәүдә базасы директоры...

Соңгы көннәрдә диярлек отрядларга махсус истребительный батальоннар килеп кушыла, бу партизаннар хәрәкәтен яхшырта, чөнки алар бик яшь, кичәге мәктәп балалары

●Әбләким Исаев.

●Ибраһим Әмәтов.

партизаннары

гына була: Сәйдали Курсәетов, шәфкать туташы Сара Фәхреддинова, шофер Әбләким Исаев... Барысы да җирле халык вәкиле, шәп спортчы, үз ватаннарының чын патриоты. Истребительный батальон сугышчылары партизан хәрәкәтенең каркасына, диңгезчеләр, чик сакчылары, Кызыл Армия командир-комиссарлары һәм сугышчылары исә – мускулына әйләнә. Менә алар арасындагы Кырым татарлары:

Мәмәт Молочников – 48 нче махсус кавалерия дивизиясеннән;

Абдрахман Мурадосилов – 172 нче укчы дивизия 747 нче укчы полкының рота политругы;

Әбләз Аединов – 51 нче армия сәяси бүлеге инструкторы, ул 5 нче Красноармейское отряды командиры була;

Зөлхә Алиева –184 нче укчы дивизия 294 нче укчы полкы хәрби табибе;

Мәмәт Аппазов – 9 нчы полкта взвод командиры;

Нафә Билалов – 48 нче махсус кавалерия дивизиясе хәрби юристы, һ.б.

1941–1942 еллардагы канкойгыч сугышлар нәтиҗәләре буенча бүләкләүләрнең шактый саран исемлегендә без кырымтатар халкының 30 кыю вәкилен күрәбез: Алиева Зөлхә, Әмәтов Әбибулла, Әмәтов Ибраһим, Аппазов Мәмәт, Әширов Абдул, Бинсәетов Умәр, Билалов Нафә, Вәлиев Смаил, Ганиев Бари, Ибраһимов Али, Исаев Әбләким, Исламов Сәет, Кавләмәтова Әзәй, Кадыев Сәетхәлил, Караев Ашир, Камилева Нажия, Курсәетов Сәйдали, Кучеров Ислам, Мәмүтов Әсән, Молочников Мәмәт, Мурадосилов Абдрахман, Моратов Курсәет, Мөслимова Һава, Османов Әбләзиз, Османов Бәкер, Топалова Һаҗия, Фәхреддинова Сара, Хәлилов Смаил, Хәлилов Әмир, Әмир-Алиев Сәет, Йосыфов Әмирхан.

Урмандагы хәрәкәткә 1943 елда килеп кушылган тагын 46 Кырым татары соңгы этапта батырлыгы өчен сугышчан бүләккә тәкъдим ителгән, әмма аннан мәхрүм калган.

Партизаннар хәрәкәтенең җитәкчелегендәге кырымтатарлар саны да таң калдыргыч: Аединов Әбләз – Красноармейское отряды командиры, һәлак булган; Әмәтов Әбибулла – Эчке отряды комиссары, һәлак булган; Әмәтов Бәкер – 6 нчы отряд комиссары, һәлак булган; Әмәтов Сәет-Али – 9 нчы отряд комиссары, качкан; Аппазов Мәмәт – төркем командиры, һәлак булган; Әширов Абдул-Кәрим – 8 нче отряд комиссары; Билалов Нафә – 1 нче отряд комиссары; Бәткәлиев Муса – Балаклава отряды комиссары, качкан; Газиев Гаффар – Балаклава отряды командиры, һәлак булган; Ибраһимов – Куйбышев отряды командиры, качкан; Измайлов Әсән – Судак отряды комиссары, качкан; Ильясов Әнвәр – 9 нчы отряд командиры;

Ирсмәмбәтов Исмаил – Кырым партизаннар хәрәкәте штабы башлыгының комсомол буенча ярдәмчесе; Исламов Сәйдәмәт – 6 нчы бригада комиссары; Кадыев Сәетхәлил – бригада командирының разведка буенча урынбасары; Колесников Җаббар – 3 нче бригада комиссары; Котбетдинов Бәкер – 9 нчы отрядның штаб башлыгы; Күртүмәров Рамазан - 17 нче отряд комиссары;

Мәмүтов Мостафа – 9 нчы отряд комиссары; Минаҗиев Сираҗетдин – 10 нчы отряд комиссары; Молочников Мәмәт – 1 нче отряд комиссары;

Моратов Курсәет – отряд комиссары; Моратов Рамазан – 2 нче отряд комиссары; Мортазаев Осман – 2 нче отрядның штаб башлыгы; Мостафаев Рефат – Көнчыгыш берләшмә комиссары; Османов Әбләзиз – отряд комиссары, һәлак булган; Сәлимов Мостафа – Көньяк берләшмә комиссары; Тынчеров Таләт – 4 нче отряд командиры; Хайруллаев Иззәт – 22 нче отряд комиссары; Хәлилов Әмир – Судак отряды комиссары; Әмиров Әсән – 20 нче отряд комиссары; Йосыфов Әмирхан – Судак отряды командиры, һәлак булган.

Исәп карточкасындагы «качкан» дигән ремарка уңаеннан: автор үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча, бу кешеләрнең күпчелеге һәлак булган, югыйсә сугыштан соң аларның исемнәре качкыннар исемлегендә калкып чыгар иде.

Владимир ПОЛЯКОВ,
тарих фәннәре докторы.
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА
тәрҗемәсе.

тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

13 май - «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
14 май – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
15 май - «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
17 май - «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
18 май - «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

13-31 май - Р.Нуриев исемендәге XXXV халыкара классик балет фестивале
13,14 май - «Щелкунчик» (П.Чайковский).
16 май - «Спящая красавица» (П.Чайковский).
17 май - «Жизель» (А.Адан).
19 май – «Алтын Урда» (Р.Ахиярова).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

18, 19, 20 май - «Кара пулат» (Э.Низамов).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

13 май - «Камыр батыр» (А.Житковский инсценировкасы).
14 май - «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).
15 май - «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).
17 май – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый).
18 май – «Ут чәчәге» (З.Хөснияр).
19 май - «Алтынч{ае}ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
20 май – 13.00 - «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.30 - «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

13 май – Түбән Новгород дәүләт курчак театрының «Конек-горбунок» спектакле (П.Ершов).
14 май – Зур залда – Түбән Новгород дәүләт курчак театрының «Конек-горбунок» спектакле (П.Ершов). Кече залда - «Су анасы» (Г.Тукай).
15 май – Зур залда – Түбән Новгород дәүләт курчак театрының «Кошкин дом» спектакле (С.Маршак). Кече залда - «Камыр батыр» (С.Хөсни).
17 май – «Маугли» (Р.Киплинг, Р.Таһиров инсценировкасы).
18 май – 11.00 зур залда - «Маугли» (Киплинг, Р.Таһиров исценировкасы). 11.00 кече залда - «Камыр батыр» (С.Хөсни). 19.00 зур залда – «Ханума» (А.Цагарели).
19 май – 11.00, 13.00 зур залда - «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман). 11.00, 13.00 кече залда - «Цветик-семицветик» (В.Катаев).
20 май – 11.00, 13.00 зур залда - «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов). 11.00, 13.00 кече залда – «Цветик-семицветик» (В.Катаев). 19.00 зур залда - «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

15 май – Ризван Хәкимов концерты.
16 май - «Рояль, вокал һәм джаз» дип исемләнгән концерт.
18 май – Композитор Кирилл Молчановның 100 еллыгына багышланган концерт.
19 май – Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары дәүләт оркестрының «Все начинается с любви» дип исемләнгән концерты.
20 май – «Мунча ташы» эстрада миниатюралары театры концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

16 май – Р.Ваһапов фондының «Микрофонсыз концерт»ы.

«Әдәби әсәрдә тарихилык» дигәндә без авторның ышандыру көчен күз алдында тотабыз. Ягъни әдәби әсәрдәге дөреслек ул тарихи мәүзугка язылган әсәргә генә түгел, бүгенге көн вакыйгаларын сурәтләүгә дә кагыла. Язучының иҗаты хакыйкатькә корылган булырга тиеш. Ләкин бар «тарихи хакыйкать» (документлар, риваятьләр). Бар «әдәби хакыйкать».

Әдәбиятта

Сөембикәнең кара тәкъдире турында ике әсәр бар. Берсе тарихи чынбарлыкка туры килә торган әсәр, икенчесе халык үзе чыгарган риваять, ягъни – әдәби әсәр. Соңгысында Сөембикә сабые Үтәмешне кочаклап, манарадан сикереп һәлак була.

Сөембикәнең әсир төшкәнен үз күзләре белән күреп, елый-елый аның көймәсен яр буйлап озата барган халык, ни өчен Сөембикәне манарадан «ташлаган»? Имәнгеч бер вакыйга! Татар халкы үзенең сөекле Сөембикәсен үзе үтерә булып чыгамыни?

Татар халкы Сөембикәне Кансыз Иван кочагында күрмәс өчен бу бәетне иҗат иткән. Һәм тарихи хакыйкатькә караганда әдәби хакыйкать халыкның күңелен яулаган.

Яшәгән ди мәшһүр шагыйрь Сирано де Бержерак: сугыш чукмары, мәхәббәттә бәхетсез, ямьсез чырайлы, алагаем зур борынлы бер француз егете. Күп үлемнәрне җиңеп, ул 36 яшендә тыныч кына үз үлеме белән дөнья куя. Бу – тарихи дөреслек.

Яшәгән ди драматург Ростан. Ул «Сирано де Бержерак» исемле пьеса язган. Әсәрдә Сирано ватанын саклап, кулына кылыч ала, иленә басып кергән дошманнарга каршы сугышта һәлак була. Тарихи Сиранодан 15 елга алда һәлак була. Бу пьеса Европа, Америка, Россия – бөтен дөньяда да йөз ел инде уңыш белән уйнала килә.

– Нигә тарихны бозасың, нигә дөресен язмыйсың? – дип Ростанны тарихчылар, әдәбиятчылар сүгәме? Юк! Ростан ялганчымы? Юк!

Менә монда «сәнгати хакыйкать» дигән төшенчә килеп керә шикелле. Сиранонның ватаны өчен һәлак булуы, тарихи дөреслектән дә дөресрәк, кирәгрәк икән. Тамашачылар Сиранонның үз ястыгына ятып вафат булганын беләме? Белә!

Тарихи Идегәй әмир белән дастанындагы Идегәй арасында аерма шактый. Һәр халыкның үз «Идегәе». Һәр язучының үз «Идегәе». Кайчак Идегәй халык каһарманы, кайчак Идегәй үз ватанына дошман явын чакырган сатлыкҗан сыйфатында килә.

Язучының тарихи вакыйгаларга үз хыялын өстәргә хокукы бар, ләкин тарихчының тарихи хакыйкатьтән ерак китәргә хакы юк! Әмма халкыбызның тарихи белеме җитәрлек булалмавы сәбәпле без– язучылар тарихи әсәрләр язганда тарихтан артык ераклашырга тиеш түгел, чөнки болай да мәгълүматсыз татар халкының зиһенен бутап ташлавыбыз бар!

Шуңа күрә, мин Сөембикә, Рудольф Нуриев, Тукай, Аксак Тимер, Заһидә Тинчурина, Шәймиев, Исәнбәт кебек шәхесләребез турында язганда тарихи хакыйкатьтән читкә тайпылмаска тырыштым.

Тарихи мәгълүмат бик саран булганда язучы ни кылырга тиеш? Әйтик, Сөембикә турында язма тарихта мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Сөембикә гүзәл, акыллы, батыр булган! Вәссәлам! Сөембикәнең сабый чагы турында мәгълүмат бөтенләй юк. Язучының фантазиясе бу юклыкны тутырырга тиеш. Тарихи мәгълүмат булмаганда язучының хакыйкате алга чыга. Һәм ул хакыйкать укучыны ышандырырга тиеш.

Кайчак тарихта ялган мәгълүмат та булырга мөмкин. Әйтик, Куликов сугышы турында тарихта бары тик ялган мәгълүмат кына. Ул сугышның кайда булганы да билгеле түгел. Куликов кырында йөз илле мең урыс гаскәре, ике йөз мең татар гаскәре кара-каршы сугышкан, имеш. Куликов кыры бик бәләкәй мәйдан ул, анда өч йөз илле мең сугышчы, өч йөз илле мең ат сыя алмый. Бу – тарихи ялган! Куликов кырында сынык сөңгеләр, ярык калканнар, ат сөякләре, кеше сөякләре табылырга тиеш иде. Берни дә юк, табылганнары да соңгы гасырларга карый. Имеш, Куликов сугышы урысларны татар коллыгыннан коткарган, дип яза урыс тарихчылары. Ялган! Беренчедән, Мамай гаскәрендә Алтын Урда ханы Туктамышның төмәннәре катнашмый. Урыс тарихчылары язганча, Мамай хан түгел, ул бары тик төмәнбашы, ягъни унмеңлек гаскәр генералы гына була. Дмитрий Донской, Туктамыш ханның вассалы буларак, ахмак төмәнбашы Мамайга каршы Туктамыш мәнфәгатьләрен яклап сугыша. Куликов сугышыннан соң Мәскәү 150 ел буе Алтын Урдага ясак түләп тора.

Яшь каләм ияләренә тагын бер тарихи мәгълүмат. Мәскәүдән Василий Икенче, Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәт үзен Мәскәү тәхетенә күтәрсен өчен ярлык сорап, Сарай каласына килә. Олуг Мөхәммәт Василийгә ярлык тоттыра, Василий ханның итегенә йөзе белән орынып, ханга мәңге тугры булырга ант итә.

Вакыт уза тора. Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәт, Кече Мөхәммәт фетнәсе аркасында, Алтын Урда тәхетен ташлап китәргә мәҗбүр була. Тәхетен кайтару өчен, ул Мәскәүгә (үзе тәхеткә утырткан) Василий Икенчегә ярдәм сорап бара. Ләкин Василий тәхетсез калган ханга ярдәм итәсе урынына аңа һөҗүм итә. Ханның үзе янында корал тотарлык бер мең кешесе була. Василийның гаскәре 30 000 сугышчыдан тора. Коточкыч сугыш-кырыш башлана. Олуг Мөхәммәт хан утыз меңлек урыс гаскәрен бер мең сугышчысы белән тар-мар китерә. Моны ничек аңлатырга? Сугыштан соң Олуг Мөхәммәт Казан ягына йөри һәм Казан ханлыгына нигез сала.

Мәңге тугры булырга ант иткән Василий Казанга һөҗүм оештыра, Муром ягындагы бу сугышта Василий яралanып, Олы Мөхәммәтнең әсир төшә, Олуг Мөхәммәт олы булып кала, Василийны дәвалап, Мәскәвенә кайтарып җибәрә.

Халык исеме буларак, Татар сүзе язма чыганакларда (борынгы Кытай архивларында сакланып калган кульязмаларда) безнең эрага кадәр (б.э.к.) 209 елда, ягъни моннан 2230 ел әүвәлдә күренә башлый. Димәк ки, безнең тарихыбызга 2230 яшь, ләкин безнең дәвергә чаклы 209 елгача да шушы исемдәге бу халык турында мәгълүмат бар.

Тарихчы Ма Туван-лин бу мәсьәләдә башка язучылар белән бәхәскә керә. Бу елларга (ягъни, б.э.к. 209 елга) күпкә алдан шушы халыкны милләте буенча шушылай билгеләү еш кулланылышта булган. Шул ук вакытлардан ук бу халык үзе белән санлашырдай көчкә ия булган. (Эдуард Паркер, «Татарларның мең еллык тарихыннан» исемле китап, 8 бит).

Б.э.к. 209 елда корылган бу дәүләтне «Беренче төрк каханаты» (аның каханы Тумын) булса да, әле ул вакытта кытайларга да, башка халыкларга да «төрк» атамасы таныш булмаган. Илнең башлыгы «кахан» дип аталмаган. Тумын үзенең патшалык хокукын һәм вазифасын «Җания» дип атый. Җания – патша, хан, солтан, шаһиншаһ, император мәгънәләрен үз эченә ала. Кытайчасы – «шаньюй». Кытай телендә «р» авазы һәм хәрефе булмаганга, төрки-татар халыкларда «р» авазы ырылдап торганга, кытайлар «р» урынына яки «ж» авазын, яки «л» авазын кулланган. «Рәфкат» исеме кытайча язылышта (һәм әйтелештә дә) «Жуфухати» була. Исемнәр



● Идел буе Болгары. X-XIII г.

кытай теле тегермәнендә тартылып, танымаслык булып үзгәргән. Җан – душа, ия – хозяин. Повелитель душ, ягъни халкының рухын саклаучы, дип аңлатып булыр иде. Шань–җан,юй – саклаучы.

Татар (да-да, та-тань) атамасын б.э.к. 209 елда очрата башлыйбыз. Әмма Ма Туван-лин хәбәренә күрә, без бу атаманың тагын да борынгырак заманнарда кулланылганын белгән идек. Ләкин кытай архивында сакланган язмаларда бу халык «хиен-ну» дип тә йөртелә. Шуннан бу атама да үзгәрешләр кичерә: хунну, кунну, гунну, һуннар. Ләкин кытай телен озак еллар өйрәнгән галим үзенең «Татарларның мең еллык тарихыннан» исемле китабында кытай чыганакларыннан «да-да» турыдан-туры «татар» дип тәрҗемә иткән. Әмма хиен-нулар, скифлар, кыргызлар һәм башка төрк халыкларын үз эченә берләштергән телләре бер, йолалары бер, яшәү рәвешләре бер булганга борынгы тарихчылар ат өстендә туган, ат өстендә үлгән, киез йортларда, тула тирмәләрдә, хайван тиресе белән каплаулы өйләрдә яшәгән, җылкы ите ашаган, кымыз эчкән күчмә кабиләләренең барысын да «татар» дип атаулары табигый хәл. Мәсәлән, әзәрбайҗаннарны, гомумән, урыс булмаган башка халыкларны да «татар» дип атау гадәти хәл булган. Ләкин татар атамасы гасырларны, мең елларны узып, исән-сау бу көннәргә килеп җитеп тә, күп миллионлы милләт булып яшәве, телләрнең бик якын торуы, борынгы һәм кайбер бүгенге йолаларның уртак булуы чыннан да без – бүгенге татарлар ике мең елдан да артык дәүләт корып яшәгән, дип горурлана алабыз. Безнең бу тарихыбыз уртак, әйтик, Атилла кемнең милли каһарманы, Идегәй кемнең батыры? - дип сорау куелганда, без «бөтен төрк телле халыкларныкы да», дип әйтә алабыз.

Ләкин «төрк-тюрк» атамасы язмаларга, кытайларга, башка халыкларга V гасырда гына килеп керә башлый. Ул вакытта хан да, кахан да, каханат та була алмый. Дәүләтчелеге була татарларның, әмма ханы, каханы булмагач, «төрк каханлыгы» атамасы да була алмый. «Хан» атамасы «кахан-каган» сүзеннән аерылып чыккан, дигән фикер бар. Чыннан да «кахан» сүзе ул «император»га туры килә. Ягъни, күп ханлыкларны буйсындырган түрәнең «кахан» дип аталуы табигый. Шуңа күрә, без «каган, каганат» дип язмыйбыз, ә бәлки «кахан, хан» дип язабыз. «Төрк-татар каханлыклары» дип язсак, тагын да дөресрәк булыр иде кебек. Чөнки казахлар да, үзбәк, әзәрбайҗан, төрекләр дә, төркмән, хакас, тыва, башкорт, нугайлар да, балкар, карачәй, кумык, чуаш, каракалпак, гагауз, уйгурлар да, хәтта мангул, бурят, калмык, төрекләр дә бу каханлыкларны корyда катнашкан халыклар.

Хиен-ну (татар) гомере буе ат өстендә, татар ат сыртында туа, ат сыртында үлә, дигәннәр. Татар монда туа, еракта үлә, дигәннәр. Атсыз татар – адсыз татар, дигәннәр.

Бу очракта ат – сугыш аты, ад – исем, ягъни «аты булмаган татар исемсез, даньсыз, абруйсыз татар», дигән сүз. Төркләрнең «адсыз калдын татар агасы» әйтеме нәкъ безнең турыда. Атсыз да, исемсез дә, абруйсыз да калды татар.

Җылкы ите җыймаган, кымыз чөмермәгән татар татар түгел! – дигәннәр. Атың булмаса, атаң сыртын атлан, дигәннәр. Ягъни, сине балачактан ат белән тәэмин итә алмаса, атаңны җик, дигән сүз. Заманчасы: «Жигулиең булмаса, атаңны җик!»

Татарның мендәре – ияр, ястыгы – туфрак, юрганы – күк йөзе, дигәннәр.

– Татар беркайчан да ат ите ашамаган, ашамый һәм ашамаячак! – дип әйтүчеләр бар.

– Мин кичә генә кунакта ат ите ашадым.
– Димәк, син татар түгел!
– Син үзең дә ат ите ашыйсың бит.
– Юк! Мин ат ите ашамыйм, мин җылкы ите ашыйм!
– Нәрсә ул – җылкы?
– Җылкы да – ат нәселеннән, ләкин җылкы ул – җигелмәгән, ияр салынмаган, айгыр алмаган, ике яшьлек махсус

тарихилык

● Алтын Урда. XIII-XV г.

симертелгән бия. Татар беркайчан да үзен сугыштан исән алып чыккан сугыш атын суеп ашамаган. Татар беркайчан да җир сөргән алашаны суеп ашамаган. Татар беркайчан да ярышта катнашкан чабышкыны суеп ашамаган. Ханнар, падишалар, бәкләр, мирзалар, кулаклар, хәлле татар җылкы ите, куй ите, дөя ите, сыгыр-бозау ите, кәҗә ите, кош ите, балык ашаган.

Татарларның иң затлы эчемлеге кымыз, аннан кала – буза, аннан кала – бал.

Татарларның иң затлы ризыгы – җылкы ите, ялы, картасы, казысы.

Татарларның байтак ризыкларының атамасы да «к»дан башлана.

Кабартма, Каз, Казы, Каймак, Как (җиләк кагы, әлү кагы, әлван кагы), Каклаган каз, Кан тәбәсе (керәшеннәр ризыгы), Калач, Карбыз, Карлыган, Катлама, Катык, Кәлҗемә (крахмал), Кәрәкә, Кәрәч, Кәбестә кучәне, Кәрчемә (кәеф ача торган эчемлек), Коймак, Койрык (куй, бозау, җылкы койрыгы), Корот, Кукы (какы), Куллама, Куырма, Кыздырма куян, Күкәй, Күкәй тәбәсе, Күмәч, Күзикмәк, Күркә ите, Кыстыбый, Кыздырылган кузы (бәрән, бәкәй ите), Кызыл эремчек, Кымыз, Кыртыш (керәшеннәр ризыгы, тиресе белән какланган чучка ите), Кыяк (суган, сарымсак кыягы), Кыяр...

Хәзерге заманда «раздельное питание» дигән нәрсә модага кереп китте. Имеш, ит белән ипине бергә кушып ашау, ул ашказанына бик авырга килә. Борынгы бабаларыбыз моны әллә кайчан ук белгән. Ит янына беркайчан да бабаларыбыз ипи куймаган. Беренчедән, далада ит күп булган, ипи аз булган, ипи иттән кадерлерәк саналган. Ипине, икмәкне, ханны, кумәчне аерым ризык буларак табынга куйганнар.

Ризык кабул итү (ашау) тәртибе болай булган:

Иң беренче кунакларга чәй тәкъдим ителәә. Аннан соң коры ризык: ит, бәлеш, яки балык ризыгы. Аннан соң шулпалы аш бирелә. Шулпадан соң тагын икенче ризык табынга чыгарыла. Тыгыз ризыклар шулпалы ризыклар белән аралаштырып бирелә. Иң соңыннан тагын чәй белән тәмамлана.

Утрак тормышта,урманда, урманга якын авылларда яшәгән татарлар чолыкчылык белән шөгыльләнгән. Кыргый умарталарга җыелган кәрәзле балны җыеп ашаганнар, бал сатып көн күргәннәр. Балдан әче бал (исерткеч), ширбәт ясап эчкәннәр.Чолыкларга җыелган бал гаять хуш исле, тәмле. Чолыкчылыктан умартачылык һөнәре башланып киткән. Корыган юкә (соян) агачын кисеп, черек эчен тазартып, киселгән кисмәкнең төбен каплап, түбәсен куеп, бал кортларына кереп-чыгып йөрер өчен ярык калдырып, умарта ясаганнар. Шулай итеп, умартачылык белән көн күргән борынгы бабаларымыз.

Зур шәһәрләрнең зур мәйданнарындагы сулыклар, бассейннарга тимер акча ташлауны күргәнегез бар. Имештер, чишмәгә-коега акча ташласаң, син бу сулыктан киләчәктә тагын су эчәчәксең. Ләкин бу йола борынгыдан килә. Чүлләрдә су юк. Сәүдәгәрләр кәрваны йөри торган юл кырыенда байлар казыткан коелар булган. Кое – казыткан кешенең исеме белән аталган, Комбар ата Коесы, Сәхиулла Коесы... Шушы коелар янында су белән тулган улаклар, кавузлар булган, җыелган суны юлчылар, атлар, дөяләр, куйлар эчкән. Юлчылар, кәрванчылар шушы кавузлардагы суга алтын-көмеш акчалар ташлап китә торган булган. Кое караучы шул акчаларны җыеп, кое казыткан кешегә биреп барган. Ул акчалар кое казучыга хәер, сәдака булып ирешкән.

Борын-борыннан дала кабиләләре оланнарны сугыш, ау һөнәренә сабый чакларыннан ук өйрәтә башлаган. Сабыйлар башта сарыкка атланып, җәядән ук атып, күсе-тычкан ауларга өйрәнгән. Үсә төшкәч, оланны юаш атка атландырганнар да олырак җәя биреп, куян, төлке ауларга алып чыкканнар. Һәр олан ит ашаган, сөт эчкән. Бераз үскәч, аңа җитез ат биргәннәр, кулына санай җәя, еракка ата торган җәя тоттырганнар. Сугыш җәясен тарттыра алса, үсмер егет яугир санала башлаган.

Әгәр дә ата кеше картаепмы, яудамы вафат булып китсә, аның тол калган хатыннарын әлеге олан алырга тиеш булган. Үз анасыннан башка. Һәлак булган абыйсының хатыннарын мәрхүмнең энесе үзенә хатынлыкка алган.

Без бу йоланы риваятьләрдә, әдәбиятта да очратабыз. Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» исемле трагедиясе нәкъ шушы йолага корылган.

Б.э.к. (безнең эрага кадәр) 210 елларда татар түрәсенең дәрәҗәсе «Тәнре Котый Җания» дип аталган. Кайберәүләр бу дәрәҗә атамасын болай тәрҗемә итә: «Тәңре углы Җания». Күренеп тора ки, бу татар сүзе «кот» Ана телебездә бүген дә киң кулланыла, ул җан, кот, котсыз, котым ботыма җитте, котымны алдың, кот очарлык, кот чыгарлык, бу йортның коты калмаган кебек гыйбарәләрдә көн саен кулланыла. Димәк ки, «Тәңре котый» гыйбарәсен «Тәңре биргән Җаниясе» дип тәрҗемә итеп буладыр шәт.

Җаниянең кытайдан алган катыны Инчи (энҗе) дәрәҗәсен алган.

Бүгенге Сабан туебызны без бик борынгыдан килгән бәйрәмебез, дип сөйләргә күнеккәнбез. Ул чыннан да шулай, Сабан туе ул Исламга чаклы бик күп еллар әүвәл барлыкка килгән. Кайберләребез Сабан туе ул Римдагы Олимпия уеннарының күчермәсе, ди. Олимпия уеннары дүрт елга бер генә узган. Сабантуе исә һәр елны уза тора. Сабан туе юнан-грек, Эллада халкыннан алынган, дигән сүздә дә хаклык бар кебек. Борынгы бабаларыбыз эскифләр Византия, юнан, Румелия белән нык бәйләнештә булган. Татарларның борынгы бабасы (Эскиф) түрәсе Гонур Рум кызына өйләнеп, Эскифиягә, Днепр, Кырым якларына алып кайтып китә. Аларның Анахарсис исемле уртак уллары туа. Эскифчә дә, элладача да яхшы белем алып, Анахарсис Элладага барып, атаклы фәйләсүф булып китә. Бу хәл б.э.к. 676, ягъни 2346 ел элек була. Эскиф далаларында Сабан туе гөрли, Элладада олимпия уеннары гөрли. Бу йоланы кем кемнән алган? Белгән юк. Ләкин Анахарсисның гомере фаҗига белән тәмамлана. Ватанына кайткач, аны үзенең ир кардәше ук атып үтерә. Эллиннарда тәрбия алганга күрә, Анахарсис эллин йолаларын эскифләргә кертергә маташа, ул эллин ягына каерылып каткан, дип аңа гаеп ташлыйлар.

Кытай чыганакларында Сабан туена охшаш олы бәйрәмне сурәтләгән язма бар. Бу бәйрәмне һәр Яңа елны каршылаганда татар дәүләтенең башында торучы Җания үзе оештыра торган була. Бу хәбәр сәяхәтче Марко Поло китабында да бар.

Ул башта Сабан туе дип аталмаган, күрәсең, ул башта Җыен (корылтай, тупланыш) дип аталган. Без үскәндә дә «Җыен» аерым, «Сабан туе» аерым бәйрәм иделә иде. Соңыннан гына аларның икесен берләштерделәр. Җыен ул аксакалларның үзара киңәше, голәма мәсьәләләрен уртага салып хәл итәр өчен туплана иде. Бу Тәнречелек заманнарыннан ук шулай булган, башта җыен узгарылган, хөкем чыгарылган, аннан соң бәйрәм ясаганнар. Тәңрегә олы-олы рәхмәтләр укып, иң башта борынгы бабалар рухына атап корбан чалганнар. Аннан соң Күккә (Тәңрегә, Кояшка), соңра Җиргә, соңра рухларга, әрвахларга атап корбан чалына. Корбан итен бәйрәм ясап, бөтен (будун) халык бергә ашый. Аннан соң ат узышлары, дөя ярышлары башлана. Узышларны да Җания күзәтә һәм үзе нәтиҗә чыгара.

Димәк, Сабан туе бәйрәменә 2813 ел тула.

Рабит БАТУЛЛА.

Айга карын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

14 май (шимбә). ***Шәүвәл аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,17.21 сәгатьтә калка, 3.17 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.13 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бирgәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Чәй сихәте (1)

Чәйдәге кофеин (теин) үзәк нерв системасын ярсыта, фикерләү сәләтен арттыра. Танин исә бик яхшы абсорбент, ул әгъза һәм тамыр тышчаларындагы зарарлы матдәләрне үзенә сеңдерә. Чәй гомерне озынайта, организмга хроник авырулар килеп чыгуны кисәтә торган микроэлементларны (бакыр, тимер, марганец, калий) кертә, кан тамырларын киңәйтә, мускулларның сыгылмалылыгын арттыра.

15 май (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,18.57 сәгатьтә калка, 3.31 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.16 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Чәй сихәте (2)

Чәй кандагы холестерин микъдарын киметә, вирусларны үтерә, иммунитетны көчәйтә. Андагы антиоксидантлар Е витаминының тәэсирен арттыра һәм бавыр күзәнәкләрен саклый. Чәй атеросклерозны кисәтә, радиоактив нурланышка каршы торырга булыша, организмның кан ясау эшчәнлеген һәм калкансыман бизнең вазифаларын торгыза, сөякләрдән стронцийны чыгара, күз күремен яхшырта. Чәйне 85-90 градуслы йомшак чишмә суында пешерсәң, аның бөтен файдалы сыйфатлары саклана.

16 май (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,20.37 сәгатьтә калка, 3.52 сәгатьтә бата. 7 сәгать 14 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 16.20 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлы булу сорала. Үпкәләшүчән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Инсульт билгеләре

Табибләр әйтүенчә, инсульт булганнан соң өч сәгать эчендә үк ярдәм күрсәтелсә, ул организмга зыян китереп өлгерми. Инсульт булганмы-юкмы икәнне белү өчен, кешегә елмаерга кушарга кирәк (ул елмая алмаячак); гади җөмлә әйттереп

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

карыйлар; ике кулын да өскә күтәрергә кушалар (күтәрә алмый); телен чыгарырга кушалар (монысын да эшли алмый). Әгәр шул билгеләрнең берсе генә булса да, тиз арада табиб чакырту мөһим.

17 май (сишәмбе). ***Шәүвәл аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 22.14 сәгатьтә калка, 4.26 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.24 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Банан ютәлне баса

Озакка сузылган ютәлдән интеккәндә, болай дәваланып була. Өлгергән ике бананны изеп, өстенә 1 стакан кайнар су салалар, бераз шикәр кушалар, утка куеп җылытып алалар һәм шушы катнашманы көн дәвамында җылы килеш әкренләп эчеп бетерәләр.

18 май (чәршәмбе). ***Шәүвәл аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 23.36 сәгатьтә калка, 4.49 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.28 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

19 май (пәнҗешәмбе). ***Шәүвәл аеның 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 5.20 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.31 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Лимон тырнакны ныгыта

1 аш кашыгы лимон согына бер чеметем тоз кушып болгаталар да, тырнакларга сөртеп 15-20 минут тотканнан соң, җылы су белән юалар. Яки 1 стакан җылы суга 1 аш кашыгы тоз, 3-5 тамчы йод өстәп болгаталар, бармакларны шуңа тыгып, 15-20 минут тоталар.

20 май (җомга). ***Шәүвәл аеның 19 нчы көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 0.33 сәгатьтә калка, 6.38 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.34 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Онсыз шоколадлы печенье

125 г атланмайга 180 г ачы шоколад кушып, микродулкынлы мичтә эретәләр; миксер белән 5 йомырканы күпертәләр, 130 г шикәр, ярты чәй кашыгы тоз өстәп күпертүне дәвам иттерәләр; аннары шоколадлы май, 50 г какао,1 чәй кашыгы камыркөпшәкләндергеч өстәп, миксер белән акрын тизлектә болгаталар, диаметры 22 см табага җәеп, тигезлиләр дә, 180 градуслы мичтә 25-30 минут пешерәләр, ванильле туңдырма белән ашыйлар.

Яшьлеккә, туган җиргә мәдхия

Ринат Мөхәммәдиевнең Татарстан китап нәшриятында чыккан яңа китабы исеме белән үк игътибарны җәлеп итә – «Кайларда сез, авылдашлар...» Әлеге риторик сорау күпләр өчен уртак, чөнки авылда туып-үскән кеше өчен аннан да кадерле җир юктыр. Ә инде язучының авылдашларына эндәшүе артында хәтер чишмәләре, истәлек сәхифәләре һәм җан сыкравы ишетелә...



Китапка әдипнең авыл турындагы хикәя-повестьлары туплап бирелгән. Аларны туган ягына, җиренә, аның гаҗәеп кешеләренә булган ярату, олылау, сагыну хисе белән үрелгән сыкранулы аһәң бербербәләштерә. Дөрес, Р.Мөхәммәдиевнең бөтен язганнары милләт гаме белән сугарылган. Аның бай иҗатында күтәрелгән гаять төрле һәм катлаулы әхлакый, иҗтимагый, сәяси, фәлсәфи мәсьәләләр милли яшәеш белән тыгыз бәйләнештә ачыла. Әмма әлеге китаптагы авыл белән бәйле әсәрләр үзгә бер яңгыраш ала, аларны автор образы, аның туган җиренә булган ихлас хисләре, үткән һәм бүгенге бәйләнешендә чагылган яшәеш сорауларыннан туган әрнүле уйлары иңләп үтә. Җыентыктагы әсәрләрнең күбесе, алданрак басылып, укучыларга килеп ирешкән иде. Әдипнең туган ягына, туган авылына, әти-әнисенә һәм игелекле якташларына багышланган әсәрләрен кабаттан уку яңадан яшьлек иленә алып китә, ашкынулы-хисле халәт тудыра. Р.Мөхәммәдиевнең сюжет кору, вакыйга-күренешләрне җанлы итеп гаҗәеп уңышлы тел-стиль чаралары ярдәмендә күз алдына бастыру осталыгы үзеннән җибәрми. Алай гына да түгел, геройлары язмышы синең дә язмыш булып китә.

Җыентык «Кирмән башым минем» дип аталган публицистик язма белән ачыла. Автор туган авылының тарихына бәйле даннлы да, фаҗигале дә сәхифәләрне барлый, аларның ил-халык язмышыннан аерылгысызлыгын раслау аша бүгенгесенә килә. Халкыбызның милли бишеге, рухи-әхлакый яшәешебезнең чишмә башы булган авылның бетеп баруын күреп сызлана. Әхлак һәм иман башлангычына янаган куркынычның милләт киләчәгенә барып тоташуын кат-кат искәртә. Бу мәсьәләдә аның фикере икеләнүне белми: татарның менталь сыйфатлары, традицияләре, борынгыдан килгән яшәү рәвеше бары тик авылда гына тулы бөтенлегендә саклана ала, шуңа да татар авылын саклап калу дәүләти әһәмиятле мәсьәлә булып тора. Бай тарихка ия булган дистәләрчә авылларга бетү, юкка чыгу куркынычы яный. Бу афәттән ничек котылырга? Моңа әзер җавап юк, шул ук вакытта үз асылын саклап яшәгән авыллар гыйбрәтле үрнәк була ала. Илбашыннан алып, туган авылыннан чыгып киткән һәр кешегә кадәр – һәммәбез бу турыда уйлансак, билгеле бер эш-гамәл кылуга килсәк иде. Р. Мөхәммәдиев авылдашларына һәм китап укучыларга әнә шул фикерне җиткерергә тели.

Җыентыктагы хикәя-повестьларда Нурлы Алан авылының гомумиләштерелгән образы калкып чыга. Хикәяләүче йә бала, йә яшүсмер, йә өлкән кеше күзе белән туган авылының гүзәл табигатен, ярата һәм яраттыра белүче яшьләрен, сөйкемле карт-карчыкларын күз алдына бастыра. Тегеяисә бу вакыйгага бәйле геройларын әхлакый сынау алдына куя. Шул рәвешле Нурлы Алан авылының күпләр хәтерендә саклана торган кешеләре чорның үзенчәлекле типлары буларак калкып чыга. Алар гади һәм гадәти булулары, ихласлыклары, беркатлылыктан котыла алмаган характерлары белән безгә якын. «Фәрештә канаты», «Әкбәр бабай», «Күңел күзе», «Перәннекле төшләрем» хикәяләрендә зурлар тормышына бала психологиясе аша мөнәсәбәт белдерелә. Автор тудырган җанлы тормыш күренешләре беркемне битараф калдырмый, аларда кеше шәхесе формалашу бара. Вакыйгаларда халкыбызның иң матур сыйфатлары – миһербанлылыгы, ярдәмчеллеге, сабырлыгы ачыла. «Әкбәр бабай» хикәясендә 7 яшьлек малай өлкәннәрнең икмәккә булган ихтирамын күзәтә һәм хөрмәтнең үзара мөнәсәбәтләргә күчүе турында нәтиҗә ясый. Әлеге күренешкә капма-каршы рәвештә колхоз рәисе Сафинның кукуруз арасыннан чүп үләне җыйган малайларны рәнҗетүе, аларны яклаган Әкбәр бабайга камчы күтәрүе сурәтләнә. Колхоз рәисеннән үч алу теләге белән йөргән малай көтелмәгән хәбәр ишетә. Әкбәр бабай, буранлы төндә, егылып имгәнгән колхоз рәисен район сырхауханәсенә илтеп, аның гомерен саклап кала. Хикәяләүче гыйбрәтле вакыйга аша тәрбия дәресе биргән Әкбәр бабай алдында тирән хөрмәт белән баш ия. «Чияләнгән төен», «Безнең әниләр бәхете» хикәяләрендә әти һәм әнинең онытылмас образлары алга килеп баса. Тормыш шартлары туган яктан читкә алып китсә дә, ата-анага булган якынлык гомер буе озата бара. Меңнәрнең күңел сыкравы булып калган ата-ана белән очрашу һәм саубуллашу, аны үзгәртү мөмкин түгеллеге гаҗәеп уңышлы ачкыч-метафора булып килгән «Чияләнгән төен» исеменә чыгарыла.

Ринат Мөхәммәдиев хикәяләрен сызлану хисе иңләп үтә. Балачагы сугыштан соңгы елларга туры килгән автор үткән гасырның 50-60нчы елларына күз ташлый һәм кеше шәхесен санга сукмаган системага әрнү хисе ташып чыга. «Тик безнең илдә генә» хикәясендә җәмгыятьтәге гаделсезлек һәм аннан котылу мөмкин түгеллеге ачыла. Сугыштан әсирлеккә төшеп, Сталин лагерьлары аша үткән Хуҗа абый язмышы күздән яшь китерә. Ел саен Җиңү көнендә клубка ветераннарны җыеп бәйрәм ясаганда, каршыдагы өйдә яшәгән Хуҗа абый ниләр кичерде икән? Әнә бит, авыл куштаннары хәзер дә аны кимсетүдән чирканмый. Ә яшәргә кирәк. Илдәге ялганның, күзбуяуның бер чагылышы буларак җыр яңгырый: «Иркен-рәхәт, матур тормыш тик безнең илдә генә...» Күзләре үкенүле, сызланулы яшь белән тулы Хуҗа абый да җырга кушыла...

«Күңел күзе», «Җавап эзлим» хикәяләрендә сурәтләнгән Зөфәр, укытучы образлары кемне генә битараф калдырып икән? Әлеге гыйбрәтле язмышлар аша автор мәхәббәт һәм нәфрәт, рухи һәм матди байлык, яшәү мәгънәсе кебек мәңгелек кыйммәтләр турында уйланырга этәрә. Тормышта ялганга баш бирү, сүздә бер, ә гамәлдә икенче төрле булуның яшәү принцибына әверелүе җәмгыятьтәге әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүенә китерә. «Фатыйма апа» хикәясендә гомере буе сугыштан кайтмаган ирен көтеп ялгыз яшәгән, намусына «кер түгел, тузан да кундырмаган» Фатыйма әби һәм колхозга бер атнага эшкә килгән Эльмира сурәтләнә. Тыштан ялтырап торган яшь хатынның, ире, баласы була торып, чит ирләр белән «типтереп» йөрүен белгән әби аң-акылын югалткан кешедәй тораташтай катып кала. Тормышта очраган мондый хәлләргә бәя бирү укучы өлешенә калдырыла.

Җыентыкта урын алган «Ак кыялар турында хыял», «Истәлек өчен – Гыйлемханга...», «Беренче умырзая» повестьлары татар авылы турында тулы бер цикл тәшкил итә. Байтак еллар элек язылган әсәрләр бүген дә заманча яңгырый. Автор күтәргән мәсьәләләр милли эчтәлек белән сугарылып, гомумкешелек кыйммәтләренә алып килә. Р. Мөхәммәдиев татар әдәбиятының иң матур традицияләренә таяна, аларны үстерер, сәнгати табышлар белән баета. Беренче повестьта уйланма катлам, аллегорик һәм символик образлар аша яшәештәге әхлакый һәм фәлсәфи сорауларга җавап эзләүгә китерә. Чит җирдән китерелгән кәҗә Микәй белән бәйле сәер-серле вакыйгалар борчу тудыра, әрнетә, шуның белән битарафлыктан чыгара. Алар артында яшәешкә үтеп кергән эчкечелек, әхлаксызлык күренешләрен хуплаган система идеологиясен фаш итү, сарказм аша кире кагу чагылыш таба. «Истәлек өчен – Гыйлемханга» әсәрендәге вакыйгалар үткән-хәзерге бәйләнеше аша киләчәккә йөз тотып язылулы белән күңелгә кереп кала. Яшәешнең нигезе яратуда – Аллаһны, туган җирне, ата-ананы, сөйгән ярны... Ярата белү өчен кешенең тормыштагы матурлыкны күрә белүе кирәк. Матурлык исә күңел байлыгы белән генә үлчәнә ала. Вакыйгаларда рухи матурлыкка омтылу белән акча колы булу арасында тартыш бара. Ул соңгысы файдасына тәмамлана һәм шуның белән укучыны сискәндереп җибәрә. Шуның белән повесть бүгенге күп сорауларына җавап эзләргә ярдәм итә. «Беренче умырзая» повесте яшьләр турында, яшьләргә һәм... барыбызга да атап язылган. Автор яшьлеккә, мәхәббәткә, сафлыкка мәдхия укый. Геройларның хис-кичерешләре, эш-гамәлләре тирән лиризм һәм психологизм аша чагыла. Вакыйгаларда татар авылында барган үзгәрешләр, әхлакый кыйммәтләрнең урыны, кеше һәм табигать мөнәсәбәте, бигрәк тә Нурлы Алан чишмәләре белән бәйле хәлләр матур тел белән җанда уелып калырлык итеп сурәтләнә. Шул ук вакытта әсәрне гомер агышы, хикәяләүченең үткән яшьлеге, күңеленә якын авылның үзгәреше белән бәйле үзгә бер моңсулык иңләп үтә.

Гомумән, Ринат Мөхәммәдиевнең туган җир, балачак иле, авылдашлары тормышы белән бәйле вакыйгаларны үз эченә алган әсәрләре ихласлыгы, тормышчанлыгы, сәнгати эшләнеше, автор фикерләренең мәгънәви тирәнлеге белән китап укучылар күңеленә хуш килер дип ышанам.

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ.

Рәис САФИН кытыклары

Дөрес әйткән

Хәзерге балаларның уйлы-зиһенле булуларына исем китә.

Беркөнне оныгыбыз Раянның әбисе, әле күптән түгел генә кодалашкан кодагые янына җыена.

– Барып, хәлләрен белешеп, берочтан танышып та кайтырга булдым әле, – ди ул, кызының соравына җавап биреп.

– Әби, күрешеп кайтырга, дип әйт. Сез аның белән таныш бит инде, - ди, Раян уенчыклары белән мәш килеп.

Бүлешкән

– Мин дә авыз итимче, – ди әбисе, күпереп пешкән, кып-кызыл кура җиләге ашап утыручы оныгы Раян янына килеп. – Әйдә бүлешәбез, – ди, Раян, җамаяктагы җиләкне башка савытка бушатырга керешеп.

– Рәхмәт, улым. Бүлешә белгәнең өчен рәхмәт. Рәхим-шәфкатьле, игелекле кеше булып үс, – ди әбисе, оныгын кочагына алып. – Җиләкне алып кайткан әнигә рәхмәт, – ди Раян, әбисе кочагына сыенып.

Афәрин

Туган көне белән тәбрикләргә килгән кунакларны да Раян шаккатырды. Ул үзен мактап: «Молодец, ул безнең Раян», – дигән берәүгә: «Молодец» дип түгел, «Афәрин» дип әйтергә кирәк. Шулай дөрес була – диде әни. Син дә «Афәрин» диген, – диде Раян, балаларга самими бер горурлык белән тотлыга-тотлыга.

Бичара

«Кесәсеннән йодрык күрсәтеп йөри» дип,
Дөрес әйткән тәнкыйтьче зат кая китте?
Бүген татар шундый хәлгә килеп җитте –
Кесәдән дә йодрык күрсәтүче бетте.

Күкрәк суккан, төкрек чәчкән ир-егетләр,
Өнсез калды милләтпәрвәр аталганнар.
Бәндә булмыш гамьсез каләм әһелләре,
Дер калтырап, юрган астына посканнар.

Бәндә ул – кол, илсез-җирсез, хак-хокуксыз,
Юктыр аның дәрәҗәсе җәмгыятьтә.
Гамәленә күрә – әҗере дигәндәй,
Урыны да булыр аның акыяттә.

Бер сүз әйтсә, биш караныр як-ягына,
Ишетмәде микән диеп кеше-кара.
Милли рухы, милли төсе, иман көче...
Бетеп барган алар бүген бер бичара...

Тормыш

Очканда карлыгач алдынгы,
Сайраганда – сандугач.
Оча белгән сайрый белми,
Моң дигәне булмагач.

Сайрый да, оча да белмәгән
Хөсетлектән буыла.
Сайрый белгән, оча белгән
Үз иленнән куыла.

Ашыйсы килмәгән

Авылыбызның солдат хезмәтендә булган Рәхимҗан исемле егете кунакка кайта. Авылдаш туганнары зурлап-хөрмәтләп, мул табын әзерләп кунакка дәшә.

Үзебезнең милли ризыкларыбызга тансыклаган егет бик кыенсырамый гына, әвен сугып кайткан кеше сыман тәгамнәрне мактый-мактый, солдатларча иттереп ашап куя.

Озак көттерми генә, табын күрке, кунакларның яраткан сые булган, тәмле хуш исләр бөркеп торган бәлеш тә килеп утыра.

– Әйдә, бәлешне дә авыз ит, – диләр.

– Юк. Нигәдер ашыйсым килми, – ди солдат.

Авыл халкы кешегә кушамат тагарга һәвәс бит ул. Егеткә дә «ашыйсым килми» кушаматы чәпәп куялар.

Әтисе җибәрмәгән

Алма пеш, авызга төш дип, диванда кырын ятудан арыган Мөнир карт беркөнне карчыгы Гайшәгә болай ди:

- Карчык, әллә дим, яшь чакларны искә төшереп, хыялый очрашуларга баргалап йөрик мәллә. Һич югында урамнарны бер әйләнеп кайту булыр.

- Кем белән, нинди очрашуларга йөрмәкче буласың инде син?

- Синең белән. Нәкъ яшь чаклардагы кебек иттереп. Әйтик, мин сине Кызыл капка янында зарыгып көтеп торам, ди. Ә син, һәрвакыттагыча бизәнеп, хушбуйлар сөртеп, һавалы кыяфәттә очрашуга килерсең.

– Шуннан?

– Шуннан, элеккечә итеп кинога чакырыр идем дә, тик мәдәният сараенда янгын чыгып, ул көлгә әйләнгән. Урыны ташландык хәлдә нәүмизлектә тора. Яраткан пломбир туңдырмасыннан авыз иттерермен дип уйлыйм.

- Хәзер ул да, элеккеге туңдырма кебек тәмле түгел. Балландырылган сөткә бераз нindидер май кушып ясалган нәрсә булып калган.

– Ә шулай да, юкса, мин ул тирәләрне, кибетләргә барышлый-кайтышлый һәрчак сагынып урап үтсәм дә, синең белән очрашырга бик теләп барачакмын, - ди, Гайшә ханым, ризалыгын белдереп. – Берочтан кибетләргә кереп, кирәк-яракларны да ала кайтырга кирәген дә онытмыйк.

– Рәхмәт, хатынкаем. Сихәтле сүзләрең күңелемне күтәреп җибәрде. Тик син зинһар инде, һәрвакыттагыча, соңга кала күрмә. Яшь чаклар түгел, озак басып торырга авыру аяклар чыдамас.

- Тырышырмын. Хәер, мин элек тә соңга калмый идем. Вакытында килдем. Тик бер почмакка посып, мине түземсезлек белән көткәнеңне күрүдән җаным рәхәтлек кичерә, күңелем була иде. Сине шулай сынап, ярата икәнеңә ышандым.

– Син дә минем сөекле кешемә әверелдең. Барысы өчен дә рәхмәт сиңа. Сау-сәламәт бул. Гомерләре буе ихлас мәхәббәтләренең сафлыгын саклап яшәгән бу мөхтәрәм затларның нурлар чәчеп торган күз карашлары очрашудан фатир эче яктырып китә.

Кояшның якты нурлары дөньяны балкыткан гаҗәеп ямьле язгы көннәрнең берсендә, Мөнир карт бәйрәм киемнәрен киеп, Киров районының бизәге саналган, 1866 елны нигез салынган Казан дары заводының йөз еллыгы хөрмәтенә 1966 елны төзелгән мәгърур Кызыл капка янына, сөекле хатыны белән очрашырга китә.

Әй бу заманалар, җырларда җырлана торган: «Искән җилләр, аккан сулар» кебек үткән дә киткән. Кызыл капка, тарихи һәйкәл буларак, үз сыйфатында кадерләп саклана торса да, Петров паркын әйләндереп алган биек тимер койма сүтелеп алынган, урман кебек куе агачлыклар сирәгәйгән, парк элеккеге сихри ямен җуйган. Хәзер аңа түләп керәсе түгел. Ул ачык. Капка төбен фашист илбасарларының котын алган, халык телендә полуторка дигән автомашинага көйләнгән «Катюша» җайланмасы саклый. Урам ягын тарихи сәхифәләрне хәтерләткән барельеф һәм дары заводының эшчәнлеген чагылдырган стенд бизи. Мөнир карт шуларны соклана-гаҗәпләнә кат-кат карап, инде берничә мәртәбә урап чыкса да, очрашырга килергә тиешле сөекле карчыгы һаман күренми. Ул инде пошаманга төшеп, борчыла ук башлый. «Соңга кала торган гадәте бар, ләкин килми калмый иде ләбаса» дип, ни уйларга да белми. Күңелен шомлы – хәвефле уйлар чолгап ала, күз аллары томаланып китә. «Нәрсә булды икән» дигән тәшвилле уйлар аны йөгертә башлый. Ул тыны кысылса да, абына-сөртенә өенә ашыга.

Әлсерәгәннән хәле киткән Мөнирнең калтыраган куллары ишек йозагының уемына ачкыч кертә алмый бераз изаланса да, ниһаять, өенә керә. Кемнеңдер тынычлыгын бозудан куркып, ярым чышылдап кына: «Хатынкаем, син кайда», – дип, як-ягына карала. Акрынлап йокы бүлмәсенә үтә. Анда исә, шәмаил эленгән дивар буендагы кәнәфидә мыштым гына елап утыручы Гайшәне күрә.

– Хатынкаем, нәрсә булды, ник елыйсың? – ди, Мөнир, хатынының каршына тезләнеп.

– Синең яныңа, очрашуга бара алмавыма үкенеп елыйм. Юкса мин бик тә теләгән идем. Иң затлы киемнәремне киеп, бизәнгән, ясанган идем. Яшь чакларда безнең очрашып, кавышкан кадерле урынга бик тә барасым килгән иде. Шул онытылмас вакытларны искә алып, моңарчы сер итеп саклап килгән иң мокатдәс сүзләремне әйтеп каласым килгән иде. Ләкин, минем өчен үтә кадерле бу очрашуга эти җибәрмәде, ди, Гайшә ачынып.

– Аның хәер-фатыйхасыннан башка яхшы булмас, дидем. Ә мин бик тә барырга теләгән идем югыйсә...

Кургашлы куркум

АКШтагы Стэнфорд университеты галимнәре карри тәмләткече ясауда кулланыла торган һәм дару үләне саналган куркумда нерв системасы өчен зыянлы кургаш булуын дәлилләгән. Тикшеренүчеләр Бангладеш халкы канына әлеге авыр металлның ни рәвешле эләгүен ачыклаган. Бу ил халкы куркум тәмләткечен күп куллана, ә аны эшкәрткәндә, ачык сары төс бирү өчен, буяу сыйфатында кургаш хроматы өстәлә икән – әлеге практика 1980 елларда су басулар үсемлек тукымаларын төссезләндергәннән бирле кулланыла. Кургаш өлкән яшьтәгеләрдә йөрәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгу ихтималын арттыра, балаларның үзәк нерв системасына зыян сала. Канында авыр металл микъдары югары булган сабыйларның 90 проценты хәерче илләрдә яши.

(“Phys.org.”).

Таң шәһәре

Ауровиль, яки “Таң шәһәре” – Һиндстанның көньягындагы халыкара шәһәр, ул ЮНЕСКО химаясендә исәпләнә. Тамилнад штатындагы Пудучерри шәһәре янында урнашкан бу кала сәясәт һәм дин белән кызыксынмаган, ирекле яшәргә омтылган кешеләргә тәгаенләнеп төзелгән. Ниндидер әкияткә, борынгы риваятькә охшаса да, бу – чынбарлык. 1968 елда, шәһәргә нигез салынган чакта, йөзләрчә ил вәкиле Ауровильгә үзләренең туган туфрагын алып килгән, аларны мәрмәр урналарга салып, Матримандир янына күмгәннәр. Хәзер биредә гомуми җыелышлар үтә. Матримандир “Ана гыйбадәтханәсе” дип тәрҗемә ителә һәм кешеләрне сәяси, финанс һәм социаль чикләүләрдән арындырырга тиешле яшәү рәвеше символы булып тора. Алтын гөмбәзле бу бинада шәһәр халкы бергә җыела һәм медитация белән шөгыльләнә. Үзәктә, нәкъ гөмбәз астында, гаять зур бәллүр шар әленеп тора, аңа көн буе кояш нуры төшкәнгә, бина эчендә бик якты. Шәһәр 50 мең кеше яшәрлек итеп салынган булса да, хәзер анда 2 мең кеше генә даими яши. Күпчелеге Һиндстаннан, әмма Франция, Германия, Израиль, Америка, Россия һәм башка илләрдән килүчеләр дә байтак. Алар үзәге Матримандирдан башланып, спираль булып урнашкан йортларда яши. Һәркем үз эше белән шөгыльләнә. Шәһәр үзен бөтен нәрсә белән үзе тәэмин итәргә тырыша: кыр-заводлары, икмәк пешерү йортлары, мәктәп-кинотеатрлары, җирле газета редакциясе, кояш батареясендә эшли торган ашханәсе бар. Калада барлык мөһим карарларны бергәләп кабул итәләр, мәр да, башка бердәм идарә органы да юк.

(“Die Presse”).

Полиглотлар

Кешенең чит телләр өйрәнү мөмкинлекләре чиксез. Кимендә дүрт телдә иркен аралашкан кешене полиглот дип йөртәләр. Тарихта мәгълүм тәүге полиглот – Ватикан кардиналы Джузеппе Каспар Меццофанти (1774-1849), ул 114 тел белгән, шуларның алтмышында иркен сөйләшкән, иллесендә шигырьләр язган. Рус язучысы Александр Грибоедов 9 телдә сөйләшкән. Лев Толстой инглиз, француз һәм немец телләрен камил белгән, итальян, поляк, чех, серб телләрендә укыган, грек, латин, украин, татар телләрен белгән, борынгы яһүд, төрек, голланд һәм болгар телләрен өйрәнгән. Николай Чернышевский 16 яшендә үк латин, борынгы грек, фарсы, татар, гарәп, француз, немец, инглиз, яһүд телләрен белгән. Копенгаген университеты профессоры Расмус Кристиан Раск (1787-1832) 230 телдә сөйләшкән һәм шуларның берничә дистәсенең сүзлек һәм грамматикаларын төзегән.

(“Мир новостей”).

Ничә тел бар?

Франция Фәннәр академиясе мәгълүматлары буенча, дөньяда барлыгы 3 мең тел исәпләнә. Ә инде кайбер диалектларны да санасаң, аларның саны 5 меңгә җитә. Шул рәвешле, Җирдә уртача миллион кешегә бер тел яки диалект туры килә. Телләрнең кайберләре өйрәнү өчен бик авыр. Мәсәлән, табасаран телендә 48 килеш, кабарда телендә 28 зат, убых телендә 80 тартык һәм нибары бер сузык аваз, седанг телендә 55 сузык аваз бар. Кытай теленең мандарин шивәсендә 885 миллион кеше сөйләшә, ул дөньяда иң күп кулланыла торган тел санала. Икенче урында – испан теле, аңарда 332 миллион кеше сөйләшә. Өченче урында – инглиз теле, ул 322 миллион кеше өчен аралашу чарасы булып тора. Рус теле кулланылышы буенча җиденче урында - 170 миллион кеше сөйләшә.

(“Telext Holidays”).

Энә-йорт

Нью-Йоркта планетадагы иң сәер йортлардан берсе файдалануга тапшырылган. 111 West 57th Street адресы буенча урнашкан 84 катлы күктерәр йорт хәзер дөньядагы иң юка биек бина санала, әмма ул яшәү өчен бик уңайлы һәм куркынычсыз итеп салынган. 435 метрлы Billionaires Row манарасын төзү хакында тәүге тапкыр 2013 елда игълан ителә, бер елдан соң субайларын кага да башлыйлар. 2017-2018 елларда исә, акча җитмәгәнгә, эш туктап тора. 2020 елның көзендә инде андагы ике фатир сатуга куела – икесе бергә 105 миллион долларга тәкъдим ителә. Әлеге күктерәр йортта иң “татлы калҗа” – манараның иң очындагы өч катлы пентхаус 100 миллион долларга сатылган, аның тәрәзәләреннән Үзәк паркка һәм әйләнә-тирәгә искиткеч манзара ачыла. Манарада һәр катта нибары бер фатир урнашкан, аларның бәясе 7 миллион доллардан башлана. Йорт никадәр генә футуристик тоелмасын, проект үткәннәр һәм киләчәкне бәйләп тора – аны гамәлгә кертүче девелопер янәшәдәге 1925 елгы Steinway Hall тарихи бинасын да тулысынча реконструкцияләгән. Анда кайчандыр данлыклы Steinway & Sons фортепиано җитештерүче офисы, концерт залы һәм мәдәният үзәге урнашкан булган, алар хәзер барысы да зиннәтле резиденцияләр итеп үзгәртелгән.

(“Robb Report”).

Иң зур аэропорт

Кытай башкаласы Пекиндагы Дасин аэропорты - дөньядагы иң зур һава аланы. Аэропортны биш ел буе төзегәннәр, ул барлыгы 450 миллиард юаньга (63 миллиард доллар) төшкән. 2025 елга Дасин аша елына 72 миллион, киләчәктә исә 100 миллион пассажир үтәр, дип фаразлана. Пекин үзәгеннән 46 чакрым ераклыкта урнашкан аэропортта дүрт полоса бар, гомуми мәйданы 1,5 миллион квадрат метрга якын. Баш терминал алтын йолдыз формасында ясалган. Әлеге һава аланында автомагистральләр һәм тимер юл кисешә. Аэропорттагы барлык транспорт, яктырткычлар, вентиляция экологиягә зыян китерми торган итеп эшләнгән. Терминалда яңгыр суын җыю һәм файдалану системасы да бар. Аэропорт Кытай Халык Республикасы оешуга 70 ел тулу хөрмәтенә танылган Гыйрак-Британия архитекторы Заха Хәдид бюросы проекты буенча салынган. Аны төзү өчен 11 торак пунктны җир белән тигезләгәннәр, тагын 24 ендәге 20 меңләп кешене каты тавыш астында яшәмәсен өчен күчергәннәр. Күчерелгәннәрнең һәркайсына 150 мең доллар компенсация түләп, яңа торак белән тәэмин иткәннәр. Терминалның нәкъ астында 5 линияле тимер юл урнашкан, андагы поездлар сәгатенә 300 чакрым тизлек белән хәрәкәт итә. Җир астыннан пассажирларны аэропортның һәр дүрт катына да эскалатор менгезә.

(“Reuters”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

16 май
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 12+
10.00, 23.30 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйләң».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Информационный геноцид. Война на уничтожение против России». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.40, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Ватандашлар». 6+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рәшит Абдуллин турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 16+
10.30, 21.00 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «1943». 12+
14.45 «Великие женщины России». 12+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 Великая война.
16.25 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 23.40 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15, 18.20, 0.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ВАША ЧЕСТЬ». 16+
22.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.15, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Иосиф Бродский.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.20 «Плавск. Дворец для любимой».
8.50, 16.25 «ПРОФЕССИЯ - СЛЕДОВАТЕЛЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Театральные встречи. БДТ в гостях у москвичей».
12.25 «Дуга Струве без границ и политики».
13.05 Линия жизни. Анатолий Ким.
14.00 «Первые в мире».
14.20, 21.00 Больше, чем любовь.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
17.35 К 30-летию Камерного ансамбля «Солисты Москвы». Константин Хабенский и Юрий Башмет.
18.35 «Города, завоевавшие мир. Амстердам, Лондон, Нью-Йорк».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Егор Сартаков. «Застенчивая» любовь в русской литературе».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.40 «Сати. Нескучная классика...»
22.25 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».
23.20 «Рассекреченная история».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ВСПЫШКА». 16+
23.25 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

17 май
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.50 Спектакль «Чёрная курица, или Подземные жители». 6+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рөстәм Вәлиев турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

1.45, 14.45 «Великие женщины России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 16+
10.30, 21.00 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «1943». 12+
15.00 «Тайны анатомии». 12+
15.30 Великая война.
16.25 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 23.45 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15, 18.20, 0.25 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ВАША ЧЕСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Города, завоевавшие мир. Амстердам, Лондон, Нью-Йорк».
8.35 Цвет времени. Анатолий Зверев.
8.50, 16.35 «ПРОФЕССИЯ - СЛЕДОВАТЕЛЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Георгий Свиридов».
12.10 «Забытое ремесло».
12.25, 22.25 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».
13.20 «Игра в бисер» «Поэзия Афанасия Фета».
14.00 «Первые в мире».
14.15 Больше, чем любовь.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Виктор Васнецов».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.40 К 30-летию Камерного ансамбля «Солисты Москвы». Богдан Волков и Юрий Башмет. «XX век - век поиска».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Владимир Сурдин. «Жизнь вне Земли».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.40 «Белая студия».
23.20 «Рассекреченная история».

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ВСПЫШКА». 16+
23.25 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

18 май
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА 2». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.50 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «Шома бас» һәм «Сәйләң».
15.25 Спектакль «Корова». 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Сагыйть Хәбибуллин турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

1.45, 14.45 «Великие женщины России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК». 16+
10.30, 21.00 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «1943». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 Великая война.
16.25 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 23.45 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15, 18.20, 0.25 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ВАША ЧЕСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Города, завоевавшие мир. Амстердам, Лондон, Нью-Йорк».
8.35 Цвет времени. Ар-деко.
8.45, 16.35 «ПРОФЕССИЯ - СЛЕДОВАТЕЛЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Доктор из Кургана». Академик Гавриил Илизаров».
12.10 «Забытое ремесло».
12.25, 22.25 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».
13.20 Искусственный отбор.
14.05 75 лет со дня рождения Владимира Качана. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.45 К 30-летию Камерного ансамбля «Солисты Москвы». Хор «Голоса Конельяно» и Юрий Башмет.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Максим Кронгауз. «Норма и коммуникация в современном мире».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.40 Власть факта. «Священный союз и трудный выбор Александра I».
23.20 «Рассекреченная история».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ВСПЫШКА». 16+
23.25 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

19 май
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 12+
10.00, 0.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА 2». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Бергәләп әйрәник» һәм «Сәйләң».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең республика - безнең гамәл». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Әлфия Айдарская турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

1.45, 14.45 «Великие женщины России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК». 16+
10.30 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «1943». 12+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 Великая война.
16.25 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «ОДНОЛЮБЫ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 23.45 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15, 18.20, 0.25 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ВАША ЧЕСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+

14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Города, завоевавшие мир. Амстердам, Лондон, Нью-Йорк».
8.35 «Забытое ремесло».
8.55, 16.35 «ПРОФЕССИЯ - СЛЕДОВАТЕЛЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Вас приглашает Клавдия Шульженко».
12.25, 22.25 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».
13.20 Абсолютный слух.
14.00 «Первые в мире».
14.15 90 лет со дня рождения Майи Булгаковой. Документальный фильм.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Мастера Суджи и Самоурядова».
15.45 «2 Верник 2».
17.40 К 30-летию Камерного ансамбля «Солисты Москвы». Даниил Трифонов и Юрий Башмет.
18.35 «Тайна гробницы Чингисхана».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Анна Марущенко. «Джексон Поллок в парфюмерии».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Ищите женщину». Какая ты красивая, когда молчишь!»
21.40 «Энигма. Юстус Франц».
23.20 «Рассекреченная история».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ВСПЫШКА». 16+
23.25 «ЧП. Расследование». 16+
23.55 «Поздняков». 16+

Җомга

20 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 12+
10.00 Пленарное заседание Группы стратегического видения «Россия - исламский мир».
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 Церемония установки памятного камня строительства Соборной мечети 1100-летия принятия ислама Волжской Булгарией.
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.30 «Рыцари вечности». 12+
15.15 «Тәймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00, 20.00 Концерт. 6+
21.00 «Юлчы». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
10.00 «Россия - ислам деньясы» стратегик караш төркеменең пленар утырышыннан турыдан-туры трансляция. 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Равил Харисов турында телеочерк. 6+
13.00 Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу Җәмигъ мәчетенә истәлекле таш салу чарасыннан турыдан-туры трансляция. 6+
13.40 Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» YII татар музыкасы фестивале. 6+
15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
15.30 «Нәсыйхәт». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Родная земля». 12+
19.35 «Казанның кадерле кичләре». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

1.45, 14.45 «Великие женщины России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК». 16+
10.30, 21.00 «ОДНОЛЮБЫ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «МОЙ МАЛЬЧИК». 12+
15.00 «Тайны анатомии». 12+
15.30 Великая война.
16.25 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
23.00 «ТАЙНЫ ГОРОДА ЭН». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.40 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
23.40 «АРАХИСОВЫЙ СОКОЛ». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Тайна гробницы Чингисхана».
8.35 «Агатовый каприз Императрицы».
9.05, 16.35 «ПРОФЕССИЯ - СЛЕДОВАТЕЛЬ».
10.20 «ШУМИ ГОРОДОК».
11.30 «Петр Алейников. Неправильный герой».
12.10 «Либретто». Л. Минкус «Баядерка».
12.25 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».
13.20 Власть факта. «Священный союз и трудный выбор Александра I».
14.00 «Первые в мире».
14.15 Больше, чем любовь.
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Юстус Франц».
16.20 «Забытое ремесло».
17.30 Цвет времени. Владимир Татлин.
17.45 К 30-летию Камерного ансамбля «Солисты Москвы». Михаил Пореченков и Юрий Башмет. «Маяковский и Есенин».
18.45 «Билет в Большой».
19.45 Искатели. «Неизвестная столица России».
20.35 Линия жизни. Феликс Коробов.
21.30 «КРЫЛЬЯ».
22.55 «2 Верник 2».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
20.00 «Жди меня». 12+
20.50 «Страна талантов». 12+
23.00 «Своя правда». 16+

Шимбә

21 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 Мероприятие, посвящённое 1100-летию принятия ислама Волжской Булгарией.
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.35 Современная музыка Мусульманского мира. Концерт, посвящённый 1100-летию принятия ислама Волжской Булгарией 6+
17.00 «Мин». 12+
17.30 «Халкым минем...» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Ватандашлар». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «НЕБО В АЛМАЗАХ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Атылган йолдыз эзләреннән. Ф.Яруллин». 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган тантанадан турыдан-туры трансляция. 6+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Ислам дөньясының заманча музыкасы». Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган концерт. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Ватандашлар». 6+
18.15 «Башваткыч». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җиде малай». Фирдүс Тямаев концерты. 12+
23.20 Спектакль «Китәм инде, китәм». 12+

«ЭФИР»

1.45, 15.45 «Великие женщины России». 12+
2.00, 3.00, 19.00 «Город». 16+
5.00 «Мировой рынок». 12+
6.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
6.30 «Биосфера. Законы жизни». 12+
7.00 «Три кота».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Планета лошадей». 12+
8.30 «ЛИШНИЙ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВУЛКАН СТРАСТЕЙ». 16+
14.35 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
21.00 «СИЛЬВИЯ». 16+
22.55 «Человек - невидимка». 16+
23.45 «ДРУГАЯ БОВАРИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «Любовь Полищук. Последнее танго». 12+
11.10, 12.15 «Видели видео?»
13.45, 15.15 «ДОРОГОЙ МОЙ ЧЕЛОВЕК».
15.55 «Елизавета Федоровна. Осталась лишь одна молитва». 12+
18.20 «Пусть говорят». 16+
19.55 «На самом деле». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «МАДАМ ПАРФЮМЕР». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.15 «Доктор Мясников». 12+
13.20 «ТОЛЬКО О ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ТОТ МУЖЧИНА, ТА ЖЕНЩИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.55 «РАСПИСАНИЕ НА ЗАВТРА».
9.25 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.50 «НАЧАЛО».
11.20 Больше, чем любовь.
12.00 «Королевство кенгуру на острове Роттнест».
12.55 Черные дыры. Белые пятна.
13.35 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.50 Концерт в Большом зале Московской консерватории. Солист и дирижер Михаил Шехтман.
16.20 «Рубец». 16+
16.50 «Ищите женщину». Какая ты красивая, когда молчишь!»
17.35 «ИЩИТЕ ЖЕНЩИНУ».
20.00 Большой джаз.
22.00 «Агора».
23.00 «ПРЕКРАСНЫЙ НОЯБРЬ».

«НТВ»

5.00 «Хорошо там, где мы есть!»
5.25 «ЧП. Расследование». 16+
5.50 «КРОВНЫЕ БРАТЬЯ». 16+
7.30 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00 «Тайные рецепты неофициальной медицины». 12+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.10 Ты не поверишь! 16+
21.00 «Секрет на миллион». 16+
23.00 «Международная пилорама». 16+
23.35 Концерт «Квартирник НТВ у Маргулиса». 16+

Якшәмбе

22 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Яратып яшик!» Раяз Фасихов концерты. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Полосатая зебра».
9.00 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Тархан». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.35 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Соотечественники». 12+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ВЕЧНОСТЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.00 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Ватандашлар». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Ул бит кичә иде». 12+
9.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Җырлы-моңлы сынчы-тылсымчы Бакый Урманче». 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.30 Спектакль «Йөрәк маем». 12+
15.50 «Җырларымда син генә». Рафил Җәләлиев һәм Эльмира Гыйльфанова концерты.
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «СТЕНДАПхана». 16+
21.40 «Китмә, сандугач». Илһам Шакировядкәре. 6+

«ЭФИР»

1.45 «Великие женщины России». 12+
2.00, 3.00, 19.00 «Город». 16+
5.00 «Мировой рынок». 12+
6.00 «Тайны анатомии». 12+
6.30 «Клятва Гиппократа». 12+
7.00 «Три кота. Сезон 3».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Удиви меня». 12+
9.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «СИЛЬВИЯ». 16+
15.00 «Планета лошадей». 12+
15.30 «ЛИШНИЙ». 12+
21.00 «ВУЛКАН СТРАСТЕЙ». 16+
22.35 «ВСЕ, КРОМЕ ЛЮБВИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.45, 6.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ»). 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15 «Ванга. Пророчества». 16+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
14.10 «Рихард Зорге. Подвиг разведчика». 16+
15.15, 18.20 «ЗОРГЕ». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «Харджиев. Последний русский футурист». 16+

«РОССИЯ»

5.35 «ДЕВУШКА В ПРИЛИЧНУЮ СЕМЬЮ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.15 «Доктор Мясников». 12+
13.20 «ТОЛЬКО О ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Каштанка».
7.10 «ИЩИТЕ ЖЕНЩИНУ».
9.40 «Мы - грамотеи!»
10.20 «ПРОЩАНИЕ СЛАВЯНКИ».
11.40 Диалоги о животных.
12.25 Невский ковчег. Теория невозможного. Михаил Дудин.
12.50 «Игра в бисер» «Осип Мандельштам. «Шум времени».
13.35 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.50 «ПРЕКРАСНЫЙ НОЯБРЬ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Фарид Бикчантаев. В поисках свободы».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «НАЧАЛО».
21.40 «Коппелия».
23.40 «МАЯК НА КРАЮ СВЕТА».

«НТВ»

5.10 «АФЕРИСТКА». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.15 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.30 «Ты супер! 60+». 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Кышкы салкын көндә Буа районы полициясенә Сәет Хәйсаров шундый шомлы хәбәр ирештерә. 24 гыйнварда өлкән яшьтәге туганнан туган апасының хәлен белергә дип килгәч шәхси йортның ишегалдында кар түгә торган зур гына калай тагаракны күреп сагая кала, чөнки өеп тутырылган кар астыннан чыгып торган аяк киеме күзгә ташлана, ә якынрак килеп карагач, үзе әйтмешли, ошбу киемнең буш түгел икәне, ягъни аның эчендә кеше аягы булуы ачыклана. Шул сәбәпле, абзый өйгә кереп тә тормыйча, полициягә таба тәпили.

Кар астында мәет бар

Авыру апасы 1969 елгы улы Илгиз карамагында. И.Ягъфәров һөнәри училищеда укып механизатор, шофер белгечлекләре алган, армия хезмәтеннән соң төрле оешмаларда машина, автобус йөртүче булып эшләгән, соңгы елларда үз хуҗалыгында агач әйберләр ясап сату белән шөгыльләнә. Илгиз гаилә кормаган, ягъни өйләнмәгән буйдак кеше, гомере буе әнисе белән бергә торган. Туганнары, күршеләр аның турында бары тик яхшы сөйлиләр, ләкин артыгын эчүен, аның янына шешәдәш сәрхушләр килеп йөрүен әйтәләр.

Тагарактагы кар астында шундый кунакларның берсе, 47 яшьлек В.Шакирҗанов була да инде. Вилнур да хәмергә хирыслыгы аркасында юньле-рәтле тормыш кора алмаучылар рәтеннән. Туганнары аның Алабугада язылышмыйча бер хатын белән яшәвен, ун яшьлек малае булуын әйтә. Биш-алты ел элек аерылышканнан соң, туган шәһәре Буага кайтып ялгыз яшәгән, очраклы эшләргә йөреп тапкан акчасын башлыча эчәргә тоткан, баласы белән дә аралашмаган. Рәсми кәгазьләрдә бернигә тапкыр хөкемгә тартылуы, яшәү урынында тискәре бәяләнүе дә күрсәтелә аның.

Фаҗиганең исерекләр бәрелеше нәтиҗәсе икәне аермачык була. Чөнки мәетнең йөз-битендә күгәргән-шешкән җәрәхәтләр күренеп тора. Хәер, хуҗа үзе дә ике көн элек, ягъни 22 гыйнвар кичендә Вилнурның баш тирәсенә өч-дүрт тапкыр тимер көрәк белән кундыруын яшерми. Тикшерү комитетының Буа районара бүлеге тикшерүчесе Айгөл Абдуллина шул көнне үк аңлы рәвештә кеше үтерү очрагы буенча җинаять эше кузгата, өч көннән суд карары белән Илгиз Ягъфәров сак астына ябыла. Аның авыру әнисен Чаллыда яшәүче кызы үз янына ала. Җинаять эшендә зарар күрүче итеп мәрхүм В.Шакирҗановның Әлмәт районында торучы бертуган сеңлесе билгеләнә.

И.Ягъфәров мәет табылган көнне биргән күрсәтмәсендә вакыйганы сурәтләп бирә. Әйтүенчә, кичке сәгать 8 ләр тирәсендә шул тирәдәге «Добрый» кибете янында очраша алар һәм Вилнурның бер яртысын икәүләп эчәргә булалар, шул нияттән Илгизнең остаханәсенә керәләр, ошбу шешә бушагач та, хуҗа өеннән алып чыккан икенчесен бушатырга керешәләр. Исерекләр ишегалдында тәмәке тартырга чыккач бәйләнешеп китә. Илгиз моны утырып кайткан В.Шакирҗановның начар сүзләр кычкырып кимсетә башлавы белән аңлата. Ничек кенә булмасын, аяныч тәмамлана бу, сәрхушләр бәргәләшеп, җирдә әүмәкләшеп кенә калмый, шул тирәдәге көрәккә дә ябышалар. Илгиз Вилнур кулындагы тимер көрәкне тартып алып кыры белән түгел, ә яссы ягын туры китереп ике тапкыр битенә тондыруын, ул җиргә чалкан егылгач та, тагын шунда ук ике мәртәбә сугуын әйтә. Сөйләвенә караганда, хәрәкәтсез яткан шешәдәшен торгызып та карый, ләкин үлде дип уйлый һәм өенә кереп китә. Шактый вакыт узгач, ишегалдына чыгып җансыз гәүдәне тимер тагаракка сала, аны җәймә белән каплап, алдан канга буялган, аннан соң чиста кар белән күмеп куя. Ул чакта исерек, хәлсез идем, шуңа күрә өстерәп өенә илтеп ташларга яисә читкәрәк алып китеп күмеп куярга көчем юк иде ди ул. Шул рәвешле, мәетле савыт тагын бер тәүлектән артык аның ишегалдында капка буенда тора. Әлбәттә, ут йотып йөри ул. Сатучы хатын-кыз Илгизнең 23 гыйнварда көндез кибеткә кереп тә аракы алмыйча чыгып китүенә гаҗәпләнүен әйтә.

Шулай итеп И.Ягъфәров дүрт мәртәбә көрәк белән тондыруын таный, ләкин моны үтерәм дип түгел, ә имгәтү өчен чамалап кына суктым ди, димәк, үтерү нияте булуын кире кага. Икенче көнне әлеге явызлыгын ни рәвешле кылуын шаһитлар алдында сөйләп күрсәтеп йөри. Ләкин тора-бара алданрак биргән күрсәтмәләренә төзәтмәләр кертә, ягъни мин өйгә кереп киткәндә исән иде, ыңгырашуы ишетелеп торды, өенә кайтып китәр дип уйладым, дип белдерә. Һәм, ахыр чиктә, мәрхүм В.Шакирҗанов сәламәтлегенә җиңел зыян китерүен генә таный.

Яклау ягының ошбу фикере нигезсез түгел. Эш шунда ки, суд-медицина экспертизасы нәтиҗәләрендә Вилнурның маңгаеннан иягенә чаклы дистәгә якын җәрәхәт санап үтелә, ләкин алар җиңел дәрәҗәдә дип белдерелә, ә муен, кул тирәсендәге сыдырылган, күгәргән урыннар сәламәтлеккә бөтенләй зыян китермәгән булып чыга, димәк ки, аларның берсе дә үлемгә сәбәпче, ә Ягъфәров үтерүче түгел, дигән сүз. Чөнки 1974 елгы ир-атның туңып үлүе ачыклана. Һәм моны мәрхүмнең исереклегенә дә сылтарга була бит.

Шул ук вакытта ир кешенең катып үлүе аның башына сугып егу нәтиҗәсе икәне дә аермачык кебек. Шуңа күрә дә тикшерү комитеты һәм прокуратура И.Ягъфәровка аңлы рәвештә кеше үтерү дигән бик җитди гаепләү белдерә. Аның эчтәлегенә кыскача гына тукталсак, Илгиз шешәдәше Вилнурны аңсыз һәм нык исерек хәлдә икәнен, димәк, үзлегеннән котыла алмаячагын белә, аңлый торып үләргә калдырган булып чыга.

Мондый эшләрне карау хөкем утырышларында бәхәсле уза. Әгәр экспертиза нәтиҗәләрендә тән җәрәхәтләренең үлемгә этәргеч бирүе күрсәтелмәү һәм, әлбәттә, хәзерге заманда җинаять кылучылар хокукларын яклаучы законнарның биниһая күп булуын исәпкә алсак, судта яклау ягы фикеренә өстенлек бирелү, ягъни И.Ягъфәровның җиңел җәза белән котылу мөмкинлеге юк түгел.

* * *

Минзәләдә яшәүче 45 яшьлек ханымның аерылышкан ире белән «сожителе» арасындагы бәрелеш тә үтерү һәм мәетне карга күмү белән төгәлләнә.

Надежда һәм Вәкил Галимовлар 2009 елда язылышып, законлы никахта биш ел яшәгәч, рәсми рәвештә аерылышалар. Аннан соң да өч ел чамасы бергә торалар. Ләкин 2017 елда араны өзәләр, хатын-кызның әйтүенә караганда, гаилә башлыгы юньләп эшләмичә эчеп йөри. Әгәр Вәкилнең элегрәк хөкем ителүен, административ тәртиптә дә җавапка тартылуын исәпкә алсак, монда хаклык юк түгелдер. Әмма полициядә Н. Галимованың үзенең дә хәмергә хирыслыгын әйтәләр. Ир кеше 2011 елгы улы белән аралашып тора, аны шәһәр янәшәсендәге Коноваловка авылындагы өенә кунакка да алып киткәли.

Изге урын буш тормый дигәндәй, күп тә үтми Н.Галимова тормышында үзеннән яшьрәк яңа ир заты пәйда була. 1980 елгы Евгений Сундрунов турында озаклап сөйләргә мөмкин. 18 яшеннән башлап урлау, машина куу, үтерү белән янау кебек гамәлләре өчен сигез мәртәбә хөкемгә тартылган, берсендә хәтта 6 ел ярымга иреgеннән мәхрүм ителгән, ләкин төрмәгә утыртылган саен яхшы тәртибе өчен вакытыннан алда иреккә чыгарылып килгән, шулай да 8 елдан артык гомерен тимер рәшәткә артында уздырган. Надежда белән тора башлагач та, аерылышкан хатыны белән яшәүче кечкенә кызына алимент түләмәгән өчен, тугызынчы хөкемен алып, дүрт ай гомерен кырыс режимлы колониядә уздырып кайткан.

Ошбу парның рәтле тормыш кора алуына ышаныч булмый, билгеле. Узган ел азагында мөнәсәбәтләр нык кискенләшә, хуҗабикә ирне өеннән куа башлый, анысы, тиз генә бирешергә теләмичә, килгәли һәм еш кына хатынны тукмап китә. Ул арада ошбу өйдә Вәкил күренгәли, 23 гыйнвардан соң кунарга да кала башлый, әлеге очрашулар дуслык вә үзара аңлашу шартларында бара, чөнки өстәлдән хәмер төшми.

25 гыйнварда инде 4 нче сыйныфта укучы малай мәктәптән кайтканда, әти-әнисенең сыйланып утыруын күрә. Аталы-уллылар кибеткә чыгып киткән арада өйгә исерек Евгений килеп керә. Тегеләр кайтып җиткәнче, «хыянәтче» хатынны бик ныклап дөмбәсләп һәм төрле яман сүзләр әйтеп куркытырга өлгерә ул. Дүрт-биш сәгатьтән кулына балта тотып пәйда була һәм икегезне дә «хәл итәм» дип котырына. Шөкер, әлеге очраклар зур хәвефкә китермичә тәмамлана. Әйтүләренчә, Вәкил белән хатын ике шешә аракы эчеп йокларга яталар. Соңрак Е.Сундруновның шушы галәмәтләре үтерү белән янау дигән ике җинаятьчел гамәл дип табыла. Евгений гаебен танымый, куркытмадым, күршедән алып торган балтаны кайтарып бирергә генә уйладым дип барысын да кире кага. Ләкин хатын-кыз күрсәтмәләренә, аның тәнендәге җәрәхәтләр һәм башка дәлилләргә өстенлек бирелә.

Әмма болары эшнең башы гына була әле. Икенче көнне иртә белән Надежда улын мәктәпкә озата, аннан соң кичтән калган аракы белән баш төзәткәч, икәүләп караватка яталар. Шул мәлдә килеп кергән теге аймас Евгений, әлбәттә, тыныч кала алмый, ә бәлки көндәшне котельныйга чыгып сөйләшергә чакыра. В.Галимов киенеп аның артыннан юнәлә, бер-ике минуттан ук хатын-кыз аның кычкырып җибәрүен ишетә, тиздән акайган Евгений килеп кереп, теләгеңә ирештең дип акыра-акыра, аны җилтерәтеп пар казаны торган бүлмәгә алып керә. Һәм канга батып идәндә хәрәкәтсез яткан Вәкилгә ымлап терчә булып чыкты, суярга туры килде, дип кычкыра.

Ошбу коточкыч хәлне күреп тетрәнгән хатын-кыз үз гомере өчен дә курка һәм теге явыз кушканнарны үти. Канга буялган пычакны юып куя, полициягә хәбәр итмичә өйдә утыра. Бераздан котельныйга кергәч, мәетнең юкка чыгуын күрә, анда төсе киткән Ришат атлы Коноваловка кешесе дә булгач, мәетне икәүләп чыгаруларын төшенә һәм идәнне юып куя да яңадан өенә кереп утыра. Явыз бәндә исә дусты Ришатка бәрәңге бакчасындагы кар астындагы мәетне караңгы төшкәч алып китеп күмәргә кирәк булачагы турында сөйләнә.

Өйлә вакытында кайткан укучы малай әнисенә казанлы бүлмәдәге кәнәфидә Сундрунов йоклавын әйтә. Русланга (исеме үзгәртелә) участок инспекторына шалтыратырга кушыла. Малай аның телефон номерын белә, чөнки әлеге гаилә низаглары белән еш мәшәкатьләнгән полиция хезмәткәре аңа Сундрунов килсә, теләсә кайсы вакытта шалтырат дигән була. Шул рәвешле, хәбәр район полициясенә барып җитә.

Оператив төркемне Надежда каршы ала һәм барысын да кыскача сөйләп бирә, бакчадагы мәет күмелгән урынны күрсәтә. Сундруновны уятып эчке эшләр бүлегенә алып китәләр. Суд-медицина экспертизасы 1977 елгы ир-ат язмышы күкрәкнең уң ягына ике мәртәбә пычак чәнчү хәл иткән, ә муен, ияк һәм күкрәктәге тагын өч яра сәламәтлеккә җиңел дәрәҗәдәге зыян китергән дип белдерә.

Тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән В.Н.Сәлахов Е.Сундрунов явызлыгын аңлы рәвештә кеше үтерү дип таба. Моңа үтерү белән янау дигән югарыда телгә алынган эпизодлар да өстәлә, билгеле. Евгений аларның ялангач ятуларын күргәч, Галимовны үтерергә уйладым, шул сәбәпле кухня өстәлендәге пычакны алып кесәмә салдым дип барысын да яшермичә бәян итә.

Наил ВАХИТОВ.

Яңара алмаган «Беренче театр»

К.Тинчурин театрында Г.Камалның «Беренче театр»ын куялар, дигән хәбәр таралгач, театр сөючеләрнең күңеле, һичшиксез, җилкенеп куйгандыр. Бигрәк тә аның традицион һәм авангард театрлар каршылыгына корылуын, Галиәсгар аганың әсәреннән аермалы буларак, баш геройларның берсе Хәмзә байның яңа төр театрга каршы чыгуы турында икәнен белгәч, премьера көнен көнләп, сәгатьләп сагаеп шактый булгандыр. Режиссер Илнур Гарифуллин бу идеяне уңышлы итеп тормышка ашыра алса, чыннан да, кызыклы спектакль килеп чыгасы иде. Әмма өметләр акланмады.

Югыйсә сәхнәдә кызыклы яңалыклар да бар иде. Сәхнә зурлыгындагы бер-берсенә тоташтырылган ике келәм иске театрны, традицияләрне гәүдәләндерә, янәсе. Келәмнәр агач җирлеккә беркетелеп, анда ишекләр уелган һәм геройлар шул ишекләрдән керен-чыгып йөри. Рәссам Александр Греньковның бу табышы шундый уңышлы ки, бу спектакльдә сәхнәдә башка нәрсә кирәкми дә сыман тоелды. Аз чаралар белән күпне белдерткән һәм вакыйгалар барышында куллану өчен файдалы келәмле декорация – тамашаның уңышы. Костюмнар буенча рәссам Нәҗия Галимованың эше дә күзләрне иркәләде. Әмма модельер костюмнарны сәхнә бизәлешләренә яраклаштырмыйча, үзләренә аерым иҗат итеп шактый оттырган. Нәтиҗәдә, Факиһә һәм Бибинең күлмәкләре келәмнәр янында югалып кала. Һәм күлмәкләренең төссезләнеп калуы тулаем образны тонгыраклаңдыра төшә.

Артистларга тел-теш тидерерлек түгел. Бигрәк тә иркә, назлы бай кызы Гафифәне гәүдәләндерүче Айсылу Мөсәлләмовага. Айсылу кебек үк һәр җөмләдә басымнарны урынында куеп сөйләшүче Хәбибрахман – Эдуард Никитинга да мактаудан башка сүз әйтеп булмый. Биби Диләрә Фәттахова да бер дигән. Фатыйх Айдар Фәтрахмановның да һәм уенында, һәм сөйләм телендә хилафлык юк. Факиһәне гәүдәләндерүче Альбина Гашигуллинаның уены төсмерләргә шундый бай ки, кайвакыт хәтта актриса артыгын кыланып җибәрә дигән тәэсир кала. Вәли образын иҗат иткән Илфак Хафизовның сөйләм телендә пафос күп, табигыйлык, тормышчанлык җитенкерәми кебек. Хәмзә байны уйнаучы Татарстанның атказанган артисты Ренат Шәмсетдинов артык йомшак, мәрхәмәтле тоелды. Яшьләрнең өнен качырган усал Хәмзә бай түгел иде ул.

Җыр-бию өлешләре матур гына килеп чыккан. Сәхнәдәге гармонияне ара-тирә урындык, ләгән белән шакылдаулар, дөбердәүләр генә боза.

Аларына да түзәр идең, ахырдан Хәмзә байдан авангард театрны сүгеп көн күргән Кыек Каләмов ясап, аны пьедесталга һәйкәл итеп бастырып куймасалар. Бу ни бу, дип аптырашта калды шушы мәлдә тамашачы. Матур гына барган «Беренче театр»дан бер мизгел эчендә җилләр исте. Өстәвенә, рекламада вәгъдә ителгән традицион һәм авангард театр каршылыгын да күрмәдек. Шулай итеп тамашачыны алдаладылар булып чыга. Классиканы да ахыргача әзлеклелек саклап куя белмәделәр, ахырдан тәмен җибәрделәр, үзләре дә юньле-рәтле яңалык иҗат итә алмадылар. Бөтен көчәнүләре театрларны әнә шундый суррогатлар өчен тәнкыйтьләгән журналистларга үчләшүгә кайтып калды. Пушкин картасы белән күрсәтер өчен дип, балалар һәм яшүсмерләргә әнә шундый суррогат әзерләүләре бик аяныч.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 13.05.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе иректә

Тираж – 2710 данә

Заказ 2752

16+